качеств, способностей выполнения обязанностей опекуна (попечителя) при рассмотрении заявлений граждан, выразивших желание стать опекуном (попечителем).

5. В целях соблюдения прав граждан на охрану здоровья и медицинскую помощь Министерству здравоохранения Республики Татарстан принять дополнительные меры, направленные на организацию своевременной записи к специалистам медицинских организаций, осуществляющих оказание амбулаторно-поликлинической помощи в рамках программы государственных гарантий бесплатного оказания гражданам медицинской помощи на территории Республики Татарстан.

6. В целях соблюдения прав несовершеннолетних детей в сфере образования органам местного самоуправления:

осуществлять контроль за проведением заблаговременной разъяснительной работы в общеобразовательных организациях по вопросам приема учащихся в 10-ые классы, в том числе по организации индивидуального отбора для приема на профильное обучение;

усилить контроль за своевременным проведением ремонтных работ в образовательных организациях.

7. В целях реализации жилищных прав граждан Министерству образования и науки Республики Татарстан при рассмотрении заявлений об обеспечении жилыми помещениями специализированного жилищного фонда в каждом случае учитывать положения Порядка формирования списка детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, утвержденного постановлением Правительства Российской Федерации от 04.04.2019 № 397, которые подлежат обеспечению жилыми помещениями в части требований к перечню документов, которые обязан представить заявитель для включения в указанный список.

8. В целях реализации права человека на благоприятную окружающую среду Министерству экологии и природных ресурсов Республики Татарстан активизировать работу в качестве модератора ГИС РТ «Народный контроль» по категории «Свалки».

9. В целях соблюдения и защиты прав лиц, отбывающих наказание в виде лишения свободы или принудительных работ, освобожденных из мест лишения свободы:

9.1. Управлению Федеральной службы исполнения наказаний по Республике Татарстан:

оказывать содействие органам службы занятости в организации проведения в исправительных учреждениях выездных ярмарок вакансий для осужденных, срок отбытия наказания которых составляет менее шести

месяцев, с участием руководителей (должностных лиц) организаций, в которых имеются вакантные места;

при заключении соглашений с работодателями по трудоустройству осужденных к принудительным работам принимать меры по недопущению нарушений трудовых прав осужденных в части оплаты труда (в случаях установления работодателями осужденным к принудительным работам заработной платы в размере менее установленного минимального размера оплаты труда, направлять соответствующие сведения в контрольно-надзорные органы).

9.2. Органам местного самоуправления организовать работу межведомственной комиссии по вопросам ресоциализации лиц, освобожденных из мест лишения свободы, в соответствии с Типовым положением о муниципальной межведомственной комиссии по вопросам ресоциализации лиц, освобожденных из мест лишения свободы, утвержденным постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 29.07.2019 № 631.

10. В целях правового просвещения жителей республики:

10.1. Кабинету Министров Республики Татарстан рассмотреть вопрос о включении в Государственную программу «Обеспечение общественного порядка и противодействие преступности в Республике Татарстан на 2014 – 2025 годы», утвержденную постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 16.10.2013 № 764, проекта по реабилитации осужденных, попавших в зависимость от психоактивных веществ, реализуемого Уполномоченным совместно с Казанской общественной организацией родственников наркозависимых «Вера» и Региональной общественной организацией «Профилактика и инициатива в области охраны здоровья населения и предотвращения социально негативных явлений»;

10.2. Государственному комитету Республики Татарстан по архивному делу, Государственной инспекции труда в Республике Татарстан, Министерству труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан продолжить совместную работу с Уполномоченным по организации обучающих семинаров-совещаний руководителей и кадровых работников организаций и предприятий по вопросам соблюдения трудовых прав граждан;

10.3. Министерству строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан, Государственной жилищной инспекции Республики Татарстан, Саморегулируемой организации Регионального некоммерческого партнерства «Содружество организаций управляющих многоквартирными домами Республики Татарстан», Некоммерческому партнерству «Региональный Центр общественного контроля в сфере жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан» принять

участие в реализации проекта Уполномоченного по проведению обучающих семинаров-совещаний для управляющих организаций по вопросам соблюдения прав граждан в сфере жилищно-коммунального хозяйства;

10.4. Татарской региональной организации Общероссийской общественной организации инвалидов «Всероссийского ордена Трудового Красного Знамени общество слепых», Татарскому республиканскому отделению Общероссийской общественной организации инвалидов «Всероссийское общество глухих», Татарской республиканской организации Всероссийского общества инвалидов – «Общество инвалидов Республики Татарстан» принять участие в реализации проекта Уполномоченного – Школа правовых знаний для лиц с ограниченными возможностями здоровья и родителей (законных представителей) детей-инвалидов.

Уполномоченный по правам человека
в Республике Татарстан С.Х.Сабурская

г. Казань
Февраль, 2021 год

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ 2020 ЕЛДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ ДОКЛАДЫ**

## ЭЧТӘЛЕК

**Кереш...............................................................................................................93**

**Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүне анализлау..................................95**

**Гражданнарның сайлау хокукларын яклау....................................................107**

**Вәкаләтле вәкилнең кешенең социаль хокукларын яклау буенча эшчәнлеге........................................................................................114**

**Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын яклау буенча эшчәнлеге.....................................................144**

**Кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре өлкәсендә хокукый агарту, аларны яклау формалары һәм ысуллары.......................................................154**

**Йомгак..........................................................................................................168**

## Кереш

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге турындагы әлеге еллык доклад 2000 елның 3 мартында дөнья күргән 95 нче «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында»гы Татарстан Республикасы Законының 26 нчы маддәсенә ярашлы рәвештә әзерләнде һәм Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасы Конституция суды рәисенә, Татарстан Республикасы Югары суды рәисенә, Татарстан Республикасы Арбитраж суды рәисенә, Татарстан Республикасы Прокурорына җибәрелә.

Докладта Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең (Алга таба – Вәкаләтле вәкил) 2020 елдагы эшчәнлегенең статистика мәгълүматлары китерелә, гражданнарның социаль һәм сәяси хокукларын, шулай ук мәҗбүри тоту урыннарындагы гражданнар хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилнең эш үрнәкләре күрсәтелә, проблемалы хәлләргә күзәтү ясала. Докладның аерым бүлеге халыкны хокукый агартуга булышлык итүгә багышланган.

Докладны әзерләгәндә Вәкаләтле вәкилнең һәм аның Аппараты хезмәткәрләренең барлык көндәлек эшен тасвирлау максат итеп куелмады. Вәкаләтле вәкилнең эш үрнәкләре һәм проблемалары хәлләргә күзәтүе, барыннан да элек, Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен бозуны, шул исәптән, короновирус инфекциясе таралу чорында барлыкка килгән хокук бозуларны бетерү буенча системалы чаралар кирәк булган очракларда үткәрелә. Шуңа күрә доклад ахырында дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына киләчәктә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү, саклау һәм яклау максатында кайбер чараларны күрүне карарга тәкъдим ителә.

Вәкаләтле вәкилнең һәм Аппарат хезмәткәрләренең агымдагы эшендә 2020 ел бай булган әһәмиятле даталар һәм иҗтимагый-сәяси вакыйгалар игътибардан читтә калмады. Болар – Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 75 ел, ТАССР оешуга 100 ел, Россия Федерациясе Конституциясенә үзгәрешләрне хуплау мәсьәләсе буенча Россиякүләм тавыш бирү; Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар, Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутатын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын сайлау буенча өстәмә сайлаулар, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарына депутатлар сайлауларны үткәрү белән бәйле

13 сентябрьдәге Бердәм тавыш бирү көне; Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институты оешуга 20 ел.

Шулай ук 2020 елның 18 мартында дөнья күргән 48 нче «Россия Федерациясе субъектларында вәкаләтле вәкилләр турында»гы Россия Федерациясе субъектларындагы кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең кеше һәм граждан хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен дәүләт яклавын тәэмин итү буенча эшчәнлегенә бердәм таләпләрне билгеләгән федераль закон көченә керүен дә билгеләми булмый.

Доклад әзерләгәндә Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итүчеләрдән килгән шикаятьләр, Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы мәгълүматлары, дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының мәгълүматлары, шулай ук Вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре тәкъдим иткән мәгълүматлар, хокук саклау оешмаларыннан килгән яки массакүләм мәгълүмат чараларында басылган кеше хокукларын бозу турында мәгълүматларны тикшерү йомгаклары, республика ведомствоара комиссияләр материаллары һәм башка чыганаклар анализланды.

**Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүне анализлау**

Ел саен Вәкаләтле вәкил адресына килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренә, «Халык контроле» Татарстан дәүләт мәгълүмат системасы мәгълүматларына, социаль челтәрләрдә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында басылган язмаларга, яки ГЛОНАСС +112 Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы аша җибәрелгән мәгълүматларга анализ ясау, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазифаи затлары ягыннан кеше һәм гражданнар хокукларын яклау гарантияләрен көчәйтүне таләп итүче проблемалы мәсьәләләр спектрын ачыкларга мөмкинлек бирә.

2020 елда дөнья коронавирус йогышлы авыруы пандемиясе (COVID-19) – җәмәгать сәламәтлеге өлкәсендә гадәттән тыш хәлгә юлыкты, ул кыска вакыт эчендә җәмгыять тормышының барлык өлкәләрендә тирән үзгәрешләргә китерде һәм барлык дәүләт, муниципаль органнар һәм шәхси оешмалар, шул исәптән хокук саклау берләшмәләре эшенә төзәтмәләр кертте.

Шуңа да карамастан, хокук саклау эшчәнлегенә ихтыяҗ кискен артты, һәм Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил COVID-19 таралуга һәм аның нәтиҗәләренә каршы көрәш барышыннан читтә калмады.

2020 елда Татарстан Республикасында яшәүчеләр Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә үзләрен кызыксындырган мәсьәләләр буенча 5859 тапкыр мөрәҗәгать иттеләр (2019 елның шул чорында – 4713).

1нче таблица

| **Күрсәткечләр** | **Саны** |
|---|---|
| Барлыгы | 5859 |
| Шул исәптән телдән килгән мөрәҗәгать | 1508 |
| Шул исәптән язма формада һәм электрон документ рәвешендә | 2488 |
| ЕГИС ГЛОНАСС +112 | 1863 |
| «Халык контроле» системасы | 76 455 |

Узган ел кеше һәм гражданнар хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу фактлары турында мәгълүмат гражданнарның телдән һәм язма мөрәҗәгатьләреннән (3996) һәм ГЛОНАСС + 112 системасы (1863) хәбәрләреннән алынды.

Гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрнең гомуми санынннан 2 488е язмача, шул исәптән 389ы электрон почта аша җибәрелде һәм 1 027се – Вәкаләтле вәкилнең рәсми сайтының Интернет-кабул итүе, 733е почта элемтәсе

аша керде, шуларның 92се – гражданнарның күмәк мөрәҗәгате (2019 елның шул чорында – 106).

2020 елда «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында барлык статуслардан кайтарылган мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып 76 455е бастырылды, шул исәптән: 59 382 мөрәҗәгать хәл ителде – 78 %, 12 183е буенча эшләр планлаштырылды, 3 965енә сәбәбен күрсәтеп, баш тарту белдерелде, 925е – карала.

Гражданнардан мөрәҗәгатьләр актив рәвештә түбәндәге төрләр буенча килде, әйтик, «Территорияне төзекләндерү» төре буенча – 43 933 мөрәҗәгать, «Муниципаль юлларны карап тоту һәм ремонтлау» – 15 006 мөрәҗәгать, «Юл хәрәкәтен оештыру» – 7 182 мөрәҗәгать, «Тышкы рекламада закон бозулар» – 5 068, «Торак-коммуналь хезмәтләр» – 4 686, «Җәмәгать транспорты» – 3 066 мөрәҗәгать, «Сырхауханәләр һәм хастаханәләр» – 2 921 мөрәҗәгать.

2020 ел башыннан бирле «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында социаль челтәрләрдән кергән 475 мөрәҗәгать бастырылды, бу 2019 ел белән чагыштырганда 37 процентка күбрәк, шуларның 330ы хәл ителде, бу 2019 ел белән чагыштырганда 21 % ка күбрәк, 112се – планлаштырылды, 4се – эш барышында, 29 мөрәҗәгатькә, аларны үтәү мөмкинлеге булмау сәбәпле «Дәлилләнгән баш тарту» статусы бирелде.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына килгән мөрәҗәгатьләрне сыйфатлы һәм оператив үтәү максатыннан, 2020 елда ведомствоара комиссиянең бер утырышы һәм Татарстан Республикасы Вәкаләтле вәкил Аппаратында һәм муниципаль районнарында 36 эш киңәшмәсе, шул исәптән видеоконференция тәртибендә, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, Татарстан Республикасы Прокуратурасы вәкилләре, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр тирәләре башкарма комитетларының структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм җаваплы башкаручылары катнашында уздырылды, 3 674 мөрәҗәгать контрольгә алынды, бу 2019 ел белән чагыштырганда 8 процентка күбрәк булды (3401).

Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре 2020 елда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрдә күрсәтелгән объектлар буенча 450 күчмә тикшерү үткәрелде. 3 674 мөрәҗәгать Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы һәм шәһәр тирәләрендәге җаваплы башкаручыларга, аларга нигезсез башкару статуслары бирелүгә бәйле рәвештә, эшкә кире кайтарылды.

Республика территориясендә гамәлгә ашырыла торган тармак инвестиция программалары нәтиҗәсендә, автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау мәсьәләләре буенча гражданнарның – 9 518 һәм йорт яны территорияләрен

төзекләндерүгә һәм җәмәгать киңлекләрен карап тотуга кагылышлы 25 851 мөрәҗәгате уңай хәл ителде, бу 2019 ел белән чагыштырганда 8 процентка күбрәк (23 866 мөрәҗәгать).

«Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары» Илкүләм проекты кысаларында узган елда «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына килгән мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып, юл-урам челтәрләрендә 13 светофор объекты урнаштырылды.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына кергән мөрәҗәгатьләрне үтәү буенча бигрәк тә Әгерҗе (84 %), Актаныш (87 %), Әтнә (81 %), Бөгелмә (78 %), Чүпрәле (77 %), Зәй (79 %), Кама Тамагы (81 %), Лениногорск (81 %), Мамадыш (85 %), Минзәлә (89 %), Мөслим (83 %), Балык Бистәсе (89 %), Саба (87 %), Теләче (77 %), Чирмешән (79 %), Ютазы (88 %), Түбән Кама (80 %) муниципаль районнары һәм Яр Чаллы (84 %) шәһәр округы башкарма комитетларында эшнең актив алып барылуы билгеләнде.

ГЛОНАСС +112 системасы аша кергән һәм Вәкаләтле вәкил тарафыннан эшкә кабул ителгән мәгълүмати хәбәрләрнең саны 2019 елда 541 хәбәрдән 2020 елда 1863кә кадәр артты, ГЛОНАСС +112 (669) хәбәрләренең күп өлеше коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә гражданнарга ярдәм күрсәтү мәсьәләләренә кагылды.

Вәкаләтле вәкилнең әлеге хәбәрләре, чаралар күрү өчен, министрлыкларга, ведомстволарга һәм җирле үзидарә органнарына оператив рәвештә тапшырылды, яисә Россия Федерациясе территориясендә яңа коронавирус инфекциясен кертүне һәм таралуны кисәтү һәм тыю буенча Илкүләм планны гамәлгә ашыру кысасында, 2020 елның апрелендә Вәкаләтле вәкил инициативасы буенча махсус төзелгән «COVID-2019: коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау» дигән яңа төрдә «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында басылды.

Әлеге төр буенча «Халык контроле» системасында барлыгы 630 мөрәҗәгать бастырылды, шуларның 568е хәл ителде – 90 %, 16 мөрәҗәгать буенча эшләр планлаштырылды, 43е буенча дәлилләнгән баш тарту бирелде, 3 мөрәҗәгать буенча эш алып барыла.

ГЛОНАСС +112 системасына һәм «Халык контроле» системасына кергән мөрәҗәгатьләрдә республика халкы волонтерлык ярдәме күрсәтү (159 мөрәҗәгать), күп фатирлы йортларда гомуми кулланылыштагы урыннарны дезинфекцияләү (70 мөрәҗәгать), саклану чараларын үтәмәү (социаль, мәдәни-күңел ачу учреждениеләрендә, кибетләрдә, даруханәләрдә, медицина оешмаларында һәм башка учреждениеләрдә кешеләр арасында социаль дистанцияне саклау) (233 мөрәҗәгать), саклану чаралары булмау (битлек,

перчаткалар, антисептик чаралар) (18 мөрәҗәгать), sms-пропусклар алу һәм башка мәсьәләләрне күтәреп чыкты.

Әлеге төр буенча мөрәҗәгатьләр «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасының баш модераторы буларак, республикада яшәүчеләр мәнфәгатьләрендә, аларны хәл итү өчен Вәкаләтле вәкилнең махсус контролендә калды.

Күрсәтелгән төр буенча өлкән яшьтәге һәм аз тәэмин ителгән гражданнарга волонтерлык ярдәме күрсәтү турында кергән мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Казан шәһәре, Яр Чаллы шәһәре, Азнакай, Әлки, Әлмәт, Апас, Арча, Әтнә, Бөгелмә, Буа, Чүпрәле, Алабуга, Зәй, Яшел Үзән, Лаеш, Лениногорск, Менделеевск, Минзәлә, Мөслим, Түбән Кама, Нурлат, Тәтеш, Тукай, Теләче, Чирмешән, Чистай, Ютазы муниципаль районнары җирле үзидарә органнары тарафыннан мохтаҗларны азык-төлек һәм дару чаралары белән тәэмин итү буенча оператив тәртиптә эш алып барылды.

Күп фатирлы йортларда гомуми кулланылыштагы урыннарны дезинфекцияләү мәсьәләләре буенча «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы мөрәҗәгатьләре Вәкаләтле вәкил тарафыннан республиканың муниципаль районнары һәм шәһәр округларының торак идарәче компанияләренә җибәрелде. Күп фатирлы йортларда яшәүчеләрдән сораулар алган идарәче оешмалар тарафыннан тиз арада гомуми кулланылыштагы урыннарны санитар эшкәртү үткәрелде.

Вәкаләтле вәкил Аппаратына гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләр структурасы «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маенда дөнья күргән 59 нчы федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә, мөрәҗәгать итүчеләр төрләре һәм конституцион хокук төркемнәре буенча 2 нче һәм 3нче таблицаларда тәкъдим ителә.

2нче таблица

(мөрәҗәгать итүче категориясе идентификацияләнергә мөмкин булган мөрәҗәгатьләр проценты)

| **Мөрәҗәгать итүчеләр** | **2020 ел** |
|---|---|
| Пенсионер | 29,9 % |
| Инвалид | 12,2 % |
| Хөкем ителүче (шул исәптән хөкем ителүче ихтыяҗларында) | 22,9 % |
| Эшкә сәләтле кеше | 14,01 % |
| Хезмәт ветераны | 2,3 % |
| Шик астына алынучы/гаепләнүче | 4,4 % |
| Коллектив | 14,12 % |

3 нче таблица

| Конституцион хокуклар төркеме | 2020 елда барлыгы |
|---|---|
| Социаль хокуклар | 47,78 % |
| Гражданлык (шәхси) хокуклары | 34,05 % |
| Сәяси хокуклар | 17,23 % |
| Икътисадый хокуклар | 7,28 % |

Социаль хокуклар төркеме структурасында күпчелек өлешне социаль тәэминат мәсьәләләре – 42,4 %, торак хокукларын гамәлгә ашыру, торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр 28,07 % тәшкил итә.

2019 ел белән чагыштырганда хезмәт хокукларын (326 мөрәҗәгать, 2019 елда – 227) һәм сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокукны (639 мөрәҗәгать, 2019 елда – 378) бозуга бәйле мөрәҗәгатьләр саны артты. Хокук мөнәсәбәтләренең әлеге өлкәләре кысаларында проблемалы мәсьәләләр махсус бүлектә каралачак.

Гражданлык хокуклары структурасында иң күп санны – 58,1 % – гражданлык, административ һәм җинаять-суд эшчәнлеге кысаларындагы мөрәҗәгатьләр тәшкил итә, 9,58 % – гаилә мөнәсәбәтләре кысаларында мөрәҗәгатьләр (ата-аналар арасындагы бәхәсләр, үз бурычларын тиешенчә үтәмәү һ.б.) һәм 16,4% – иреккә һәм шәхси кагылгысызлыкка хокукны яклау турында мөрәҗәгатьләр.

Гомумән алганда, төрле элемтә каналлары буенча Вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрнең тематикасы соңгы елларда үзгәрешсез кала (4нче таблица).

4нче таблица

| Мөрәҗәгатьләр тематикасы | 2019 ел | | 2020 ел | |
|---|---|---|---|---|
| | Сан | % | Сан | % |
| Торак мәсьәләләре, шул исәптән торак-коммуналь хезмәте күрсәтү мәсьәләләре | 1081 | 22,94 | 678 | 11,58 |
| Суд карарлары белән ризалашмау | 300 | 6,37 | 141 | 2,40 |
| Хокук саклау органнары хезмәткәрләренә дәгъва | 295 | 6,26 | 571 | 9,75 |
| Социаль тәэминат һәм халыкны социаль яклау | 547 | 11,61 | 1024 | 17,48 |
| Кешеләрне мәҗбүри тоту урыннарында тоту шартлары | 155 | 3,29 | 171 | 2,92 |
| Хезмәт законнары | 227 | 4,81 | 326 | 5,57 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| РФ Кораллы Көчләрендә хезмәт | 33 | 0,70 | 34 | 0,58 |
| Медицина хезмәте күрсәтү | 378 | 8,01 | 639 | 10,91 |
| Мәгариф | 79 | 1,68 | 74 | 1,26 |
| Җир мәсьәләләре | 95 | 2,01 | 42 | 0,72 |
| РФ гражданлыгын кабул итү һәм паспорт бирү | 164 | 3,48 | 108 | 1,84 |
| Башкарма производство | 199 | 4,22 | 196 | 3,34 |
| Хокукый мәгълүмат бирү мәсьәләләре | 210 | 4,46 | 500 | 8,53 |
| «Халык контроле» системасы эше мәсьәләләре | 449 | 9,53 | 550 | 9,38 |
| Башка сораулар | 501 | 10,63 | 805 | 13,74 |
| Барлыгы: | 4713 | 100 | 5859 | 100 |

Вәкаләтле вәкил, шулай ук Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре тарафыннан, коронавирус инфекциясе таралуны профилактикалау белән бәйле чикләү чаралары гамәлдә булган чорда, 2020 елның 30 мартыннан 12 маена кадәр гражданнарны шәхсән кабул итү туктатылды. Шул ук вакытта, Вәкаләтле вәкил һәм Аппарат хезмәткәрләре көн саен видеоэлемтә тәртибендә гражданнарны Skype, Zoom, WhatsApp программалары яисә телефон элемтәсе аша кабул итте.

Вәкаләтле вәкил өчен видеоэлемтә тәртибендә гражданнарны кабул итү практикасы яңалык түгел. Татарстан Республикасының ерак муниципаль районнарында яки аннан читтә яшәүче гражданнарны видео аша кабул итү Вәкаләтле вәкил тарафыннан 2011 елда кертелде.

Чикләү чаралары йомшарганнан соң Вәкаләтле вәкил аппараты гражданнарны күбрәк видеоэлемтә тәртибендә кабул итүне дәвам итте.

Гомумән алганда, 2020 елда Вәкаләтле вәкил тарафыннан гражданнарны 70 тапкыр кабул итү үткәрелде, алар кысасында республиканың 639 кешесе үзләрен борчыган сораулар белән мөрәҗәгать итте. Шуларның 49ында видеоэлемтә системаларын кулланып кабул итү үткәрелде.

Вәкаләтле вәкил, вәзгыятьнең катлаулы булуына карамастан, гражданнарны бердәм кабул итү практикасын да дәвам итте.

Күрсәтелгән чорда кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (19.05.2020), Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы (16.06.2020, 08.07.2020), Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (03.03.2020, 23.06.2020, 16.12.2020), Татарстан Республика Прокуратурасы (25.02.2020, 14.07.2020, 27.11.2020, 30.12.2020), Татарстан Республикасы профсоюзлар федерациясе (30.06.2020),

Татарстан Республикасында дәүләт Хезмәт инспекциясе (11.02.2020, 30.06.2020, 18.08.2020), Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе (11.03.2020, 27.10.2020), Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (17.03.2020), Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы (20.10.2020), Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы (09.12.2020), Татарстан Республикасы буенча медико-социаль экспертизаның Баш бюросы (08.07.2020), Дәүләт учреждениесе – Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе социаль иминиятләштерү фондының төбәк бүлеге (08.07.2020), Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы (04.02.2020), Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы җитәкчелеге (03.12.2020), Чуваш Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (04.02.2020), Татарстан Республикасы медицина хезмәткәрләре берлеге президенты (04.02.2020), Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты О.И.Павлова (30.06.2020, 03.12.2020), алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты М.Ф. Сыровацкий (14.02.2020) белән бердәм тематик кабул итүләр уздырылды.

2020 елда барлыгы 27 бердәм кабул итү булды.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе, Татарстан Республикасы Прокуратурасы вәкилләре, «16нчы медико-санитар часте» ФСКУ җитәкчесе, шулай ук Татарстан Республикасы Премьер-министрының хокук саклау һәм административ эшчәнлек буенча ярдәмчесе белән берлектә Вәкаләтле вәкил тарафыннан хөкем ителүчеләрне 6 кабул итү, шул исәптән Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе 3 нче, 4 нче, 5 нче, 10 нчы, 18 нче, 19 нчы төзәтү колонияләре медицина частьләре белән тоташтырылып, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән видеоконферецэлемтә (телемедицина) системасы кулланып, 5 дистанцион кабул итү уздырылды. Алар кысаларында 56 хөкем ителүче шәхси сораулар буенча консультация ала алды.

Видеоэлемтә форматында Вәкаләтле вәкил һәм җәмәгать ярдәмчесе тарафыннан Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча идарәсенең чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту үзәгендә тотылучы затларны кабул итү уздырылды, алар кысаларында 460 тапкыр чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга хокукый консультацияләр күрсәтелде, 2020 елның февралендә бер кабул итү үткәрелде (24 кеше).

Коронавирус эпидемиясе дөньяга моңарчы күрелмәгән карантин чаралары күрүне таләп итте: чикләрне ябу, авиаэлемтәне туктату. Күп кенә ил чит ил кешеләре өчен чикләрен тулысынча япты.

Бу чорда чит илләрдә калырга мәҗбүр булган россиялеләрнең язмышы турындагы мәсьәлә кискен туды. Вәкаләтле вәкил адресына башка дәүләтләрдә: Америка Кушма Штатлары, Кытай, Тайланд, Танзания, Әзербайҗан, Кипрда вакытлыча булган татарстанлылардан 14 шундый мөрәҗәгать керде. Барлык мөрәҗәгатьләрне дә, Россия Федерациясе территориясендә яңа коронавирус инфекциясен кертү һәм таратуны кисәтү буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Оператив штабына үтенечнамә юнәлткән Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н.Москалькова ярдәме белән, гражданнарның туган якларына әйләнеп кайту хокукларын торгызып, уңай хәл итә алдык.

2020 елда Вәкаләтле вәкил һәм аның ярдәмчеләре тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен урыннарга чыгып карау максатларында, 100дән артык тикшерү чарасы үткәрелде, шул исәптән түбәндәге мәсьәләләр каралды:

• гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә (Казан шәһәренең 78 нче номерлы «Фарватер» лицее, белем бирү процессын оештыру; Казан шәһәренең «208 нче номерлы татар телендә тәрбия һәм белем бирү катнаш төрдәге балалар бакчасы», хезмәткәрнең хокукка каршы гамәлләре; Казан шәһәренең

«Советлар Союзы Герое С.А.Әхтәмов исемендәге 121нче номерлы лицей, белем алу хокукын бозу»; Алексеевск районының «Реченск төп гомуми белем бирү мәктәбе»; Казан шәһәренең «132 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы», урын бирүдән баш тарту; Биектау районының «Чебурашка» Пермяковск балалар бакчасы», ата-аналар түләве белән ризалашмау; Казан шәһәре Идел Буе районының «35нче номерлы лицее – «Галактика» белем бирү үзәге», белем алу хокукын бозу; «Советлар Союзы Герое А.С. Умеркин исемендәге 116нчы номерлы лицей», белем алу хокукын бозу; «Югары Ослан урта гомуми белем бирү мәктәбе»);

• җиһаз җитештерүне оештыру белән бәйле яшәү шартларының канәгатьләнерлек булмавы (тавышның югары дәрәҗәсе, «Авиатөзелеш районының Торак-коммуналь хуҗалыгы» идарәче компаниясе; фатирда чит исләр (Казан шәһәре, «Идел буе АДС»); торак бина торышының канәгатьләнерлек булмавы (Лаеш районы);

• торак-коммуналь хуҗалык өлкәсе эшләре: күп фатирлы йортның инженерлык челтәрләренә санкциясез тоташу («Мәскәү районы торак-коммуналь хуҗалыгы» идарәче компаниясе); түбәне сыйфатсыз ремонтлау

(«Лаеш районы ТКХ»); газ белән тәэмин итүдә өзеклекләр (Казан шәһәре, «АРТ СИТИ» җәмгыяте) һәм су белән тәэмин итүдә өзеклекләр (Казан шәһәре, «Дәрвишләр торак-коммуналь хуҗалыгы» идарәче компаниясе); торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурыч («Мәскәү районы торак-коммуналь хуҗалыгы» идарәче компаниясе);

• торак шартларын яхшырту (Биектау районы), шул исәптән инвалид бала тәрбияләүче гаиләләр (Казан шәһәре);

• балалар өчен тернәкләндерү үзәкләрендә кеше хокукларын бозу («Көч-балаларда» Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларга ярдәм хәйрия фонды, Казан шәһәре) һәм өлкәннәр (Лаеш районы);

• хезмәт законнарын бозу (клининг компаниясе);

• тимер юл аша җәяүлеләр өчен җир өсте кичүендә «Уңайлы мохит» булмау («Әмәт» Тимер юл станциясе);

• башкарма производство (Казан шәһәре);

• каты коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгаруның канәгатьләнерлек оештырылмавы (Казан шәһәренең Константиновка бистәсе, «ПЖКХ» җәмгыяте);

• хөкем ителүчегә дисциплинар җәзаны нигезсез салу һәм шикаять җибәрүдә төзәтү учреждениесе хакимияте тарафыннан тоткарлык күрсәтү (Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе 2 нче төзәтү колониясе) һәм башкалар.

Ел дәвамында хокуклар һәм ирекләр торгызу буенча мөмкин булган һәм кирәкле чараларга карата Вәкаләтле вәкилнең 20 тәкъдиме һәм кисәтүе җибәрелде. Хисап елында дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, аларның вазифаи затлары һәм оешмалары адресына башкарма производство өлкәсендә суд пристав-башкаручылары суд гамәлләре өлешендә бозылган хокукларны торгызу турында тәкъдимнәр җибәрелде (Казан шәһәренең аерым башкарма производстволары буенча суд приставларының районара бүлеге, суд приставларының Киров районы бүлеге), мәгариф өлкәсенең гомумбелем бирү һәм мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү учреждениеләре өлешендә («Югары Ослан урта гомуми белем бирү мәктәбе», Казан шәһәре Яңа Савин районының «208нче номерлы татар телендә тәрбияләү һәм укыту катнаш төрдәге балалар бакчасы», Казан шәһәренең «Фарватер» 78нче лицее»), Сәламәтлек саклау өлкәсендә («Арча үзәк район хастаханәсе» ДАССУ медико-социаль экспертиза бюросына мөрәҗәгатьтә хокукны торгызу турында), торак өлкәсендә (Биектау районы башкарма комитеты төзекләндерелгән торак бинасында яшәү хокукын торгызу турында; Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы ятим балалар арасындагы затның торак бинага мохтаҗ дип тануга хокукын торгызу

турында), торак пунктын газлаштыру, авыл җирендә яшәүче гражданнарга дәүләт ярдәме мәсьәләләре буенча.

2020 елда Вәкаләтле вәкилне конституциячел суд эшчәнлегендә катнашырга җәлеп итү практикасы дәвам итте. Узган чорда «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы законының 24 нчы маддәсе һәм 51 маддәсе өченче өлеше булеге тәртибендә Вәкаләтле вәкил торак-коммуналь хуҗалык, социаль хезмәтләр күрсәтү, сәламәтлек саклау, социаль иминият, торак өлкәсендә гражданнарның шикаятьләренә бәяләмә бирү өчен Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан 6 тапкыр җәлеп ителде.

Суд органының конституция контроле буенча әлеге инициативасы кеше һәм гражданнар хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне, яклауны һәм торгызуны тәэмин итү күзлегеннән мөһим булып тора.

Шулай ук Вәкаләтле вәкил гомуми юрисдикция судларының миграция мәсьәләләре буенча утырышларында 55 тапкыр катнашты, аларның нәтиҗәләре буенча 24 эш буенча карар чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат файдасына кабул ителде, шул исәптән:

• гражданлыгы булмаган 9 затка карата район судлары карарларын Россия Федерациясеннән административ чыгару өлешендә үтәүне туктату турында уңай карарлар кабул ителде;

• бер эш буенча Әзербайҗан гражданының өч бала атасы булуы ачыкланды, шуңа бәйле рәвештә балаларга яшәүгә рөхсәтне рәсмиләштерү мөмкинлеге туды;

• Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның хокукый хәлен җайга салу буенча вакытлы чаралар турында» 2020 елның 18 апрелендә дөнья күргән 274нче Указын үтәү йөзеннән, район судларының чит ил гражданнарын Россия Федерациясеннән читкә административ чыгару һәм вакытлыча тоту үзәгенә урнаштыру өлешендә карарлары юкка чыгарылды.

2020 елда Вәкаләтле вәкилгә юридик фирмаларның намуссыз гамәлләре белән очрашкан 6 граждан мөрәҗәгать итте, шулай ук пенсия белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча, мөрәҗәгать итүченең шәхси мәгълүматларына үзгәрешләр кертеп кенә, бердәм шаблон буенча мәгълүматлары бер юридик компания тарафыннан әзерләнгән 81 мөрәҗәгать керде.

Зыян күргән 6 кешенең һәркайсы, үз проблемаларын хәл итү өчен, юридик компаниягә мәҗбүри мөрәҗәгать итүләре, килешүдә күрсәтелгән хезмәтләрнең фактта күрсәтелмичә, 20дән алып 90 мең сумга кадәр юридик

хезмәт күрсәтүгә килешү төзелүе, һәм шул көндә үк эшләрнең үтәлүе турында нәтиҗә ясалуы турында хәбәр итте.

Гражданның телдән мөрәҗәгать итү очрагы да булган (телефон шалтыратуы), юридик компания үз имиджын ныгыту һәм клиентлар җәлеп итү өчен мөрәҗәгать итүчеләргә үз эшчәнлеген Вәкаләтле вәкил исеменнән башкаруы турында хәбәр иткән.

Вәкаләтле вәкил һәм Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре тарафыннан юридик фирмалар эшчәнлегенә кагылышлы шикаятьләр һәм гаризалар игътибар белән өйрәнелә. Гражданнарга закон нормалары аңлатылган җаваплар бирелә, я хезмәт күрсәтү турындагы килешү буенча йөкләмәләрне тиешенчә үтәмәгән очракта шикаять прокуратура органнарына җибәрелә; гражданга карата җинаять кылынган очракта, шикаятьләрнең дәлилләрен тикшерү өчен, алдан тикшерү органнарының вазифаи затларына тапшырыла.

Дәүләт органнарының җайга салынган уртак эше нәтиҗәсендә, Казан шәһәрендә урнашкан «Меридиан» җәмгыяте юридик фирмасына карата, куллнучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан, аның эшчәнлегеннән зыян күргән гражданнарның мәнфәгатьләрен яклау өчен, күмәк дәгъва гаризасы әзерләнде. Янәсе, «Меридиан» җәмгыятенең гражданнарга түләүсез консультацияләрдән килгән зыян 1,5 млн сум тәшкил иткән.

2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр тирәсендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерүгә Вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре актив ярдәм күрсәтте. Вәкаләтле вәкил кушуы буенча ярдәмчеләр тарафыннан ГЛОНАСС +112 системасыннан килгән 233 хәбәр һәм гражданнарның 114 мөрәҗәгате тикшерелде.

Узган ел җәмәгать ярдәмчеләре адресына гражданнардан 1 845 мөрәҗәгать керде. Гражданнар җәмәгать ярдәмчеләренә элеккегечә торак, шул исәптән торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү, социаль яклау һәм социаль тәэмин итү, медицина хезмәте күрсәтү, хезмәт законнары, җир һәм мәгариф мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать иттеләр. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, аларның бер өлешен урында хәл итеп була иде. Берничә мисал китерәбез.

*Түбән Кама районында яшәүче I төркем инвалид, ГЛОНАСС + 112 ашыгыч хезмәте номеры буенча коляскада йөри торган инвалидка подъездка керү юлын япкан автотранспорт чарасы хуҗасына шикаять белән мөрәҗәгать итте. Вәкаләтле вәкилнең Түбән Кама районындагы җәмәгать ярдәмчесе Т.В. Трошина әлеге мөрәҗәгать буенча инвалидның өенә барды,*

*пандус урнаштыруда ярдәм итү мәсьәләсе күтәрелде. Җәмәгать ярдәмчесе «Торак» идарәче компаниясе» директоры И.Г. Валасеевка коляскада йөри торган I төркем инвалид өчен подъездда култыклар һәм пандус урнаштыру үтенече белән мөрәҗәгать итте. Үтенеч тулысынча канәгатьләндерелде. Мөрәҗәгать итүче ярдәм күрсәткән өчен рәхмәт белдерде.*

*Вәкаләтле вәкилнең Арча районындагы җәмәгать ярдәмчесе Р.А. Һидиятовка Апайкино Гәр авылында яшәүче ханым авылдан чыгу юлында яшәүчеләргә уңайсызлыклар тудырган агач ташый торган автомобиль юлын ябу мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итте. Р.А. Һидиятов «Арча урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчелегенә мөрәҗәгатеннән соң автомобиль юлы кырыенда өелгән агач материаллары алынды һәм алга таба әлеге юл участогыннан агач материалларын ташуны алып бармау турында карар кабул ителде.*

*Вәкаләтле вәкилнең Тәтеш районындагы җәмәгать ярдәмчесе И.В. Гавчевага ташламалы дару препаратлары белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча өлкән яшьтәге бер ханымнан шалтырату булды.*

*Җәмәгать ярдәмчесе мөрәҗәгать итүче янына бу хакта җентекләп сөйләшү һәм хәлне ачыклау өчен барды. Әңгәмә барышында гариза бирүчегә даими нигездә «Ксарелто» препараты кирәклеге ачыкланды. Җәмәгать ярдәмчесе 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 20 сентябренә кадәр бушлай җибәрелгән дару чараларына рецептлар реестрын соратып алды. Анда мөрәҗәгать итүчегә дару чараларын бирү факты билгеләнмәгән. И.В. Гавчеваның «Тәтеш үзәк район хастаханәсе» баш табибы Р.Р.Салаватуллинга мөрәҗәгатеннән соң мөрәҗәгать итүчене дарулар белән тәэмин итү мәсьәләсе хәл ителде.*

*Вәкаләтле вәкилнең Әлки районындагы җәмәгать ярдәмчесе Ф.Г. Яруллинага Базарлы Матак авылында яшәүче 1924 елда туган ялгыз яшәүче күршесенең сиделка хезмәтенә мохтаҗ булуы турында хәбәр итте. Җәмәгать ярдәмчесе мөрәҗәгать итүче белән бергә Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Әлки районындагы социаль яклау бүлегенә мөрәҗәгать итте. 2020 елның 1 октябреннән өлкән яшьтәге пенсионер караучы хезмәтеннән файдалана.*

Вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре шулай ук узган елда сайлау участокларының сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен ачык булуны, шикләнелүчеләрнең һәм гаепләнүчеләрнең, Россия Федерациясе

Конституциясенә төзәтмәләрне хуплау мәсьәләсе буенча Россиякүләм тавыш бирүе һәм Татарстан Республикасы Президентын сайлау вакытында хастаханәгә салынган гражданнарның сайлау хокуклары үтәлүне, авария хәлендәге торак йортларда яшәүчеләрне күчерү өчен каралган күп фатирлы торак йортларның яшәү өчен яраклы булуны, Татарстан Республикасы муниципаль районнарында адаптив физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүне оештыру мониторингында катнашты.

## Гражданнарның сайлау хокукларын яклау

2020 ел сәяси вакыйгаларга бай булды. Бу – 25 июньнән 1 июльгә кадәр узган Россия Федерациясе Конституциясенә үзгәрешләр кертелгән үзгәрешләр буенча Россиякүләм тавыш бирү (алга таба – Россиякүләм тавыш бирү), Татарстан Президентын сайлау, 11 сентябрьдән 13 сентябрьгә кадәр тагын өч сайлау кампаниясе узды: Россия Федерация Дәүләт Думасына Түбән Кама сайлау округыннан депутат сайлау, Татарстан Дәүләт Советына депутат сайлау, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарына депутатлар сайлау булды.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе мәгълүматлары буенча, 2020 елның 1 июленә, республикада сайлаучыларның саны 2 937 257 кеше тәшкил итте.

Россия Федерациясе Конституциясенең 1 өлеше 32 нче маддәсенә һәм 2 өлеше 32 нче маддәсенә ярашлы рәвештә, Россия Федерациясе гражданнары дәүләт эшләре белән идарә итүдә турыдан туры да, үз вәкилләре аша да катнаша, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарына сайлану һәм сайлау хокукына, шулай ук референдумда катнашу хокукына ия.

Шулай итеп, сайлау хокуклары, гражданнарга турыдан туры дәүләт белән идарә итүгә мөмкинлек бирүче сәяси хокуклар системасының мөһим компоненты булып тора. Ә сайлаулар, чынлап та алар ирекле икән, җәмгыятьтә демократиянең мөһим күрсәткече булып тора. Тавыш бирүгә әзерләнү һәм үткәрү вакытында гражданнарның сайлау хокукларын тормышка ашыруны, күзәтүне, яклауны һәм торгызуны тәэмин итүгә булышлык итү, хокук бозуларны ачыклау һәм булдырмау, хокук бозулар турындагы мәгълүматны тикшерү – сайлау процессы кысаларында – Вәкаләтле вәкилнең төп бурычлары булып тора.

Ел саен, гражданнарның сайлау хокукларын саклауны күзәтү йомгаклары буенча, Вәкаләтле вәкил, язмача яки еллык Докладта әйтелгән тәкъдимнәр рәвешендә, сайлау процессын оештыручыларга киләсе елларда сайлау

системасында килеп туачак проблемаларны булдырмау буенча эчтәлекле тәкъдимнәр җибәрә.

2020 елда Вәкаләтле вәкил, Аппарат хезмәткәрләре һәм Вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре тарафыннан Россиякүләм тавыш бирү һәм сайлау, аларны үткәрү вакытында төрле чыганаклардан (дәүләт органнарыннан, матбугат чараларыннан, интернеттан, коммерциячел булмаган оешмалардан, «кайнар элемтә»ләрдән) килгән хокук бозулар турындагы мәгълүматларны анализлау үткәрелде, гражданнарның сайлау хокукларын бозулары турындагы шикаятьләр һәм мөрәҗәгатьләр каралды, тавыш бирү көнендә сайлау хокукларын саклау контрольдә тотылды.

Гражданнарның сайлау хокукларын саклау эшендә Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, республиканың дәүләт органнары һәм иҗтимагый оешмалары белән бергә эшләде.

2020 елның сайлау кампанияләренең үзенчәлекләре дә булды. Яңа короновирус инфекциясе таралу белән бәйле вәзгыять (алга таба – COVID-19) соңгы илле елда сәламәтлек саклау өлкәсендә иң җитди дөнья кризисларының берсе булды. Билгеле, COVID-19 таралу куркынычы саклану шартларында, сайлау процессын оештыру вакытында санитар-эпидемиологик иминлекне тәэмин итүгә һәм тавыш бирүдә катнашучыларның сәламәтлеген саклауга аерым игътибар бирелде.

Беренчедән, тавыш бирү вакыты халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү һәм Россиякүләм тавыш бирүдә һәм сайлауларда катнашучылар өчен уңайлы шартлар тудыру зарурлыгы уңаеннан арттырылды. Әлеге күренеш «тавыш бирүгә кадәр тавыш бирү» дигән атама алды. Әйтик, Россиякүләм тавыш бирү кысаларында россиялеләрнең игълан ителгән тавыш бирү көне – 2020 елның 1 июленә кадәр, алты көн дәвамында тавыш бирү мөмкинлеге булды.

Бу максатларда тиешле норматив хокукый актлар кабул ителде. Әйтик, Россиякүләм тавыш бирү 2020 елның 14 мартында дөнья күргән «Хакимиятне оештыруның һәм эшләтүнең кайбер мәсьәләләрен көйләүне камилләштерү турында» 1 нче номерлы федераль законның Россия Федерациясе Конституциясенә төзәтмәләр турындагы Россия Федерациясе законының 2 нче маддәсендә; Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 17 мартында дөнья күргән 188 нче «Россия Федерациясе Конституциясенә үзгәрешләрне хуплау мәсьәләсе буенча Россиякүләм тавыш бирүне билгеләү турында»гы, 2020 елның 25 мартында дөнья күргән 205 нче «Россия Федерациясе

Конституциясенә үзгәрешләрне хуплау буенча Россиякүләм тавыш бирү датасын күчерү турында»гы, 2020 елның 1 июнендә дөнья күргән 354 нче, «Россия Федерациясе Конституциясенә үзгәрешләрне хуплау мәсьәләсе буенча Россиякүләм тавыш бирү көнен билгеләү турында»гы указларында; Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе кабул иткән «Россия Федерациясе Конституциясенә үзгәрешләрне хуплау мәсьәләсе буенча Россиякүләм тавыш бирү тәртибе»ндә, РФ Үзәк сайлау комиссиясенең һәм Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең (алга таба – Роспотребнадзор) башка норматив хокукый актларында күрсәтелде.

Икенчедән, килеп туган хәлдә үткәрелгән тикшерү чаралары кысаларында, аерым игътибар, сайлау участокларында шәхси саклану һәм гигиена чаралары булуга, санитар-эпидемиягә каршы иминлекне саклау таләпләрен үтәүгә, шул исәптән, социаль дистанция саклауга, сайлау комиссияләре әгъзаларының тиешенчә киенү рәвешенә бирелде.

Сайлауларны күзәтү институтын тормышка ашыруның ил һәм чит ил тәҗрибәсе шуны күрсәтә, сайлау комиссияләрендәге ачыклык атмосферасы, сайлау участокларында күзәтүчеләрнең катнашуы җәмәгатьчелектә шактый дәрәҗәдә сайлауларның гаделлегенә ышаныч тудыра, гражданнарның сайлау процессында актив катнашуына булышлык итә.

Татарстан Республикасында сайлауларда күзәтүчеләр сыйфатында 16 меңнән җәмәгатьчелек күзәтүчесе җәлеп ителде, алар сайлау участокларын әзерләүдән алып, тавышларны санауга һәм йомгак ясауга кадәр, сайлауларның барлык этапларында барлык процедураларның ачыклыгын тәэмин итүгә чакырылган.

Беренче тапкыр төрле өлкәләрдән 100 блогер – яшь әниләр, студентлар, актив яшь кешеләр, блог өлкәсенең татар сегменты вәкилләре, иҗат, фән, мәдәният һәм спорт вәкилләре, эшмәкәрләр, иҗтимагый активистлары, тавыш бирүгә әзерләнү, тавыш бирү барышы белән үз укучыларын таныштырды. Болар барысы да тавыш бирү залларында үтте, алар моны үзләренең социаль челтәрләрендә туры эфирда күрсәтте.

Вәкаләтле вәкил белән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе арасында төзелгән килешү кысаларында Татарстан Республикасы Сайлаучылары форумын үткәрү хезмәттәшлекнең яңа формасы булды, моның төп максаты – гражданнарның хәбәрдарлыгын арттыру һәм сайлаулар турында күбрәк мәгълүмат бирү. Әлеге форум кысаларында Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н. Москалькова ике сессиядә катнашты. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил күп тапкыр форум сессияләрендә, шулай ук 2020 елның 13 сентябрендә

Бердәм тавыш бирү көненең беренче нәтиҗәләрен ясау буенча Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең туры элемтәсендә чыгыш ясады.

Вәкаләтле вәкил Аппаратында 2020 елда ике тапкыр гражданнарның сайлау хокукларын яклау буенча «кайнар элемтә» оештырылды.

29 июньнән 1 июльгә кадәр Россиякүләм тавыш бирүне оештыру һәм үткәрү чорында «кайнар элемтә»гә 147 шалтырату булды;

10 сентябрьдән 13 сентябрьгә кадәр сайлауларны оештыру һәм үткәрү чорында «кайнар элемтә»гә 174 шалтырату булды.

«Кайнар элемтә» эше кысаларында гражданнарның сайлау хокукларын бозуның җитди фактлары турында мәгълүмат килмәде. Күп сораулар аңлатуны сорауга кагылышлы иде. Шалтыратучылар яшәү урыны буенча сайлау участогы кайдалыгын сорап (66 шалтырату); сайлау вакытында булу вакытында тавыш бирүгә гариза бирмәгән очракта, ничек тавыш бирү (84 шалтырату), шулай ук алдан тавыш бирү, өйдә тавыш бирү, мобиль сайлау участогында тавыш бирү, «Мин тавыш бирдем!» браслеты бирү, COVID-19 белән авырган сайлаучыларның сайлау тәртибе белән кызыксынды, мобиль участокка яки йортка сайлаучыларга китү сәбәпле, комиссия әгъзаларының стационар сайлау участогында булмавыннан, булачак сайлаулар турында мәгълүмат бирүнең тиешенчә оештырылмавыннан, җирле депутатларны сайлаганда «Мобиль сайлаучы» системасын кулланганда чикләүләр булуыннан зарланды.

Килгән шалтыратулар буенча Вәкаләтле вәкил, аның җәмәгать ярдәмчеләре һәм Аппарат хезмәткәрләре урынга чыгып тикшерүләр үткәрде.

Тикшерү нәтиҗәләре тиз арада Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә җиткерелде, ачыкланган кимчелекләрне бетерү буенча чаралар күрергә тәкъдим ителде.

Тулаем алганда, гражданнарның сайлау хокукларын саклау, яклау һәм торгызуны тәэмин итү эшләре Татарстан республикасы Үзәк сайлау комиссиясе белән 2016 елның 13 июлендә төзелгән килешү нигезендә барлыкка килгән практикага ярашлы рәвештә тормышка ашырылды.

Әлеге килешү кысаларында гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча уртак тикшерү чаралары үткәрелде, ачыкланган хокук бозулар буенча мәгълүмат алмашу җайга салынды, республикада яшәүчеләрне хокукый агарту һәм гражданнарның сайлау хокукларын саклауга күзәтчелек, шул исәптән, сәламәтлек саклау учреждениеләрендә, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының вакытлыча тоту изоляторларында һәм муниципаль районнар һәм шәһәр округларында җинаять-башкару системасы тикшерү изоляторларында оештырылган ябык сайлау участокларында, дәвам итте.

Сайлау участокларында авыр хәрәкәтләнә торган кешеләрне уңайлы тирәлек белән тәэмин итү мәсьәләләре дә, Вәкаләтле вәкилнең ныклы

контролендә булды. Татарстан Республикасында элеккечә үк сайлау участокларының 92 проценты биналарның беренче катында урнашкан. Кызганычка каршы, 2020 ел дәвамында бу күрсәткеч артмады, шунлыктан Вәкаләтле вәкил элеккечә үк гражданнарның сайлау хокукларын тормышка ашыру максатыннан, җирле үзидарә органнарына сәламәтлекләре чикләнгән гражданнарның, шул исәптән инвалидларның сайлау хокукларын тәэмин итү юнәлтелгән практиканы дәвам итәргә кирәк дип саный, моның өчен лифтлар яки сәламәтлеге чикләнгән кешеләрне, шул исәптән инвалидларны күтәртү өчен кирәкле башка җайланмалар булмаган биналарда тавыш бирү участокларын беренче каттан югары урнаштырмаска кирәк.

Республикадагы 208 сайлау участогы элеккечә үк 2 катта урнашкан: шуларның 123е – Казанда, 56ы – Чаллыда, 13е – Әлмәттә, 10 ы – Яшел Үзәндә, 3е – Түбән Камада, 1 әр – Бөгелмә, Мамадыш һәм Минзәлә муниципаль районнарында.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, 13 сентябрьдә Бердәм тавыш бирү көне алдыннан игълан ителгән «кайнар элемтә»гә әлеге тема буенча шалтыратулар булмады (чагыштыру өчен – Россиякүләм тавыш бирү көне алдыннан «кайнар элемтә» кысаларында «уңайлы тирәлек» булмавыннан зарланып 17 кеше шалтыраткан иде). Әлеге уңай үзгәреш, 13 сентябрь сайлауларын үткәрүгә ныклап әзерләнгәндә инвалид булган гражданнарга сайлау участокларының урнашкан урыны һәм йортта гариза буенча тавыш бирү тәртибе турында персональ мәгълүмат бирү белән аңлатыла.

Ике кампания кысаларында терәк-хәрәкәт итү аппараты кимчелекләре булган сайлаучылар күпләп яшәгән урыннарда 490 сайлау участогы җиһазландырылды. Алар барысы да беренче катта урнашты, «уңайлы тирәлек» таләпләренә җавап бирде, инвалид коляскаларында хәрәкәт итүче сайлаучылар тавыш бирә алсын өчен махсус киң кабиналар белән җиһазландырылды.

Күз күреме буенча кимчелекләре булган сайлаучылар күпләп яши торган урыннарда беренче катта урнашкан 732 сайлау участогы җиһазландырылды, мөстәкыйль рәвештә тутыру өчен Брайль шрифты белән 2 815 трафарет әзерләнде.

Санитар иминлек чараларын тәэмин итү максатыннан, 2020 елда трафаретлар һәм махсус басма продукцияне әзерләү процессы барлык санитар-эпидемиологик таләпләрне һәм тәкъдимнәрне үтәп башкарылды. Басма продукция республиканың сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен махсус китапханәсенең нәшриятендә әзерләнде. Китапханә хезмәткәрләре перчатка һәм битлекләрдән эшләде, биналар җилләтелеп, йогышсызландыру чаралары белән эшкәртелде. Моннан тыш, төрелгән әзер продукция сайлау

комиссияләренә тапшырылганчы берничә тәүлек дәвамында санитар сынау узып, махсус киштәләргә урнаштырылды.

Начар ишетүче гражданнар өчен Бөтенроссия чукраклар җәмгыятенең төбәк бүлеге диспетчер хезмәтенең бердәм видеотелефон элемтәсе бердәм номеры эше оештырылды. Оператор –сурдотәрҗемәче хезмәт күрсәтте.

Күп кенә медицина оешмалары һәм җинаять-башкару системасы учреждениеләре карантинга ябылганлыктан, короновирус инфекциясе таралу шартларында Вәкаләтле вәкил аерым игътибарны тигез шартларда сайлау хокукын тәэмин итүгә юнәлтте.

Россиякүләм тавыш бирү һәм 13 сентябрьдәге сайлауларны үткәрү өчен сәламәтлек саклау учреждениеләрендә, тикшерү изоляторларында аларның хезмәткәрләреннән ябык вакытлыча сайлау участоклары оештырылды.

Вәкаләтле вәкил һәм Аппарат хезмәткәрләре үткәргән тикшерү нәтиҗәләре шуны күрсәтте, Татарстан Республикасы территориясендәге биш тикшерү изоляторында сайлау участоклары ачык иде һәм шәси саклану чаралары, участокны йогышсызландыру өчен җиһазлар һәм тавыш бирү өчен кирәкле материаллар белән тулысынча тәэмин ителгән иде.

Тикшерү изоляторлары территориясендә Россиякүләм тавыш бирүдә 1800 нән артык тикшерүгә кулга алынган кеше, 13 сентябрьдәге сайлауларда 1563 кулга алынучы катнашты.

Вәкаләтле вәкил өй арестында булган кешеләргә дә игътибарны юнәлтте. «Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе җинаять-башкару инспекциясе» филиалларында, Россиякүләм тавыш бирү вакытында өй арестында булган 237 кеше исәптә тора иде, Татарстан Республикасы Президенты сайлаулар вакытында аларның саны 274 кә җитте.

Мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән 211 тоткыннан 209 кеше сайлау хокукына ия иде, аларның 189ы Россиякүләм тавыш бирүдә катнашырга теләк белдерде, 122 граждан 13 сентябрьдәге сайлауларда тавыш бирде, аларның тавыш бирүе 1 нче төзәтү үзәгендә оештырылды.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы да Россиякүләм тавыш бирүдә Әлмәт, Бөгелмә, Алабуга, Яшел Үзән, Лениногорск, Түбән Кама, Норлат, Чистай, Казан шәһәрләрендә һәм Биектауда, үз карамагындагы медицина оешмаларындагы сайлаучылар вакытлыча була торган 33 участок сайлау комиссиясендә тавыш бирү өчен барлык шартлар тудырды.

13 сентябрьдәге сайлауларда республиканың медицина учреждениеләрендә 41 ябык участок оештырылды.

«Академик В.М. Бехтерев исемендәге республика клиник психиатрия хастаханәсе»ндә Россиякүләм тавыш бирүдә катнашу хокукына 350 кеше, 13 сентябрьдәге сайлауларда хастаханәдә булган 1496 кешедән, 554 пациент

ия иде. Хастаханә территориясендә ике ябык сайлау участогы эше оештырылган иде.

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Интенсив күзәтү белән махсуслашкан типтагы Казан психиатрия хастаханәсе» учреждениесе территориясендә Россиякүләм тавыш бирү вакытында 666 кеше тавыш бирү хокукына иде, Татарстан Республикасы Президентын сайлау вакытында андыйларның саны 659 кеше иде, аларның барысына да сайлау хокукы бирелде.

Вәкаләтле вәкилнең һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең уртак эше мәсьәләләре, берничә тапкыр «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм мәгълүмат чаралары республика агентлыгы базасында Россиякүләм тавыш бирү һәм 13 сентябрьдәге сайлаулар барышын яктыртучы массакүләм мәгълүмат чаралары өчен Бердәм мәгълүмат үзәгендәге матбугат очрашулары кысаларында, тикшерү предметы булды, шулай ук сайлау процессы торышы һәм үсеш перспективаларын тикшерү сайлаучылар, иҗтимагый һәм сәяси оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары, фәнни-эксперт җәмгыяте вәкилләре, волонтерлык хәрәкәте активистлары өчен үзарә эш мәйданчыгы булган «Минем тавыш» сайлаучылар форумында булды.

2021 елның көзендә 19 сентябрьдә, Россия территориясендә Бердәм тавыш бирү көнендә, гражданнар сигезенче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль җыены Дәүләт Думасы депутатларын сайлаячаклар, шул уңайдан Вәкаләтле вәкил Аппараты Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына, «Минем тавыш» Татарстан сайлаучылары форумы сессияләре кысаларында, гражданнарның сайлау хокукларын саклау һәм яшь сайлаучылар белән эшләү буенча уртак эшне дәвам итү тәкъдиме белән мөрәҗәгать итә.

**Вәкаләтле вәкилнең кешенең социаль хокукларын яклау буенча эшчәнлеге**

Кешенең социаль хокукларын дәүләт яклавын тәэмин итү – Вәкаләтле вәкилнең төп эш юнәлешләренең берсе. Хезмәт мөнәсәбәтләренә, гаилә, ата-ананы, баланы яклау, социаль тәэминатны күздә тоткан социаль яклау, сәламәтлек саклауга, медицина ярдәменә хокукларны яклауны тәэмин итү, торакка хокукны тәэмин итү, уңайлы әйләнә-тирә мохитка, белемгә хокукны тәэмин итүгә кагылышлы шикаятьләр, Вәкаләтле вәкил Аппаратына килгән мөрәҗәгатьләрнең яртысыннан артыгын тәшкил итә.

Кешенең социаль хокукларын яклауга (барыннан да элек, уңайлы әйләнә-тирә мохитка хокук) эшчәнлекне без «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына килгән мөрәҗәгатьләрне күзәтү аша да алып бардык. Дәүләт органнары статистика мәгълүматлары, иҗтимагый оешмалар белешмәләре, массакүләм мәгълүмат чаралары язмалары да читтә калмады.

Хәзерге шартларда кешенең социаль хокукларының аерылгысыз өлеше булып хезмәт хокуклары тора. Соңгы елларда хезмәт хокукларына гарантияне арттыру, минималь хезмәт хакы дәрәҗәсен яшәү минимумы дәрәҗәсенә кадәр күтәрү, хезмәткәргә эш хакы һәм тиешле башка суммаларны түләү буенча эш бирүче бурычын мәҗбүри башкару механизмын җиңеләйтү, хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне саклау дәрәҗәсен күтәрү (хезмәт кнәгәләрен электрон рәвештә алып бару) буенча эзлекле сәясәт аша алып барылды.

Вәкаләтле вәкилнең хокук саклау практикасын күзәтүгә карасак, барлык дәрәҗәдәге хакимият органнары өчен хезмәткә кеше хокукларын тәэмин итүдә һәм яклауда яңа короновирус инфекциясе таралу зур сынау булуын билгеләми ярамый.

Кызганычка каршы, 2020 елда, илдәге кебек үк республикада да, үз хезмәте өчен лаеклы хезмәт хакы алуга кеше хокукларын тәэмин итүнең тискәре күренешләре барлыкка килде. Аерым алганда, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларын анализлау шуны күрсәтте, 2020 елның май аенда 2019 ел ахыры белән чагыштырганда, эш бирүче башлангычы белән тулы булмаган эш көне(смена) һәм (яки) тулы булмаган эш атнасы эшләүче, яки эш бирүче гаебе белән тик торучы, яки хезмәт хакын сакламыйча чираттагы ялда булучы татарстанлылар саны ун тапкыр диярлек артты. Әйтик, статистика мәгълүматлары буенча 2019 елның 25 декабренә тулы булмаган эштә эшләүче 5 086 кеше булса, 2020 елның 6 маена бу сан 40 646 тәшкил иткән. Аннан соңгы айларда, шул ук мәгълүматлар буенча вәзгыять яхшыра башлаган (әйтик,

2020 елның 2 декабренә тулы булмаган эштә эшләүче 22050 кеше булган), ләкин мәгълүматлардан күренгәнчә, узган елгы күрсәткечләргә җитмәгән.

Халыкара хезмәт оешмасы ысулы белән исәпләгәндә республикада гомуми эшсезлек дәрәҗәсе 3,8 процент тәшкил иткән (2019 елда – 3,3 %).

Шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт Хезмәт инспекциясе мәгълүматларына караганда, хезмәт хакы буенча бурыч түләтү катлаулы булып калган. 2020 елның унбер аенда, хисап көненә (һәр айның беренче көне) хезмәт хакы буенча бурыч күләме 226839,01 мең сумнан 305084,8 мең сум арасында булган, ә оешмалар саны 81 дән 159 га җиткән (дөрес, соңгы айларда бурыч күләме һәм бурычлы оешмалар саны кимү күзәтелә).

Россия Федерациясе Президентының эшләмәгән көннәргә кагылышлы 2020 елның 25 мартында дөнья күргән 206 нчы, 2020 елның 2 апрелендә дөнья күргән 239 нчы, 2020 елның 28 апрелендә дөнья күргән 294 нче боерыкларын билгеләү чорында, 2020 елның апрелендә безнең адреска килгән мөрәҗәгатьләрнең күбесе бу көннәрдә хезмәт хакы түләү мәсьәләләрен аңлатуга кагылышлы иде.

Тулаем алганда, Вәкаләтле вәкил хезмәт мөнәсәбәтләре уңаеннан хезмәт хакы күләмен яисә башка түләүләрне үз вакытында алуга аларның хокукы бозылуга гражданнар шикаятьләренә колак салып, андый шикаятьләр уңаеннан тикшерүләр уздыруны сорап, контроль-күзәтчелек органнарына гына мөрәҗәгать итеп калмыйча, хокук бозуларга юл куйган оешмалар җитәкчеләренә, аларны бетерү уңаеннан үз позициясен белдерде. Әлеге чара, хезмәт хокукларын бозу сәбәпләре түләүгә акча юклыктан түгел, ә хезмәткә хокук нормаларын ялгыш аңлау очракларында кулланылды.

Әйтик, Вәкаләтле вәкил фикеренчә, 2020 елның ноябрь башында Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән хезмәткәрнең хезмәт хокуклары бозылган, аңа Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 180 нче маддәсе өченче өлешендә билгеләнгән, оешманы юкка чыгару белән бәйле вакытыннан алда эштән киткән өчен өстәмә компенсация түләнмәгән. Акчалата компенсация түләмәүне хезмәткәр белән хезмәт килешүен өзү турындагы боерык вәкаләте булмаган зат (ул вакытта оешма җитәкчесе вазифасын башкаручы) тарафыннан имзаланган булуы, соңрак гамәлдән чыгарылуы белән аңлатылган. Моннан тыш, юридик зат исеменнән ышаныч кәгазеннән башка эшләү хокукы булган башка зат турында мәгълүматлар юридик затларның Бердәм дәүләт реестрына хезмәт килешүен өзү турында боерык басылгач кына кертелгән. Эштән китү турындагы боерыктан соң тиешле язу аңа бирелгән хезмәт кенәгәсенә язылган, ул икенче эшкә урнашкан булган. Әлеге хәлне исәпкә алып, Вәкаләтле вәкилнең хокукый позициясе хезмәткәр белән хезмәт килешүен өзү турында боерык чыгуга, эштән китү турында хезмәт кенәгәсенә язуга (алып бару

һәм саклау эш бирүченең бурычы булып тора) һәм аны хезмәткәргә бирүгә нигезләнде, ә хезмәт кнәгәсен бирү фактта хезмәткәр белән хезмәт килешүен өзүне аңлата.

Кайбер очракларда Вәкаләтле вәкил гражданнарның хезмәт хокукларын тәэмин итү өчен тикшерү органнарына мөрәҗәгать итте. Андый мөрәҗәгатьләрнең төп сәбәпләреннән берсе, эш бирүче элеккеге хезмәткәрләренә тулы күләмдә хезмәт хакы түләмәгән, үзенең факттагы адресын үзгәрткән, салым органына юридик затларның Бердәм реестры белешмәләренә үзгәрешләр кертү турында гариза белән мөрәҗәгать итмәгән хәл тора. Шул ук вакытта әлеге эш бирүчегә карата бөлгенлеккә чыгару процедурасы алып барылмаган.

«Фактор» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең элеккеге хезмәткәрләреннән хезмәт хакын тулысынча түләмәүгә, шулай ук эштән киткәндә түләнергә тиешле түләүләрне бирмәүгә кагылышлы шикаятьләр беренче елын гына килми. Әйтик, Вәкаләтле вәкил тикшерү комитетына мөрәҗәгать иткәннән соң, күрсәтелгән оешманың элеккеге хезмәткәренә ниһаять, тулы күләмдә хезмәт хакы түләү мисалы узган елгы еллык докладта сурәтләнгән иде. Быел Вәкаләтле вәкил, аңа 2020 елның декабренә мөрәҗәгать иткән оешманың башка элеккеге хезмәткәрләре хезмәт хокуклары бозылу турындагы шикаятьләр хакындагы мәгълүматны алдан тикшерү органына җибәрде.

Докладта конкрет хуҗалык итүче субъект мисалына тукталып, шуны билгеләргә кирәк, 2020 елда «Фактор» җәмгыятенә теркәүче орган оешма турында дөрес булмаган мәгълүматлар керткәнлектән, аны бердәм реестрдан (ЕГРЮЛ) чыгару турында карар кабул итте. Шуның белән бергә, Вәкаләтле вәкил фикеренчә, күрсәтелгән сәбәп буенча аның исеменнән эш итүче яки аның гамәлләрен билгеләүче затларны, юридик затны бердәм реестрдан (ЕГРЮЛ) чыгару, хезмәт хакы түләү буенча җаваплылыктан азат итмәскә тиеш.

Үз хезмәтенә хезмәт хакы алуга хокуктан тыш, гражданнарның хезмәт хокукларын саклауның аерылгысыз бер билгесе булып, халыкны эшле итүнең нәтиҗәле сәясәте тора. Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2020 елда төрле мәсьәләләр буенча мәшгульлек хезмәте органнарына мөрәҗәгать итүче гражданнар сизелерлек арткан. Әйтик, 2019 елда барлык сораулар буенча мәшгульлек үзәкләренә 194,7 мең кеше мөрәҗәгать иткән, 32,6 мең кеше эшкә урнаштырылган, шуларның 25,2 меңе – эше булмаган гражданнар, 2020 елның 9 аена да шундый ук күрсәткечләргә ирешелгән. Тугыз айда эш эзләүче буларак исәпкә алынган гражданнар саны ике тапкырга арткан (2019 елда – 63,1 мең кеше, 2020 елның 9 аенда – 132,3 мең

кеше). 2020 елның 1 декабренә теркәлгән эшсезлек 1,89 процент тәшкил иткән, 2020 елның 1 гыйнварына бу күрсәткеч 0,54 процент булган.

Күрсәтелгән мәгълүматлар халыкны эшле итүгә булышуда, барыннан да элек, гражданнарга кирәкле эшне эзләү һәм өстәмә һөнәри белем алу, һөнәри белемне арттыру, гражданнарга үзләренә ошаган эш(һөнәр) сайлауда булышу максатларында, гражданнарның һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдә дәүләт хакимияте органнарының роле артуын дәлилли. Моннан тыш, короновирус пандемиясе гражданнарны эшсез сыйфатында теркәүдә һәм социаль түләүләр буенча вакытлы кагыйдәләр билгеләүне исәпкә алып, халыкны эшле итүгә булышу өлкәсендә дә законга сизелерлек үзгәрешләр кертте.

2020 елда 40,8 мең кеше эшсезлек буенча максималь күләмдә пособие алды (12130 сум), балигъ булмаган балалары булган эшсезләргә һәр бала өчен 3000 сум исәбеннән 80,3 мең балага акча түләнде, 2020 елның 1 мартыннан эшсез дип танылган һәм эшкә хокукын югалткан 41,3 мең кешегә эшсезлек буенча пособие озынайтылды, 2020 елның 1 мартыннан соң эшчәнлеген туктаткан 808 шәхси эшмәкәр 12130 сум күләмендә эшсезлек буенча пособие алды, эшсезлек буенча минималь күләмдәге пособие 49,6 мең кешегә түләнде.

Статистика мәгълүматларын, закондагы үзгәрешләрне исәпкә алып, гражданнарның хезмәткә һәм эшсезлектән социаль яклауга хокукларын тәэмин итү белән бәйле теләсә кайсы мәгълүмат ныклы игътибарга алынды. Нәтиҗәдә без компетентлы органнарның игътибарын гражданнарны эшкә урнаштыру, аларның һөнәри белем бирүгә хокукын тормышка ашыру, эшсезлек буенча пособие түләү белән бәйле теге яки бу чараларны кабул итәргә кирәклегенә юнәлттек.

Әйтик, 2020 елның апрелендә Вәкаләтле вәкилгә яңа короновирус инфекциясе таралуны булдырмау буенча чаралар кабул ителгәнлектән уку туктатылу чорында, мәшгульлек хезмәтләре органнары юлламасы буенча һөнәри белем алу һәм өстәмә белем алу уңаеннан стипендия түләү мәсьәләсе буенча гражданнардан күп мөрәҗәгать керде, федераль закон положениеләрен исәпкә алып, аларга уку чорында стипендия түләнмәгән. Массакүләм мәгълүмат чаралары язмаларын анализлау, әлеге мәсьәләне хәл итүдә гражданнарның шактый өлеше кызыксынуын күрсәтте.

Килеп туган хәлне исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына 2020 елның апрелендә билгеләнгән чикләү чаралары нәтиҗәсендә, укуны туктату чорында үз теләкләре белән мәгариф оешмаларыннан киткән гражданнарга эшсезлек буенча пособие түләүләрне яңарту сроклары белән бәйле тәкъдимнәрен җибәрде, мәгариф оешмалары эшләрен яңарткач мәшгульлек үзәкләре

юлламасы буенча аларны алга таба укыту мөмкинлеген карарга кушты. Күрсәтелгән министрлыктан килгән җавапка караганда, тәкъдимнәр исәпкә алынган.

Эшсезлектән яклауга хокук индикаторы итеп аның дәрәҗәсен генә түгел, конкрет кешенең эшсезлек чоры дәвамлылыгын да әйтергә була. Узган елгы нәтиҗәләр буенча, уртача эшсезлек озынлыгы 1,81 айдан 4,8 айга кадәр дәвам итте. Гадәттәгечә инвалидлар арасында эшсезлек чоры озынлыгы уртача республика күрсәткеченнән югарырак, 3,88 айдан 5,63 айга кадәр, бу чираттагы тапкыр әлеге төркем вәкилләренең хезмәт базарында йомшак яклануын күрсәтә. Үз чиратында, Вәкаләтле вәкилгә мәшгульлек хезмәте органнарында алты айдан артык эшсез буларак исәптә торучы гражданнардан мөрәҗәгатьләр килү дәвам итә, алар эшкә урнаштыруда яки эш табуда булышуда яисә һөнәри белем алуга булышуда ярдәм итмәүләреннән зарлана.

Мөрәҗәгатьләрне карап, мәшгульлек үзәкләренә эш эзләүче буларак озак вакыт исәптә торучы эшсез гражданга эшкә юллама бирүгә, һөнәри белем алу һәм эшсез гражданнарга өстәмә белем бирү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү тәртибенә кагылышлы тәкъдимнәр һәм кисәтүләр җибәрелде. Гражданнарның андый мөрәҗәгатьләрен анализлап, халыкны эшле итүгә булышу өлкәсендә дәүләт хезмәтләре уңайлылыгын һәм сыйфатын күтәрү максатларында, Вәкаләтле вәкил мәшгульлек үзәкләренә түбәндәге тәкъдимнәрне җиткерүне максатка ярашлы дип саный:

мөрәҗәгать иткән вакытка вакантлы урын тулганлыктан, эшкә алганда элек мәшгульлек хезмәте органнары биргән юллама буенча берничә тапкыр эшкә алудан баш тарткан эшсез гражданнарны эшкә урнаштыру буенча чаралар күрергә (урыннар турында мәгълүмат алу белән кичекмәстән бу хакта эшсезгә хәбәр итәргә, шул исәптән, телефон элемтәсе аша); эшсез кешегә кабаттан аерым һөнәр (белгечлек) яки вазифа) буенча кирәкле хезмәткәрләрне җыю өчен мәшгульлек хезмәте органына мөрәҗәгать иткән эш бирүчеләргә үз персональ мәгълүматларын тапшырырга ризалык бирергә тәкъдим итәргә;

мәшгульлек хезмәте органы рәсми сайтына эшсез гражданнарны һөнәргә өйрәтү курсларына җыю турында мәгълүмат урнаштырганда, гаризалар кабул итү турында белешмәне дә кертергә.

Тулаем алганда, Вәкаләтле вәкилнең мөстәкыйль тикшерүләре нәтиҗәләре һәм аның кушуы буенча компетентлы органнар тикшерүләре нәтиҗәләре буенча, шулай ук хезмәт килешүләрендә законсыз үзгәрешләр, хезмәт нормасы буенча таләпләр үтәлмәве турында, дисциплинар җәза куллану тәртибен сакламау турында (Казан, Алексеевск районы) шулай ук кимчелекләр ачыкланды һәм аларны бетерү буенча чаралар күрелде.

Гражданнарның хезмәткә хокукларын саклау һәм яклау мәсьәләләре буенча төрле юнәлешләрдәге үзара хезмәттәшлек ел дәвамында прокуратура, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт Хезмәт инспекциясе, Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты, җирле үзидарә органнары, профсоюз органнары белән берлектә алып барылды.

Дәүләт социаль сәясәтенең төп юнәлешләренең берсе – гаиләләрне яклау өчен һәм халыкның мохтаҗ катлавы өчен дәүләт пособиеләре (башка түләүләр) һәм социаль яклауның башка гарантияләре билгеләү. Пандемия уңаеннан дәүләт яклавының өстәмә чаралары эшен югалткан кешеләргә дә, тәрбиясендә балигъ булмаган балалар яки башка эшкә сәләтсез туганнары булганнарга да зур ярдәм булды.

Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, Татарстан Республикасы территориясендә социаль яклау чаралары алучылар 1,48 миллион кешегә җитте. 2020 елның 11 аенда гомуми мөрәҗәгать итүчеләр – социаль яклау чаралары алучылар саныннан 87 проценты (1 212 554 кеше) хезмәтне электрон рәвештә алган, бу социаль яклау органнарындагы чиратлардан качарга булышкан.

779,4 мең гражданга социаль яклау чаралары автомат рәвештә озайтылган.

Күрсәтелгән статистика мәгълүматлары фонында, Вәкаләтле вәкил, норматив актлар белән каралган акчалата социаль яклау чаралары алуга хокуклар бозылу турында гражданнардан һәм иҗтимагый оешмалардан мөрәҗәгатьләрне даими алып торды. Аларны карап, Вәкаләтле вәкил конкрет гражданнарның бозылган хокукларын торгызу буенча чаралар гына түгел, социаль түләүләр белән бәйле хокукый мөнәсәбәтләр буенча хокукый куллану практикасын үзгәртүгә юнәлтелгән чаралар да күрде.

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 20 мартында дөнья күргән 199 нчы боерыгына ярашлы рәвештә, балалары булган (билгеле бер кереме һәм мөлкәте булган) гаиләләргә өч яшьтән җиде яшькәчә бала өчен айлык акчалата түләү билгеләнде, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда Татарстан территориясендә күрсәтелгән яшьтәге 53 266 балага әлеге түләү билгеләнгән. Үз чиратында айлык түләү билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү очраклары исемлеге Россия Федерациясе субъекты норматив актлары белән билгеләнергә мөмкин.

Татарстан Республикасы территориясендә айлык түләүне билгеләүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 апрелендә дөнья күргән 267 нче карары

белән билгеләнгән, һәм шундый нигезләрнең берсе – алучы гаиләнең балигъ булган әгъзаларының кереме булмау.

Вәкаләтле вәкилгә югарыда күрсәтелгән сәбәп буенча айлык түләү билгеләүдән баш тартулары турында гражданнардан шикаятьләр килде, шул ук вакытта гаиләнең, социаль яклау органнары фикеренчә, кереме булмаган балигъ булган әгъзасы инвалид баланы яисә балачактан беренче төркем инвалидны караган, һәм Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 26 февралендә дөнья күргән 175 нче боерыгы нигезендә аңа тиешле айлык түләү билгеләнгән.

Вәкаләтле вәкил фикеренчә, Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 20 мартында дөнья күргән 199 нчы боерыгына ярашлы рәвештә, инвалид бала яисә балачактан беренче төркем инвалид караган (шунлыктан эшли алмаган) гражданнар өч яшьтән җиде яшькәчә бала өчен тиешле айлык акчалата түләү алучылар исемлегеннән чыгарылмый. Вәкаләтле вәкилнең прокуратура органнарына мөрәҗәгате нәтиҗәсендә, безгә мөрәҗәгать итүчеләргә айлык түләүләр бирелде. Объективлык өчен шунысын да әйтергә кирәк, республиканың хакимият органнары да проблемага нык игътибар бирде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 апрелендә дөнья күргән 267 нче карарына үзгәрешләр кертелде.

Узган елда өч яшьтән җиде яшькәчә балага айлык түләү билгеләүгә хокукы танылмаган гаиләнең бер яки берничә әгъзасына (эшләмәүче эшкә сәләтле гражданнарга) беренче төркем инвалид караган (балачактан инвалидтан тыш) яисә дәвалау учреждениесе заключениесе буенча читләр ярдәменә мохтаҗ өлкән кешене яисә 80 яше тулган кешене караган өчен Россия федерациясе Президентының 2006 елның 26 декабрендә дөнья күргән 1455 нче боерыгына ярашлы рәвештә айлык компенсация билгеләнде. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгында аңлатуларынча, эшкә сәләтсез гражданны караган зат, бала өчен тиешле түләүләрне алу өчен, гражданнан тиешле түләү алганнан соң, 3-НДФЛ формасында салым декларациясе тапшырырга тиеш.

Вәкаләтле вәкил фикеренчә, килеп туган хәлдә, мондый төр керемнән салым алынырга тиеш түгел (әлеге төр керем алу белән бәйле салым декларациясе бирү өчен нигез юк). Моннан тыш, законда пенсиясенә компенсация түләүләре өстәлгән эшсез граждан компенсация түләвен аны караган кешегә тапшырырга тиешлеге билгеләнмәгән. Шул ук вакытта Россия Федерациясе Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә ярашлы рәвештә, һәр кеше аңа түләнә торган эш яки эшкә сәләтсез гражданны карауны сайлый ала. Әлеге уңайдан, Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләре, Россия Федерациясе

Салым кодексы һәм башка норматив хокукый актларга сылтама белән, Вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В.Песошинга, тәкъдимнәрен әйтеп, хат җибәрде. Анда Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 апрелендә дөнья күргән 267 нче карары белән расланган, өч яшьтән җиде яшькәчә бала өчен айлык акчалата түләү бирү тәртибе һәм шартларына үзгәрешләр кертүне караган, аерым алганда, беренче төркем инвалид караган яисә дәвалау учреждениесе бәяләмәсе буенча читләр ярдәменә мохтаҗ өлкән кешене яисә 80 яше тулган кешене караган кешеләргә, аларның керемнәре булмаган очракта өч яшьтән җиде яшькәчә балага айлык акчалата түләү алуга хокук бирүгә кагылышлы карар проекты эшләп, ведомствоара килешүгә җибәрергә тәкъдим ителде (доклад текстын язганда әлеге тәкъдим Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында карала иде).

Узган елда 2017 елның 28 декабрендә дөнья күргән 418 нче «Балалары булган гаиләләргә айлык түләүләр турында»гы федераль законда билгеләнгән беренче бала туу (уллыкка алу) уңаеннан айлык түләү алуга гражданнар хокукларын тормышка ашыруда билгесезлек бетерелде, бу баланың анасы аерым яшәгәнлектән баланың атасы кереме турында мәгълүмат бирә алмаган очраклар (күрсәтелгән законга ярашлы рәвештә, айлык түләү алу гаиләнең җан башына уртача кереме күләме белән бәйле).

Вәкаләтле вәкил элек тә булган бу проблемага, ире белән аерылышкан һәм баласына айлык түләү билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән хатын-кызның үз керемнәре турында гына түгел, баланың атасы булган элеккеге ире керемнәре турында да, хәтта аның кайдагы билгесез булган очракларда да, мәгълүмат бирергә тиеш, дигән хәбәрләр алгач нык игътибар бирде. Мондый ирдән ничек итеп 2-НДФЛ белешмәсе таләп итеп була, монысы табышмак булып калды.

Күрсәтелгән проблеманы республикада гына хәл итеп булмый иде. Шуңа күрә без, үз ягыбыздан, әлеге проблемага Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н.Москалькова белән Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы игътибарын юнәлттек. Россия Хезмәт министрлыгының 2020 елның 24 мартында дөнья күргән 151н номерлы боерыгы белән расланган, беренче бала туу (уллыкка алу) сәбәпле айлык түләү билгеләү һәм тормышка ашыру буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен субъектларның башкарма хакимияте органнары һәм Байконур шәһәре хакимияте тарафыннан тормышка ашыру буенча методик күрсәтмәләрдә, гаилә составында никахта тормаган һәм бала белән бергә яшәмәгән ир исәпкә алынмый, дип күрсәтелгән. Соңрак, 2020 елның 24 апреленнән, 418 нче

федераль законга беренче бала тугач (уллыкка алгач) айлык түләү билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән гражданнан элеккеге иренең кереме турында белешмәләр таләп итмәгән үзгәрешләр кертелде.

Социаль түләүләр өлкәсендә системалы проблемалардан тыш, Вәкаләтле вәкилгә короновирус инфекциясе таралу сәбәпле кертелгән закондагы үзгәрешләрне вазифадагы затлар исәпкә алмавы аркасында гражданнарның хокуклары бозылу очракларын да тикшерергә туры килде.

2020 елның июнь башында Вәкаләтле вәкилгә пенсия органыннан зарланып Мамадыш районында яшәүче мөрәҗәгать итте, аңа 20 яше тулгач паспорт алыштырмаган дип, эшкә яраксыз гражданны караган өчен тиешле компенсацияне түләмәгәннәр. Мөрәҗәгать итүчегә 20 яшь 2020 елның май аенда тулуын исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил Пенсия фондының Мамадыш районындагы идарәсе игътибарын.

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 18 апрелендә дөнья күргән 275 нче боерыгы положениесенә юнәлтте, аңа ярашлы рәвештә, Россия Федерациясе территориясендә 2020 елның 1 февраленнән һәм 15 июльгә кадәрге чорда, файдалану вакыты чыккан яки чыгачак Россия Федерациясе гражданы шәхесен танучы Россия Федерациясе гражданы паспорты һәм Россиянең машина йөртү таныклыгы гамәлдә булуы танылган. Пенсия органы Вәкаләтле вәкил позициясе белән килеште һәм мөрәҗәгать итүчегә компенсация түләүләре озайтылды.

Вәкаләтле вәкил фикеренчә, дәүләт яклавы чаралары рәвешендә керемнәр алучы затларның социаль яклауга һәм саклауга хокукларын тәэмин итү буенча проблемалары башкару производствосы белән бәйле мөнәсәбәтләрдә дә бар.

Суд карарын тулысынча үтәү – гражданның гадел суд карарына хокукының аерылгысыз өлеше.

Асылда Вәкаләтле вәкил социаль әһәмиятле категорияләрнең башкару эше буенча бурычлы-гражданнар шикаятьләре буенча Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә бер генә тапкыр мөрәҗәгать итмәде, алар нәтиҗәсендә ведомство контроле тәртибендә суд приставлары-башкаручыларына башкару эшләрен активлаштыру буенча йөкләмәләр бирелде. Шул ук вакытта узган елда Вәкаләтле вәкилнең Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе җитәкчесе белән бергәләп халыкны кабул итүе артты, өч тапкыр бергәләп кабул итү вакытында 55 кеше мөрәҗәгать итте.

Бер үк вакытта бурычлы гражданнар хокукларына кагылышлы кайбер проблемаларны да әйтми булмый. Россия Федерациясе Конституция суды, башкарма документны үтәгәндә бурычлының эш хакыннан яки башка керемнәреннән конкрет акча тотып калганда, әлеге эшнең барлык хәлне исәпкә

алырга, башкару эшенең гражданның намусын һәм бурычлы граждан, аның гаиләсе өчен кирәкле милекнең кагылсызлыгы кебек принципларның үтәлергә тиешлеген берничә тапкыр күрсәтте.

2020 елның 1 июненнән 2019 елның 21 февралендә чыккан «Башкарма эш турында»гы федераль законга үзгәрешләр кертү турында»гы башкарма эштә бурычлы граждан хокукларын яклауга юнәлтелгән 12 нче федераль закон көченә керде. Күрсәтелгән көннән гражданга эш хакы яки башка керем түләүче затлар, исәп-хисап документында башкарма документ буенча алына торган сумманы күрсәтергә бурычлы. Әгәр бу түләүләргә карата чикләүләр билгеләнсә һәм алардан акча алып булмаса, алар исәп-хисап документларында керем төренең тиешле кодын куярга тиеш. Әлеге белешмәләр нигезендә банк (яисә бурычлының исәп-хисап счетларына хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы башка кредит оешмасы) аларны тотып калу өчен исәп-хисап счетларына кертмәскә бурычлы.

Законда үзгәрешләр булуга карамастан, без тотылган акча суммасыннан максималь рөхсәт ителгән күләмдә суд приставы-башкаручысы карары нигезендә кредит оешмасының акча алып калуы фактларын да ачыкладык. Шулай ук гамәлдәге закон нигезендә акча алу ярамаган түләүдән акча алып калу фактлары булды.

Вәкаләтле вәкилгә башкару эше буенча бурычлы булган Чаллыда яшәүче пенсионер мөрәҗәгать итте. Пенсия органы аның пенсиясеннән 50 процентка кадәр акчасын тотып калган, шул ук вакытта банк өстәмә рәвештә пенсия исәпләнә торган исәп-хисап счетыннан акчасын алган. Нәтиҗәдә барлык тотып калулардан соң бу төр керем буенча 2 мең сум акчасы калган.

Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе белән бергәләп эшләү нәтиҗәсендә гамәлдәге законны бозу бетерелде, суд приставы-башкаручының акчага арест салынуы турындагы карары юкка чыгарылды.

Казанда яшәүче Вәкаләтле вәкилгә Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 7 апрелендә дөнья күргән «Балалары булган гаиләләрне социаль яклауның өстәмә чаралары турында»гы 249 нчы боерыгына ярашлы рәвештә түләнгән (2007 елның 2 октябрендә дөнья күргән 229 нчы «Башкару производствосы турында»гы федераль законның 101 маддәсенә ярашлы рәвештә, мондый керем төреннән бурыч алынырга тиеш түгел) 10 000 сум күләмендәге бер тапкыр түләнә торган акчаны башкару производствосы вакытында аның исәп-хисап счетыннан алып калулары турында мөрәҗәгать итте. Вәкаләтле вәкил башлангычы буенча, гамәлдәге законны бозу бетерелде, алынган акча мөрәҗәгать итүченең исәп-хисап счетына кире кайтарылды.

Күрсәтелгән мисаллар бер генә түгел. Гамәлдәге хокукый механизм мондый хәлләрне булдырмауны күздә тота, ләкин мондый хокук бозулар очравы, болар системалы булырга мөмкин дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Бу уңайдан Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенә Россия Федерациясе Үзәк банкы Идел-Нокрәт баш идарәсенең Татарстан Республикасындагы Милли банкы белән берлектә, 229 нчы федераль законның 70 нче маддәсе 4.1, 5, 5.1, 5.2 өлешләренә кагылган проблемалы мәсьәләләре буенча карар эшләве максатка ярашлы булыр иде дип саныйбыз.

Вәкаләтле вәкилгә безнең республикада яшәүчеләр (Казан, Чаллы, Яшел Үзән шәһәрләрендә яшәүчеләр) башкару производстволары буенча бурычлылар булган пенсионерлар пенсияләреннән законда каралган максималь күләмнән (50 процент) күбрәк акча тотып калулары турында еш мөрәҗәгать итә.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең документларын өйрәнгәч, бурычны тотып калгач калган акча яшәү минимумыннан түбәнрәк сумманы тәшкил иткән очракларда, Вәкаләтле вәкил законны төгәл үтәүне сорап Татарстан Республикасы Баш суд приставына мөрәҗәгать итте. Алга таба, тикшерү нәтиҗәләре буенча, суд приставлары хезмәтенең вазифадагы затлары мөрәҗәгать итүчеләрдән акча тотып калу күләмен әлеге хәлләрдән чыгып, хәл итте.

Татарстан Республикасы Конституциясенә ярашлы рәвештә картлык дәүләт тарафыннан яклана. 2019 елдан Татарстан Республикасы читләр ярдәменә мохтаҗ олы яшьтәге кешеләргә комплекслы ярдәм күрсәтү, озак вакытлы карау системасы булдыру проектында катнаша. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, проект кысаларында 2020 елда 13 муниципаль районнан 3682 кеше, яки социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ кешеләрнең 16,1 проценты озак вакытлы карау системасына керде.

Шул ук вакытта Вәкаләтле вәкилгә «Глонасс+112» һәм башка чыганаклар аша читләр ярдәменә мохтаҗ булган, социаль яктан куркыныч хәлдә булган өлкән яшьтәге кешеләр булуы турында мәгълүмат килә, шунысын да әйтергә кирәк, алар һәрвакытта да аерым яшәү урыны һәм шөгыле булмаган кешеләр түгел.

Мәсәлән, Казан шәһәрендә яшәүче Вәкаләтле вәкилгә, гаиләдәге низаг аркасында беркадәр вакыт ач килеш, подъездда төн кунган 1 947 елгы күршесе язмышын кайгыртып мөрәҗәгать итте. Вәкаләтле вәкил һәм «Социаль тернәкләндерү һәм адаптацияләү үзәге» коммерциячел булмаган оешмасы булышлыгы белән өлкән яшьтәге граждан күрсәтелгән оешма каршындагы

приютка урнаштырылды, аңа анда вакытлыча яшәү урыныннан тыш, өч тапкыр бушлай ашату, мунча, чәчтараш, психолог ярдәме тәкъдим ителде.

«Социаль тернәкләндерү һәм адаптацияләү үзәге» коммерциячел булмаган оешмасы мәгълүматларына караганда, 2020 елда «Кеше приюты» проекты кысаларында 2 373 кеше мөрәҗәгать иткән. Иҗтимагый оешма хезмәткәрләре ярдәме белән 30 граждан төрле социаль учреждениеләргә урнаштырылган. Күрсәтелгән саннар һәм китерелгән мисал, Вәкаләтле вәкил фикеренчә, читләр ярдәменә мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны ачыклау һәм озак вакыт тәрбияләү буенча, шул исәптән гаилә низаглары аркасында туганнары ташлаган ялгыз гражданнарны ачыклау буенча социаль яклау органнарының эшен активлаштыру максатка ярашлы булыр иде.

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкилнең хокукый эшчәнлеге опека һәм попечительлекне билгеләү, тормышка ашыру һәм туктату уңаеннан килеп туган мөнәсәбәтләр буенча да алып барылды.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2020 елның 4 декабренә опекуннар саны 4 927 кешене тәшкил итә, шулардан 3 605 опекун үз вазифаларын бушлай, 1 322 е түләүле нигездә башкара.

Тәкъдим ителгән мәгълүматтан күренгәнчә, Татарстанда күпчелек опекуннар үз вазифаларын бушлай башкара. Федераль законда билгеләнгән гомуми кагыйдә буенча, опека һәм попечительлек буенча вазифалар бушлай башкарыла. Шуның белән бергә опеканы һәм попечительлекне бушлай рәсмиләштергән опекуннар яки балигъ булмаганнарның попечительләре үз вазифаларын түләүле итеп башкаручылар дип гариза язарга хокуклы. Мондый очракларда опека һәм попечительлек органнары карарны тәрбиядәге бала мәнфәгатьләреннән чыгып кабул итәргә тиеш, шуңа күрә опеканы түләүле итеп рәсмиләштерергә теләүне дәлилсез кире каккан хәбәрләр алган очракларда без тиешле чаралар кабул иттек.

Вәкаләтле вәкилгә элек балигъ булмаган балаларга опеканы бушлай нигездә рәсмиләштерүе нәтиҗәсендә, опеканы түләүле итеп рәсмиләштерергә теләгән, ләкин аңа моны эшләүдән баш тарткан органнан зарланып, Алексеевск районында яшәүче мөрәҗәгать итте. Шикаятьне карау барышында опека органының балалар мәнфәгатьләрен яклап үз карарын үзгәртүе турында хәбәр алынды.

Узган елда беренче тапкыр балигъ булмаган балаларга аларны опекун итеп билгеләүдән, шул исәптән Россия Федерациясе Гаилә кодексының 146 нчы маддәсе 2 пунктына ярашлы рәвештә таләп ителә торган кирәкле әхлакый һәм башка шәхси сыйфатлар булмауга сылтап, баш тартулары турында опека

органнары чыгарган карарлардан риза булмаучы гражданнардан шикаятьләр килә башлады.

Шунысын да билгеләргә кирәк, опекун булырга теләгән гражданның нинди әхлакый һәм башка шәхси сыйфатларга ия булуы югарыда күрсәтелгән нормада да, башка норматив хокукый актларда да төгәл (конкрет) күрсәтелми. Шуның белән бергә, Вәкаләтле вәкил шундый шикаятьләрнең берсен караганда, мөрәҗәгать итүченең опекун булырга теләгән гаризасын объектив карау хокукы бозылган, дип тапты.

Россия Федерациясе Гаилә кодексының 146 нчы маддәсе 2 нче пунктына сылтама белән, Менделеев районының опека һәм попечительлек буенча ведомствоара комиссиясе Менделеевск шәһәрендә яшәүчене балигъ булмаган балага опекун була алмый дип тапкан. Шул ук вакытта, мөрәҗәгать итүче элек әлеге баланы вакытлыча карап торган һәм вакытлыча опекун булган вакытта, опека органнары бернинди дә кимчелекләрне дә ачыкламаган. Булган хәлләрне һәм федераль закон таләпләрен исәпкә алып, балигъ булмаганнарга опекун яки попечитель булырга теләк белдергән яки ата-ана тәрбиясеннән калган балаларны (Россия Федерациясенең башка гаилә законнарында билгеләнгән, Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2009 елның 18 маенда дөнья күргән 423 нче карары белән расланган формалары нигезендә тәрбиягә алырга теләгән гражданнарны сайлау, исәпкә алу һәм әзерләү тәртибе) тәрбиягә алырга теләгән гражданнарны билгеләү буена ахыргы карарны, Вәкаләтле вәкил фикеренчә, опека органы опекун булырга теләк белдергән гражданның тормыш шартларын тикшергәннән соң гына кабул итәргә тиеш. Бу уңайдан, Вәкаләтле вәкил җирле үзидарә органына мөрәҗәгать иткән граждан мөрәҗәгатен кабаттан караганда исәпкә алынырга тиешле тәкъдимнәрен җибәрде һәм алар алга таба исәпкә алынды.

Мондый шикаятьләр гражданнардан күп килүен исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил әлеге мәсьәлә буенча опека һәм попечительлек органнары эшен җайга салуны сорап Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына хат җибәрде. 2020 елның 23 октябрендә министрлыктан килгән хатка ярашлы рәвештә, әлеге мәсьәлә буенча тиешле тәкъдимнәр эшләнә. Үз чиратыбызда, опекунлыкка (попечительлеккә) кандидатларның әхлакый һәм шәхси сыйфатларын бәяләү буенча тәкъдимнәр опекун (попечитель) вазифасын башкарырга сәләтле гражданны опекун (попечитель) итеп билгеләүдә каршылык тудырырга тиеш түгел, дип саныйбыз.

Нәтиҗәле социаль сәясәтне, инвалидларның социаль хокукларын тормышка ашыруда башка гражданнар белән тигез мөмкинлекләр тәэмин итүгә юнәлтелгән чаралар комплексыннан башка күз алдына китереп булмый.

«Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы мәгълүматлары буенча, 2020 елның 1 декабренә Татарстан Республикасында 291 856 инвалид бар иде.

Дәүләт ягыннан инвалидларның хокукый статусы мөһим гарантияләре булып тернәкләндерү чаралары үткәрү һәм федераль бюджет акчасына хезмәтләр күрсәтү тора.

Яхшы сыйфатлы техник тернәкләндерү чараларын вакытында алу меңнәрчә татарстанлы хокукына кагыла. Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстандагы төбәк бүлеге мәгълүматы буенча 2020 елның 11 аенда авыруларны памперс белән тәэмин итүне сорап 22 146 гариза язганнар, шуның 21 696 сы үтәлгән.

Социаль иминият органнары эше контрольлек итүче органнар, җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары ягыннан ныклы игътибарда. Шуның белән бергә, барлык гаризалар тулы күләмдә тәэмин ителмәгәндә, техник тернәкләндерү чарасын үз акчасына алган инвалидка компенсация түләү белән бәйле сораулар үз актуальлеген югалтмый. Гамәлдәге закон белән инвалид үзе алган техник тернәкләндерү чарасы яки хезмәт өчен компенсация түләү каралган. Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстандагы бүлеге мәгълүматлары буенча 2020 елның 11 аенда мөстәкыйль сатып алынган техник тернәкләндерү чаралары өчен 1 112 039,6 мең сумлык компенсация түләнгән. Граждан техник тернәкләндерү чарасы яки хезмәт алганчы ук күпме компенсация түләнәчәге турында белергә тиеш.

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстандагы төбәк бүлеге рәсми сайтында (http://fss16.ru) урнаштырылган мәгълүматны анализлау шуны күрсәтте, мөстәкыйль рәвештә техник тернәкләндерү чарасы алган өчен компенсацияләр бүлегендә, инвалидка күрсәтелә торган федераль тернәкләндерү чаралары, хезмәтләр һәм техник тернәкләндерү чаралары исемлеге кысаларында техник тернәкләндерү чараларын (әйберләрен) классификацияләү позицияләре буенча техник тернәкләндерү чаралары бәяләре турында мәгълүмат юк.

Кайбер позицияләр буенча техник тернәкләндерү чаралары бәясе турында мәгълүмат юклыгын ачыклау максатларында Вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан бүлегенә хат җибәрде.

Хат нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстандагы бүлеге техник тернәкләндерү чаралары бәяләре турында мәгълүмат булган документны яңартып, өч техник тернәкләндерү чарасы бәясенә өстәде.

Инвалидлар хокуклары турындагы Конвенцияне раслап, Россия Федерациясе аны тормышка ашыру, шул исәптән, мөмкинлекләр

һәм уңайлылык тигезлеге кебек принципларны тормышка ашыру буенча йөкләмәләрне алды. Илкүләм законнар дәрәҗәсендә әлеге принципларны тормышка ашыру механизмы 1995 елның 24 ноябрендә дөнья күргән 181 нче «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» федераль законның 15 нче маддәсендә билгеләнгән, аңа ярашлы рәвештә, инвалидларны социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына тоткарлыксыз үтеп керүне тәэмин итү максатларында, инвалидларга чираттан тыш, яшәү урыны янында шәһәр төзү нормаларын исәпкә алып, техник яки башка хәрәкәтләнү чаралары өчен гараж яки туктау урыны төзергә урыннар бирелә.

Чынлыкта, Вәкаләтле вәкилгә, инвалидлардан элек җирле үзидарә органнары тарафыннан аренда килешүе буенча бирелеп, файдалану вакыты чыккан металл гараж алып торган җир кишәрлегеннән файдалануга булышлык итүне сораган мөрәҗәгатьләр килә. Ә аренда килешүе, «металл гараж»лар куллануга рөхсәт гамәлдәге законда каралмаганлыктан, озайтылмый. Хәзерге вакытта инвалидларга металл гаражларны сүтү кирәклеге әйтелгән мөрәҗәгатьләр килә. Инвалидларның металл гаражлары белән булган вәзгыять массакүләм мәгълүмат чараларында да яктырылды.

Вәкаләтле вәкил ягыннан Казан шәһәре җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитетына хәлне чишүнең альтернатив юлы тәкъдим ителде. 181 нче федераль законның 15 нче маддәсе положениеләре һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 маддәсе 2 пунктының 14 нче бүлегеннән чыгып, инвалидка муниципаль милектә булган җир кишәрлеген арендага анда (билгеле аренда килешүенә инвалидта кызыксыну булса) гараж төзү өчен бирү вариантын карау максатка ярашлы булыр иде. 2020 елның 29 февралендә алынган мәгълүмат буенча әлеге тәкъдим каралган һәм алга таба эштә исәпкә алыначак. Дөрес, конкрет практикага сылтамасыз гына.

Инвалидларның мөмкинлекләр тигезлеге принцибы шулай ук физкультура-сәламәтләндерү чаралары, спорт булган тернәкләндерү һәм тормышка яраклаштыруның төп юнәлешләре аша тормышка ашырыла.

Статистика мәгълүматлары шуны дәлилли, Татарстанда адаптив спорт елдан ел яхшыга үзгәрә. 2015 елда Казан шәһәренең «Республика спорт-адаптив мәктәп» дәүләт бюджет учреждениесе ачылу адаптив спортны үстерүгә зур этәргеч бирде. Хәзерге вакытта мәктәптә ишетмәүчеләр, сукырлар һәм терәк-хәрәкәт аппараты бозылган, интеллектуаль кимчелекле кешеләр спорты буенча бүлекләр эшли. Чаллыда, Әлмәттә һәм Лаешта, Мамадыш һәм Саба муниципаль районнарында бүлекләр ачылды. Татарстан Спорт министрлыгының 2020 елның 1 гыйнварына булган мәгълүматлары буенча, инвалидларның 28,1 проценты, шул исәптән балалар, үсмер-инвалидлар физик

культура һәм спорт белән шөгыльләнә. Статистика күрсәткечләрендә үлчәнә торган уңышлар фонында, даими рәвештә инвалид яки инвалид бала тәрбияләүче ана, шул исәптән, Россиянең спорт башкаласы исемен йөрткән Казанда спорт секциясенә языла алмый.

Әйтик, Вәкаләтле вәкилгә Дауна синдромлы балигъ булмаган баласын спорт секциясенә яздыра алмаган Казанда яшәүче мөрәҗәгать итте. Кызыксындырган сорау буенча тулы мәгълүмат алу өчен мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына җибәрелде. Күрсәтелгән министрлыктан 2003 елның 6 октябрендә дөнья күргән 131 нче «Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законга сылтама белән, әлеге мөрәҗәгать, җавап алу өчен Казан шәһәре физик культура һәм спорт комитетына җибәрелгән. Муниципаль учреждениенең җаваплы кешесе мөрәҗәгать итүчегә һәм Вәкаләтле вәкилгә, хәзерге вакытта әлеге авыру белән авырган балалар өчен Казан шәһәренең муниципаль спорт мәктәпләрендә тренировкалар үткәрелми дигән җавап җибәрде. Бер автоном коммерциячел булмаган оешмага мөрәҗәгать итәргә кушылды, анда сәламәтлегендә мондый проблемалар булган балалар белән дәресләр үткәрергә мөмкиннәр дигән мәгълүмат бар иде.

Узган елның декабрендә Вәкаләтле вәкил закон чыгару һәм башкарма хакимият, җирле үзидарәләр органнары, иҗтимагый оешмалар, югары уку йортлары, спортчы-инвалидларның тренерлары, Вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре катнашында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә адаптив физик культура һәм спорт буенча дәресләр оештыру мәсьәләләренә багышланган «түгәрәк өстәл» утырышы уздырды. Чара йомгаклары буенча анда катнашучылар безнең адреска адаптив физик культура һәм спортны үстерүгә булышлык итүгә кагылышлы үз тәкъдимнәрен җибәрделәр. Барлык килгән тәкъдимнәрне ике төркемгә бүләргә мөмкин: инвалидлар белән дәресләр үткәрү өчен спорт җиһазлары һәм инвентарь алуга, спортчы-инвалидларны йөртү өчен махсус транспорт алуга өстәмә акча бүлүгә кагылышлы тәкъдим-юллама, шулай ук спорт учреждениеләре бюджетын формалаштырганда инвалид балалар белән адаптив физик культура буенча эшне оештыру өчен штат берәмлеге булдыру; адаптив физик культура тармагына тренерларны җәлеп итү буенча максатчан эш алып бару, массакүләм мәгълүмат чаралары аша сәламәтлекләре чикләнгән кешеләр белән физик культура һәм спорт дәресләре алып баруны пропагандалау һәм агитацияләү тәкъдимнәре.

Адаптив физик культураны үстерүнең проблемалы мәсьәләләре буенча килгән мәгълүматны анализлау, безнеңчә, аерым аспектлар буенча эшне камилләштерү кирәклеге турында кайбер нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә.

Яшәү урыны буенча халык белән, инвалидлар белән физкультура-спорт эшен оештыру белән бәйле, шул исәптән Татарстан Республикасы муниципаль дәрәҗәсендә финанс һәм кадрлар белән тәэмин итүгә бәйле проблемалар барлыгы, сәламәтлекләре чикләнгән кешеләр арасында физик культура һәм спорт дәресләрен пропагандаларга кирәклеге, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартында дөнья күргән 159 нчы «2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасының «2019 – 2023 елларга физик культураны һәм массакүләм спортны үстерү» программасында да күрсәтелә. Массакүләм спорт өчен, шул исәптән инвалидлар һәм сәламәтлекләре чикләнгән затлар өчен уңайлы спорт инфраструктурасын тәэмин итү, спортны үз иткән инвалид балалар һәм үсмерләр өчен өстәмә адаптив спорт оешмалары (бүлекләре) ачу буенча чаралар үткәрүне, сәламәтлекләре чикләнгән балалар белән физик культура һәм спорт дәресләре үткәрү урыннарын кирәкле спорт инвентаре һәм махсус җиһаз белән җиһазландыруны күздә тота. Системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче инвалидлар саны буенча билгеләнелгән күрсәткечләргә ирешүгә юнәлтелгән чаралар белән бергә, Вәкаләтле вәкил фикеренчә, оештыру характерындагы сәбәпләр дә игътибарсыз кала алмый. Монда кайбер инвалидлар һәм сәламәтлекләре чикләнгән затлар физик культура һәм спортны үстерүнең гомуми тенденциясеннән читтә кала.

Дауна синдромлы баласын Казан шәһәре спорт мәктәбенә яздыра алмау турындагы югарыда күрсәтелгән мисал, республикада адаптив физик культура һәм спорт дәресләрен оештыру турында җыелган мәгълүмат, безнеңчә, инвалидлар һәм физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен тулаем өйрәнү күнегүләре оештыруга караганда, Дауна синдромлы кешеләр өчен өйрәнү күнегүләре оештыру начаррак куелган дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Әйтик, Эксперт советы йомгаклары буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитеты әлеге синдромлы кешеләр өчен спорт төркемнәре төзү авыр булуын төп проблема итеп китерә, шул ук вакытта район территориясендә терәк-хәрәкәт аппараты бозылган һәм интеллектуаль кимчелекләре булган кешеләр өчен спорт дәресләре оештырылуын билгели.

Йөзү өчен дәресләрдә ДЦП авырулы балалар булган гаиләләр башкалар белән чагыштырганда начаррак хәлдә кала. Булган мәгълүматны анализлау ДЦП авырулы балалардан бассейн өчен акча алмауларын, әмма баланың законлы вәкилләре йөзәргә өйрәтү өчен тренерны үзләре табарга тиешлеген күрсәтте. Альтернатив юллар юк.

Физик культура һәм спортның массакүләмле булуын тәэмин итү, халыкның аерым өлешенә күнегүләр белән шөгыльләнергә комачаулаучы факторларны киметү юлы белән тормышка ашырылырга тиеш. Вәкаләтле вәкил

фикеренчә, системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче Дауна синдромлы балалар һәм йөзү белән шөгыльләнүче ДЦП авырулы балалар санын арттыруга юнәлтелгән чараларны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тәкъдим итәргә тиеш. Шулай ук физик культура һәм спортның массакүләмле булуын үстерү өчен республиканың муниципаль районнарында булган иң яхшы практикаларны берләштерергә кирәк дип саныйбыз. Әйтик, Эксперт советы йомгаклары буенча, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары начар ишетүче инвалид-балалар белән күнегүләрне оештырганда Бөгелмә муниципаль районының «Факел» спорт мәктәбе эш тәҗрибәсен кулланырга тәкъдим ителде.

Тулаем алганда, шикаятьләр караудан һәм башка тикшерү чаралары үткәрүдән тыш, Вәкаләтле вәкил ел дәвамында мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең хокукларын саклау мәсьәләләре буенча максатчан аңлату эше алып барды, шул исәптән, 2020 елның декабрендә әлеге темага «кайнар элемтә», ZOOM платформасында ай саен инвалид балалары булган ата-аналар өчен «Хокукый белем мәктәбе» дәресләре үткәрелде. Консультация-аңлату эше Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан бүлеге, «Татарстан Республикасы буенча медико-социаль экспертиза Баш бюросы» белән тыгыз хезмәттәшлектә алып барылды.

Гражданны инвалид итеп тану мәсьәләләре буенча да консультация эше алып барылды. Әлеге эшнең актуальлеге турында, саннар да сөйли, 2020 елда республикада 14 843 граждан инвалидлык төркемен билгеләү өчен медико-социаль экспертизаның федераль учреждениеләренә мөрәҗәгать иткән, 14 314 кеше инвалид дип танылган, 529 кешегә инвалидлык төркеме бирүдән баш тартканнар. Шул ук вакытта муниципаль берәмлекләрне чагыштырганда, беренчел инвалидлык алу дәрәҗәсе бер төсле түгел. Зәй, Югары Ослан, Актаныш муниципаль районнарында бу күрсәткеч югары. Беренчел инвалидлыкның гомуми дәрәҗәсендә республикада 10 000 кешегә 46,8 булганда, югарыда күрсәтелгән районнарда – 64,9; 62,4; 62,1 тәшкил итә.

Шул ук вакытта Вәкаләтле вәкилгә, инвалидлык төркеме билгеләмәү, тернәкләндерү һәм абилитацияләү программасына үзгәрешләр кертергә кирәклеге турында медико-социаль экспертиза бюросы карарлары белән риза булмаган мөрәҗәгатьләр килә. Медицина оешмасы медико-социаль экспертизага юллама бирмичә гражданнарның инвалид дип тануга хокукларын бозу турындагы мөрәҗәгатьләргә аерым игътибар бирдек (узган елларда Вәкаләтле вәкилгә мондый шикаятьләр килми иде). Күпчелек очракларда без мөрәҗәгать итүченең дәвалау-профилактика ярдәме күрсәтүче

учреждениегә медико-социаль экспертизага юллама сорап мөрәҗәгать итмәвен ачыкладык. Шуның белән бергә, Арча районында медицина оешмасының граждан гаризасы буенча медико-социаль экспертизага юллама да, медико-социаль экспертизага юллама бирүдә баш тартулары турындагы белешмә дә бирелмәгән очрак булган. Әлеге уңайдан Вәкаләтле вәкил Арча үзәк район хастаханәсе җитәкчесенә ачыкланган хокук бозуны бетерү буенча тәкъдимен җибәрде.

Килгән шикаятьләр буенча теге яки бу карарлар кабул итүдән тыш, гражданнарның сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокукларын саклау һәм яклау буенча эш, даими нигездә, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасының «Сырхауханәләр һәм хастаханәләр» төре буенча килгән мөрәҗәгатьләрне карау юлы белән тормышка ашырыла.

Билгеле, хокук саклау эшчәнлеген тормышка ашырганда, сәламәтлек саклау системасын оештыруга короновирус инфекциясе пандемиясе йогынты ясавы да исәпкә алынды, шул исәптән койка-урыннарны этаплап үзгәртү, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы госпитальләр штатын тулыландыру өчен республиканың башка медицина оешмаларыннан, COVID-19 йоктырган авыруларга медицина ярдәме күрсәтүдә булмаган медицина хезмәткәрләрен госпитальләргә җибәрде. Татарстан Республикасында COVID-19 белән авыручыларны кабул итү өчен 55 медицина оешмасында 5 552 койка-урын булдырылды.

Чикләү чаралары вакытында планлы медицина ярдәме күрсәтү вакытлыча туктатылды. Шуңа күрә планлы амбулатор-сырхауханә медицина ярдәме яңадан күрсәтелә башлагач, без, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы баш модераторы буларак, халыкның белгечләр кабул итүен озак көтүен белгәч, моны контрольгә алдык. Мәгълүмат системасына килгән тиешенчә карамаулары турындагы дәгъвалар нигезле булганда, мөрәҗәгатьне кире кайтарып, җаваплы башкаручыларга кирәкле гамәлләр кылу өчен тәкъдимнәр керттек, чаралар күрдек.

Әйтик, «Халык контроле» системасыннан кулланучылар Казан шәһәренең «6 нчы шәһәр балалар хастаханәсе»ндә язылып кына түгел, «тере» чират буенча да озак кына табибка эләгә алмауларыннан зарландылар. Сәламәтлек саклау учреждениесе кадрлар кытлыгы булуын әйтеп, мөрәҗәгатькә «Гариза хәл ителде» дигән статус куйды. Без балигъ булмаган балаларның амбулатор-сырхауханә медицина ярдәме алуга хокукын тормышка ашыруга күрсәтелгән медицина оешмасы тарафыннан бернинди мәгълүмат булмаганлыктан, мөрәҗәгатьне эшкә кире кайтардык. Соңрак мәгълүмат системасындагы җаваплы башкаручылар балаларны кабул итүне оештырулары турында мәгълүмат бирде.

Граждан Р. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында расписание булмаганлыктан, Казан шәһәренең «21 нче шәһәр сырхауханәсе»нең табиб-терапевтына кабул ителүгә языла алмаган. Проблемалы хәл турында «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына җибәрелгән мөрәҗәгатькә, медицина оешмасы мөрәҗәгать итү вакытында терапевт булмавы турында хәбәр иткән, ләкин кизү торучы табибка мөрәҗәгать итү мөмкинлеге турындагы мәгълүмат системага урнаштырылмаган була. Әлеге фактка без ачыклык керттек, шуңа күрә мөрәҗәгать гражданга кизү торучы табиб кабул итү мөмкинлеге турында тиешле мәгълүмат биргәнче, эшкә кире кайтарылды.

Кадрлар кытлыгы вакытында медицина ярдәме күрсәтелмәүгә сәбәп булуы беренче елны гына түгел, ләкин бу медицина оешмалары җитәкчеләренә белгечләр эзләү һәм кабул итү буенча бурычларын өсләреннән төшерми, моңа законда билгеләнгән тәртиптә мәшгульлек хезмәте органнары белән бергәләп эшләү аша да ирешергә мөмкин.

Монда шунысын да билгеләргә кирәк, 2021 елга Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы үткәргән өстенлекле максатлар һәм бурычларны билгеләү буенча тавыш бирү нәтиҗәләре, сырхауханәләрне медицина кадрлары белән тәэмин итүне арттыру республикада яшәүчеләр өчен мөһим проблема булып торуын күрсәтте.

Конкрет мөрәҗәгатьләрне карау белән беррәттән, без «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына күп шикаять килгән медицина оешмаларын ачыклау буенча да даими рәвештә аналитик эш алып бардык. «Сырхауханәләр һәм хастаханәләр» төре буенча килгән мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны турындагы, шулай ук күп шикаять килгән һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында кулланучылардан теләктәшлек тапкан сәламәтлек саклау учреждениеләре турындагы аналитик мәгълүматны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В.Песошинга җибәрдек.

Узган ел нәтиҗәләрен карасак, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы чираттагы тапкыр республикада яшәүчеләр өчен кирәкле булуын раслады. Мәгълүмат системасында мөрәҗәгатьләрне урнаштыруда уңайлылык тудыру өчен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 10 августында дөнья күргән 676 нчы «Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасын эшләтү кысаларында гражданнарның, дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм җирле үзидарә органнарының электрон бергәлеге турында»ны карарының «Сырхауханәләр һәм хастаханәләр» төренә кагылышлы өлешенә үзгәрешләр кертеләчәк һәм төрләр исемлеге тулыландырылачак. 2021 елдан порталдан файдаланучылар ун аерым төр

буенча медицина ярдәме алу белән бәйле проблемалар турында хәбәр итә алыр дип көтелә. Шул ук вакытта аларның икесе – «Ашыгыч медицина ярдәме эше» һәм «Даруханәләрдә һәм даруханә пунктларында ташламалы дарулар юклык» буенча шикаятьләр һәм тәкъдимнәр мәгълүмат системасында билгеләнгән модерация кагыйдәләренә ярашлы рәвештә бастырылмады.

Орфан авырулар белән җәфаланучы кешеләрне дару препаратлары белән тәэмин итүгә кагылышлы проблема да кискен тора. Узган елда сәламәтлек саклау өлкәсендә федераль дәрәҗәдә сирәк авырулы пациентларны, шул исәптән арка мускул атрофиясе белән авыручы кешеләрне, федераль бюджетка киләчәк акча исәбенә дарулар белән тәэмин итү буенча фонд төзү турында мөһим карар кабул ителде. Шулай ук доклад кысаларында сирәк авыруларны дәвалау өчен өстәмә чаралар җәлеп итү буенча карар турында, элегрәк без, шул исәптән, Россия Федерациясе субъектларындагы Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр белән бергәләп, үзәкләштерелеп сатып алына торган дару препаратлары исемлеген киңәйтү турында мөрәҗәгатьләр, аерым алганда, арка мускул атрофиясе белән авыручы балаларны федераль бюджет акчасы исәбенә дәвалауны оештыруга булышлык итүне сорап, Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н. Москальковага хат җибәрдек.

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил берничә тапкыр гражданнардан даруханә оешмаларында (Казан шәһәре, Әгерҗе, Бөгелмә, Биектау районы) булмаганлыктан дару препаратларын алмаулары турында мөрәҗәгатьләр алды. Мондый мөрәҗәгатьләр тикшерү өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җибәрелде, ләкин мөрәҗәгать итүче граждан кирәкле дару препараты белән тәэмин ителү турында мәгълүмат алганчыга кадәр аларны карауны контрольдә тотты.

Әйтик, мисал өчен, 2020 елның 11 декабрендә Вәкаләтле вәкил Казанда яшәүченең аның онкологик авыру белән чирләүче әтисен тормыш өчен бик кирәкле дару препараты белән тәэмин итмәүләре турындагы мөрәҗәгате уңаеннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына хат җибәрде. Булган мәгълүматка караганда, мөрәҗәгать итүченең әтисе кирәкле дару препараты белән 2020 елның 17 декабрендә тәэмин ителгән.

Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләре 2021 елда гражданнар медицина ярдәме оештыру белән бәйле зарларын җиткергән хәлләргә ныграк игътибар бирер дип ышана.

Шәхес буларак та, җәмгыятьтә үсү өчен дә алшартлар тудыручы белемгә хокук, башка социаль хокуклар белән тыгыз бәйләнгән.

Короновирус инфекциясе таралуны булдырмау максатларында, уку йортларында уку процессын оештыруга, шулай ук дәүләт имтиханын әзерләүгә

һәм үткәрүгә үзгәрешләр кертелде, бу мәгариф өлкәсендә идарә органнарыннан да, тулаем педагоглардан да югары оешканлык таләп итте.

Шуның белән бергә, мәгариф өлкәсендә короновирус инфекциясе белән бәйле булмаган проблемалы мәсьәләләр үз актуальлеген югалтмады. Узган еллардагы кебек үк Вәкаләтле вәкил, балигъ булмаган балаларын 10 нчы сыйныфка кабул итү буенча гаризаларын карамаулары турында гражданнар шикаятьләре буенча тикшерү чаралары үткәрде. Узган еллардагы докладларның берсендә без укучыларны белем бирү оешмасына 10 нчы сыйныфка кабул итүне оештыруга юнәлтелгән, «ачыклык» принцибына нигезләнгән өстәмә чаралар кабул итәргә кирәклеге турында билгеләп үткән идек. Чаралар күрелмәсә, мондый баланың ата-анасы унынчы сыйныфка кабул итүгә гариза бирүләре турында хәбәр итеп тә, белем бирү учреждениесе хакимияте тарафыннан әлеге факт кире кагылуы кебек очраклар бетмәячәк.

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил адресына бер муниципаль район (Питрәч районы) составына кергән җирлекләр арасында укучы балаларны бушлай йөртүне оештыру буенча мөрәҗәгатьләр керде. Карау өчен әлеге мөрәҗәгатьләр җирле үзидарә органнарына җибәрелде, ләкин аларны карау барышы проблема уңай хәл ителгәнчегә кадәр контрольдә булды.

Балага муниципаль мәктәпкәчә яшьтәге учреждениедә (Казан, Лаеш районы) урын бирелмәү турындагы шикаятьләр дә игътибарсыз калмады. Әлеге шикаятьләр буенча без, беренче чиратта, җирле үзидарә органнары тарафыннан баласын бакчага урнаштырырга теләүчеләргә альтернатив вариантлар тәкъдим ителгәнме, шуны ачыкладык.

Шунысын да билгеләргә кирәк, тулаем алганда күрсәтелгән проблема элеккечә үк мәктәпкәчә яшьтәге мәгариф учреждениеләренең җитәрлек булмавы һәм аларның челтәрен киңәйтү зарурилыгы белән бәйләнгән. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2020 елның 26 октябренә дәүләт һәм муниципаль мәктәпкәчә яшьтәге мәгариф оешмаларында урын белән тәэмин ителмәгән 3 яшькәчә балалар саны – 12133, өч яшьтән җиде яшькәчә балалар саны – 3028. Бигрәк тә Казан шәһәренең яңа торак комплексларында, шулай ук Лаеш һәм Питрәч муниципаль районнарында урыннар җитмәү аеруча сизелә.

Меңнәр белән исәпләнә торган чиратта, проблемалы хәлләр масштабын арттырмау зур әһәмияткә ия. Әйтик, Вәкаләтле вәкил бер массакүләм мәгълүмат чарасында басылган язмадан соң тикшерү үткәрде, анда бинаның санитар-техник торышы канәгатьләнерлек булмаганлыктан, Роспотребнадзор органнары тикшерүе нәтиҗәләре буенча Казан шәһәренең «104 нче балалар бакчасы» эшен туктаткач балаларны башка балалар бакчаларына бүлү буенча чаралар күрелмәве хакында әйтелгән иде. Башкарма комитет мәгълүматы

буенча «104 нче балалар бакчасы»ның барлык тәрбияләнүчеләре якындагы мәктәпкәчә яшьтәге учреждениеләргә бүленгән. Шуның белән бергә, безнең Роспотребнадзорның Татарстандагы идарәсенә җибәргән хатыбызга, мәгариф учреждениесе җитәкчесенең муниципаль учреждение тиешле устав бурычларын үтәсен өчен бюджет ассигнованиеләре бүлү турында тәкъдим җибәрүе, ләкин күрсәтелгән максатларга бюджет акчасы бүленмәү турында җавап алынды.

Казан шәһәре җирле үзидарәсе органнары мәгълүматларына караганда, асылда балаларның тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы кимчелекләрне бетерү буенча чаралар күрелмәүнең сәбәбе – җитәрлек акча булмау. Шуның белән бергә, «104 нче балалар бакчасы»нда тәрбияләнүчеләрнең Роспотребнадзор органнары чара күргәнче башка мәктәпкәчә яшьтәге мәгариф учреждениеләренә бүленмәве сәбәпләре турындагы сорау ачык калды.

Компетентлы органнар белән күчмә тикшерүләр нәтиҗәсендә мәгариф оешмаларында теге яки бу санитар нормалар үтәлмәү фактлары Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре тарафыннан да ачыкланды.

Кешенең социаль хокукларының аерылгысыз бер өлеше ул – торакка хокук.

Татарстан Республикасы торак сафка бастыру буенча Россия Федерациясе субъектлары арасында лидерларның берсе булып кала. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2020 елда республикада 2 680 087 квадрат метр торак сафка бастырылган. 41 муниципаль берәмлектә 1 063 күпфатирлы йортта 6473,997 миллион сумлык капиталь ремонт үткәрелгән.

Ел дәвамында өлешләп төзетүчеләрнең проблемалы объектларын төзеп бетерү буенча актив эш алып барылды. Татарстан Республикасының өлешләп төзетүдә катнашучы гражданнар хокукларын яклау фонды мәгълүматларына караганда, 2020 елда 6 проблемалы өлешләп төзетү объекты сафка бастырылган, 7 объект буенча 398 өлешләп төзетүченең хокуклары торгызылган (2 – Казан шәһәрендә, 3 – Чаллы шәһәрендә, 2 – Питрәч муниципаль районында). Бу 421 өлешләп төзетүчегә үз фатирына күчәргә мөмкинлек биргән. Гражданнарны аварияле торак фондыннан күчерү буенча чаралар планы тормышка ашырыла (94 торактан 271 кешене 2,62 мең квадрат метрга күчерү эше алып барыла), 600 ятим бала фатирлы булды, Татарстан Республикасы бюджет акчасын кулланып, 46 күп балалы гаилә, Татарстан Республикасы бюджеты һәм федераль бюджет акчасын кулланып, 47 яшь гаилә тормыш шартларын яхшыртты. Шуның белән бергә, торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә халыкның аз якланган катлавы (аз тәэмин ителгән кешеләр, ятим

балалар һәм башкалар) вәкилләренә дәүләт яки муниципаль торак фондыннан торак биналары бирүгә хокукларын тану белән бәйле шикаятьләр, иң таралган шикаятьләр булып тора.

Әйтик, Вәкаләтле вәкил адресына Мамадыш районында яшәүчедән аварияле торагы урынына торак бирмәүләре турында шикаять килде. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүче законлы көченә кергән суд карары күчермәсен дә җибәргән, аннан күренгәнчә, әлеге бурыч Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетына йөкләнгән.

Шуның белән бергә, граждан суд карарыннан соң «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы белән торак наймы килешүе төзегән, җирле үзидарә органы үз бурычы бетте, дип санаган.

Барлык документларны өйрәнгәннән соң, Вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты адресына мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозуны бетерүне сораган тәкъдимнәрен җибәрде. Вәкаләтле вәкил җибәргән тәкъдимнәрне карагач, мөрәҗәгать итүченең торакка хокукы танылган һәм муниципаль торак фондында буш тораклар барлыкка килү белән аның торак шартларын яхшырту турындагы мәсьәлә каралачак.

Ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү – Вәкаләтле вәкилнең даими контролендә булган темаларның берсе.

Узган елда Вәкаләтле вәкил махсус торак наймы килешүе буенча торак бирүгә мохтаҗ ятим балаларны, 23 яшькә җиткән яшьләрне исәпкә кую мәсьәләләре буенча ведомствоара торак комиссиясе әгъзасы сыйфатында катнашу юлы белән, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән үзара хезмәттәшлекне дәвам итте.

Үз чиратында, Вәкаләтле вәкил, ведомствоара торак комиссияләре утырышлары уздырудан тыш, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ятим балаларны исәпкә куйганда мөрәҗәгать итүчеләрдән артык документлар тәкъдим итүне таләп итү очракларын да билгеләп үтә.

Казанда яшәүче шундый проблема белән очрашкан. 2018 елда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының торак комиссиясе карары белән махсус торак фондыннан торак бирелүгә мохтаҗ ятим баланы аның әтисе ягыннан тәэмин итү булмауны раслаучы, шулай ук торакка хокукын раслаган документлары булмау сәбәпле, торакка мохтаҗ ятим балалар исемлегенә кертүдән баш тартканнар.

Вәкаләтле вәкил тикшерүе нәтиҗәләре буенча шул ачыкланды, әлеге күрсәтелгән документларны тәкъдим итү буенча таләпләр федераль законда да, төбәк законында да юк.

Ачыкланган хәлне исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгать итүче гражданның бозылган хокукларын торгызу өчен тиешле һәм кирәкле чараларга кагылышлы тәкъдимнәр җибәрде, аны карап, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мөрәҗәгать итүчене элек гариза җибәргән көненнән махсус торак фондыннан торак бирүгә мохтаҗ ятим балалар исемлегенә кертү турында карар кабул итте.

Гражданнарның торакка хокукларын тәэмин итү дәүләт яклавына мохтаҗ булганда, без Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә һәм Россия Федерациясе башкарма хакимияте федераль органнарына торак шартларын яхшырту федераль бюджеттан акча бүлү белән бәйле булган очракларда мөрәҗәгатьләр җибәрдек.

Былтыр Вәкаләтле вәкилгә янгынга каршы хезмәт органнарында 30 ел хезмәт итеп, 2004 елдан бирле торак шартларын яхшыртуны көткән Казан кешесе мөрәҗәгать итте.

Тикшерү нәтиҗәсендә шул ачыкланды, торак шартларын яхшыртуга озак вакыт чират көтү белән, янгынга каршы хезмәтнең башка хезмәткәрләре (элеккеге хезмәткәрләр) дә очрашкан, алар да торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган һәм җыелма исемлекләрдә 15 елдан артык чиратта торалар.

Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстандагы идарәсеннән алынган мәгълүматларга караганда, 2020 елга торак алу яки төзү өчен бер тапкыр бирелә торган социаль түләү акчасы алу өчен исәптә янгынга каршы хезмәтнең 300 хезмәткәре (элеккеге хезмәткәрләр), дәүләт торак сертификаты алуга 10 хезмәткәр (элеккеге хезмәткәрләр) тора.

2017 елда Татарстан Республикасында бер тапкыр бирелә торган социаль түләү акчасы белән 7 хезмәткәр, дәүләт торак сертификаты белән – 2 хезмәткәр; 2018 елда шуңа ярашлы рәвештә – 2 һәм 3 хезмәткәр; 2019 елда бер тапкыр бирелә торган социаль түләү акчасын алучылар булмаган, 4 хезмәткәр дәүләт торак сертификаты белән тәэмин ителгән; ә 2020 елда торак сертификатлары алучы хезмәткәрләр булмаган.

Федераль норматив хокукый актлар белән күрсәтелгән гражданнарны торак белән тәэмин итүнең дәүләт финанс яклавы формалары эшләнгән, ләкин Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән Казан кешесе мисалында, янгынга каршы хезмәт хезмәткәрләренең торак шартларын яхшырту буенча эшләнгән программаларны тормышка ашыруда проблемалар булуы күзәтелә.

Мондый шартларда без, хәлне яхшырту максатыннан, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм стихияле бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министры Е.Н. Зиничевка, шулай ук Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н. Москальковага, күрсәтелгән органнар хезмәткәрләренең килеп туган торак проблемасы турында хатлар яздык.

Торакка хокукларны тормышка ашыру гражданнарның торак биналарында уңайлы һәм имин яшәвен үз эченә ала.

Күпфатирлы йортлар белән идарә итүдә гражданнарның торакка хокукларын яклауны тәэмин итү, күпфатирлы йортларда милекчеләрнең уртак милкен тоту, шулай ук коммуналь хезмәт күрсәтү дәүләт торак күзәтчелеге, муниципаль торак күзәтчелеге һәм җәмәгатьчелек торак контроле аша алып барыла. Шуның белән бергә, Вәкаләтле вәкил тарафыннан гражданнар торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә озак вакыт чаралар күрелмәве турында хәбәр иткән очракларда, гражданнарның хокукларын яклау буенча эш тормышка ашырыла.

Халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә проблемалы хәлләр буенча Вәкаләтле вәкил җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Торак инспекциясе, Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы идарәсе белән бергәләп эшләде, шул исәптән, уртак күчмә тикшерүләр үткәрү юлы белән дә. Шулай итеп, Вәкаләтле вәкил катнашында түбәндәге мәсьәләләр уңай хәл ителде: апрельдә Яшел Үзән шәһәренең Кече Кызыл урамындагы күпфатирлы йорттагы фатирда су белән тәэмин итү басымы торгызылды; августта Казан шәһәренең Имәнлек урамындагы күпфатирлы йорт фатирында кайнар су белән тәэмин итү көйләнде; сентябрьдә Казан шәһәренең Бер яклы Нокса урамындагы зыян күргән суүткәргечтә авария бетерелеп, су белән тәэмин итү җайга салынды; октябрьдә Казан шәһәренең Халезов урамындагы күпфатирлы йорт фатирында җылылык белән тәэмин ителеш җайга салынды; Сарман районы авыл җирлегендә су колонкасы куелды; Казан шәһәренең Челюскин урамындагы күпфатирлы йорты янындагы территориядә каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыгы тиешле тәртипкә китерелде. 2020 елда Вәкаләтле вәкилгә гражданнардан торак-коммуналь өлкәгә кагылышлы мәсьәләләр буенча барлыгы 199 мөрәҗәгать килде.

Тулаем алганда, төрле чыганаклар, шул исәптән җәмәгатьчелек фикерен өйрәнүче үзәкләр халык арасында үткәргән сораштырулар, торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләре илдә яшәүчеләр өчен дә, шулай ук татарстанлылар өчен дә мөһим мәсьәләләрнең берсе икәнен күрсәтә.

Ел дәвамында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендә дөнья күргән 1319 нчы карарына ярашлы рәвештә, Вәкаләтле вәкил торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфатын халык бәяләве мониторингын тормышка ашырды. Аналитик эш йомгаклары буенча алынган нәтиҗәләр, алга таба эштә исәпкә алу өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына җибәрелде. Шулай ук узган елда Вәкаләтле вәкил «Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле төбәк үзәге» коммерциячел булмаган партнерлыгы эшләгән, максаты – язылган административ санкцияләр саны, авария-диспетчер хезмәтенә шалтыратулар саны, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар алдында бурычлары булу-булмавы, һәм «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы, «Ачык Казан» һәм «Ачык шәһәр» системалары аша алынган башка мәгълүматлар буенча Татарстан Республикасы күпфатирлы йортларында идарәче компанияләр эшчәнлеген бәяләү булган проектларның берсендә катнашты.

Вәкаләтле вәкил идарәче компанияләрнең эшчәнлеген бәяләү аларның эш сыйфатын күтәрүгә этәргеч бирер, шул исәптән, Татарстан Республикасында яшәүчеләргә торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүне яхшыртуда чагылыш табар дип ышана.

2019 елда 1998 елның 24 июнендә дөнья күргән 89 нчы «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» федераль законга, әйтик, каты коммуналь калдыкларны җыюның яңа системасына этаплап күчү юлы белән каты коммуналь калдыкларны җыюны хокукый көйләү өлкәсендә, кайбер сизелерлек үзгәрешләр кертелде, хәзер аларны төбәк территориясендә җыюны, озатуны, эшкәртүне, утильләштерүне, зарарсызландыруны һәм күмүне калдыклар җыю өлкәсендә төбәк программасы һәм калдыклар җыю территориаль схемасы буенча төбәк операторы тәэмин итәргә тиеш.

Күрсәтелгән яңа үзгәрешләр уңаеннан, узган елда Вәкаләтле вәкил адресына гражданнардан каты коммуналь калдыклар җыючы төбәк операторлары эшчәнлегенә кагылышлы мөрәҗәгатьләр килү артты.

Әйтик, Вәкаләтле вәкилгә шәхси кабул итүе вакытында, Тәтеш районының Кашка авылында яшәүчеләр төбәк операторының авыл җирлегеннән каты коммуналь калдыкларны чыгару буенча тиешенчә эшләмәвеннән зарланып мөрәҗәгать иттеләр. Алар төбәк операторы «УК «ПЖКХ» җәмгыятенең каты коммуналь калдыкларны даими чыгармавы, махсус техниканың килүе көнен һәм вакытын хәбәр итмәве, чүп чыгару графигы билгеле булмавы турында хәбәр иттеләр.

Вәкаләтле вәкил башлангычы белән Тәтеш районы җирле үзидарә органнары һәм «УК «ПЖКХ» җәмгыяте – төбәк операторы белән берлектә

оештырылган күчмә чарадан соң, 2020 елның 1 июленнән чүп чыгару билгеләнгән график һәм маршрут буенча тормышка ашырыла башлады, болар авыл халкына җиткерелде.

Алга таба республикада яшәүчеләр мөрәҗәгатьләренә оператив җавап бирү максатыннан, 2020 елның ноябрендә Вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында аерым «Каты коммуналь калдыклар» юнәлеше кертү турында тәкъдим әйтелде, ул өч яңа төрне – «Каты коммуналь калдыкларны чыгару», «Контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү», «Каты коммуналь калдыклар чыгару буенча хезмәтләрне түләү»не үз эченә ала, әлеге тәкъдимне каты коммуналь калдыклар җыючы төбәк операторлары – ООО «Гринта» җәмгыяте һәм «УК «ПЖКХ» җәмгыяте хуплады.

Мәгълүмат системасында күрсәтелгән төрләрне булдыру, каты коммуналь калдыклар белән җыю буенча коммуналь хезмәтләрне тиешенчә күрсәтмәү турындагы республикада яшәүчеләр мөрәҗәгатьләренә игътибар биреп һәм уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукны тәэмин итүдәге проблемалы мәсьәләләрне тиз арада хәл итәргә мөмкинлек бирде.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында яңа төрләр кертелгәч, ике айда контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү буенча 84 мөрәҗәгатьне, республиканың муниципаль районнарыннан каты көнкүреш калдыкларын чыгару буенча 66 мөрәҗәгатьне оператив хәл итәргә мөмкин булды.

Мәгълүмат системасына гражданнардан мөрәҗәгатьләр килгәч Казан, Чаллы шәһәрләрендәге, Әлмәт, Бөгелмә, Буа, Югары Ослан, Биектау, Алабуга, Яшел Үзән, Лаеш, Лениногорск, Түбән Кама, Питрәч, Тукай һәм Чистай районнарындагы контейнер мәйданчыклары төзекләндерелде.

Шуның белән бергә, Вәкаләтле вәкилнең «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына килгән мөрәҗәгатьләрне үзвакытында һәм сыйфатлы үтәүгә көндәлек контроле нәтиҗәсендә әлеге төрләр буенча үзвакытында чаралар күрелмәү фактлары ачыкланды.

Әйтик, Казан шәһәренең Константиновка бистәсендә яшәүчеләрдән утыз шикаять килүе ачыкланды, аларда каты коммуналь калдыкларны үзвакытында чыгармаулары, каты коммуналь калдыклар җыю өчен өстәмә мәйданчыклар булдырырырга кирәклеге, күрсәтелгән мәйданчык янындагы территорияне төзекләндерергә кирәклеге хәбәр ителде.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Совет районы хакимияте вәкилләре, шулай ук «УК «ПЖКХ» җәмгыяте төбәк операторы һәм мөрәҗәгать итүчеләр белән урынга барып тикшерү нәтиҗәсендә, мөрәҗәгатьләрдә әйтелгән фактлар расланды.

Урынга чыгып тикшерү нәтиҗәләре буенча, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, «УК «ПЖКХ» җәмгыяте төбәк операторы белән берлектә Константиновка бистәсендәге торак йортлар санын исәпкә алып урам-юл челтәренә анализ ясарга, Привольной һәм Интернациональ урамнарындагы территорияләр янында каты коммуналь калдыклар җыю өчен мәйданчыкны төзекләндерү буенча чаралар күрергә һәм каты коммуналь калдыклар чыгаруның тиешле схемасын булдырырга тәкъдим ителде.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына каты көнкүреш калдыклары җыю буенча килгән мөрәҗәгатьләрне карау барышы турында Вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты эш штабының контрольлек итүче органнар, җирле үзидарә органнары вәкилләре һәм төбәк операторлары катнашындагы атналык утырышларында да хәбәр итте.

Кешенең уңайлы әйләнә-тирә мохитка хокукларын саклау максатларында «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына «Чүплекләр» төре буенча гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрне үзвакытында һәм сыйфатлы итеп башкаруга контрольлек итү буенча максатчан эш алып барыла. Рөхсәт ителмәгән чүплекләрне бетерү буенча озак вакыт чаралар күрелмәве турындагы мәгълүмат «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасын эшләтү буенча ведомствоара комиссиянең 2020 елның биш ае эш йомгакларына багышланган утырышында да җиткерелде.

Соңрак, Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасын эшләтү буенча ведомствоара комиссия утырышы йомгаклары буенча, Казан шәһәрендә, Татарстан Республикасының Бөгелмә, Түбән Кама, Питрәч муниципаль районнарында рөхсәт ителмәгән көнкүреш калдыклары чүплекләре бетерелде.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрне карау барышында җаваплы башкаручыларның вакытыннан алда «Гариза хәл ителде» статусы бирү очраклары да ачыклана.

Без «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында бастырылган, Кама елгасы ярындагы «Кама» лагеры янындагы пляж территориясендәге рөхсәт ителмәгән чүплекне бетерү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьне тиешенчә үтәмәүләрен ачыкладык.

Россия Табигать күзәтчелегенең Татарстандагы идарәсе мәгълүматларына караганда, әлеге мөрәҗәгатькә 2020 елның 3 сентябрендә кимчелекләрне бетерү турындагы җавап белән «Гариза хәл ителде» дигән статус бирелгән. Ләкин

мөрәҗәгать итүче үз шикаятендә белдерүенчә, эш тулы күләмдә үтәлмәгән һәм ул моны дәлилләүче фотоматериал да урнаштырды.

Мөрәҗәгать итүченең хәбәрен истә тотып, без Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына күрсәтелгән рөхсәт ителмәгән чүплекне бетерү буенча контроль кирәклеге турында хат җибәрдек.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге көче белән чүплек юкка чыгарылды.

Вәкаләтле вәкил аерым игътибарын III – IV класслы куркыныч калдыкларга керүче, кулланылган автомобиль шиналарын рөхсәт ителмәгән саклауны бетерү буенча үзвакытында чаралар күрүгә контрольлек итүгә юнәлтте. Әлеге калдыклар уңайлы әйләнә-тирә мохитка: һавага, җир өсте һәм җир асты суларына, шул исәптән, эчә торган суга һәм туфракка тискәре йогынты ясый.

Мәсәлән, 2020 елның гыйнварында Вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Усад авылындагы ДСУ һәм Заовражной урамнарындагы йортлар территориясендә сакланучы рөхсәт ителмәгән автомобиль покрышкаларын бетерү мәсьәләсе буенча, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасындагы мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре белән килешмәү турында гражданнан мөрәҗәгать керде.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль берәмлеге башкарма комитеты әлеге мөрәҗәгать буенча үтәүгә туры килми торган аңлатма урнаштырып, нигезләнмәгән «Дәлилле кире кагу» статусы биргән.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетына кабат мөрәҗәгать иткәннән соң гына шикаятьтә күрсәтелгән автомобиль шиналары утильләштерелде.

Ел дәвамында кешенең уңайлы әйләнә-тирә мохитка хокукларын саклау һәм яклау буенча эш, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе, Россия Табигать күзәтчелегенең Татарстан Республикасындагы идарәсе белән берлектә алып барылды.

Вәкаләтле вәкилнең, кешенең социаль хокукларына дәүләт яклавын тәэмин итү буенча эшчәнлеге мисаллары буенча, шуны билгеләргә кирәк, Россия Федерациясе субъектларында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр турындагы федераль закондагы үзгәрешләр («Россия Федерациясе субъектларында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр турында»гы 2020 елның 18 мартында көченә кергән 48 нче федераль закон) тулаем алганда практик эш өстенлекләренә үзгәрешләр кертмәде. Килгән шикаятьләрне карау белән бергә, кеше хокуклары һәм ирекләре күпләп яки тупас бозылу турында

мәгълүматлар алганда яки аерым иҗтимагый әһәмияткә ия булган очракларда, яки мөстәкыйль рәвештә хокукый яклау чараларын кулланырга сәләтсез затларның мәнфәгатьләрен яклау зарурлыгы белән бәйле очракларда, үз башлангычы буенча чаралар күрүенә зур әһәмият бирелде.

## Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын яклау буенча эшчәнлеге

Гамәлдәге федераль закон нигезендә Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр пенитенциар система учреждениеләре эшчәнлегенә күзәтчелек итү субъектлары булып тора.

Әлеге уңайдан Вәкаләтле вәкил җинаятьләр кылуда шикләнелүчеләр һәм гаепләнүчеләр, сак астына алынганнар, хөкем ителгәннәр, иректән мәхрүм ителү яки мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәүчеләр, җинаять суд эше тәртибендә медицина характерындагы мәҗбүри чаралар кулланылган гражданнар, административ арест рәвешендә җәза билгеләнгән затлар хокукларын саклау белән бәйле мәсьәләләргә нык игътибар бирә. Вәкаләтле вәкил Аппаратына килгән шикаятьләрне карау белән беррәттән, даими нигездә проактив эш ысуллары кулланылды.

Аерым алганда, дәүләт органнары, Татарстан Республикасы Адвокат һәм Нотариаль палаталар вәкилләре, Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтчелек комиссиясе әгъзалары белән берлектә төзәтү учреждениеләрендә, җәзаларны үтәүне башкару мәсьәләләре буенча «Хокукый ярдәм көннәре» үткәрү практикасы кертелде.

Узган елда яңа короновирус инфекциясен булдырмау максатыннан чикләү чаралары урнаштырылуын исәпкә алып, «Хокукый ярдәм көннәре» форматы үзгәртелде һәм видеоконференцэлемтә режимына күчерелде. Шулай итеп, 2020 елда, иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче гражданнар әлеге элемтә каналы аша үз хокуклары бозылу турында хәбәр итү яки үзләрен кызыксындырган мәсьәләләр буенча консультация алу мөмкинлегенә ия булды. Күрсәтелгән чорда «Хокукый ярдәм көннәре» кысаларында алты кабул итү үткәрелде,аларда 56 тоткын кабул ителде.

«Хокукый ярдәм көннәре» кысаларында килгән мөрәҗәгатьләрнең күбесен (Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына килгән кебек үк) иректән мәхрүм ителү, аларга тиешле медицина ярдәме күрсәтелмәү белән бәйле шикаятьләр алып тора.

Мондый һәр мөрәҗәгать төзәтү учреждениесе шартларында хөкем ителүчегә медицина ярдәме күрсәтү проблемасы турында хәбәр итүче дип

бәяләнә алмый. Төзәтү учреждениеләре шартларында да, сәламәтлек саклау учреждениесе базасында да табиб-белгечләр медицина ярдәме күрсәтә. Әйтик, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең 16 нчы медицина часте федераль казна учреждениесе мәгълүматларына караганда, 2020 елда дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренә 265 хөкем ителгән һәм тикшерү-сак астында булган кеше китерелгән: планлы тәртиптә – 160 кеше, кичектергесез күрсәткечләр буенча – 105 кеше. Узган елда пенитенциар система учреждениеләрендә туберкулез, ВИЧ-инфекция һәм башка йогышлы авырулар таралуга юл куелмавын әйтергә кирәк.

Югарыда әйтелгәннәргә карамастан, аерым очракларда без иректән мәхрүм итү урыннарында җәза үтәүче затларга билгеләнгән медицина тикшеренүе вакытының сузылуын ачыкладык.

Йөрәккә УЗИ һәм сәламәтлек саклау учреждениесендә табиб-кардиолог консультациясе үткәрү вакыты төгәл билгеле булмаганлыктан, сентябрь аенда Вәкаләтле вәкилгә Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенең 2 нче вакытлыча тоту тикшерү изоляторында тотылучы тоткын мөрәҗәгать итте. Без катнашканнан соң мөрәҗәгать итүче стационар тикшеренүгә һәм «Хастаханә» бүлегенә дәвалануга җибәрелде, стационар дәвалану вакытында аңа кирәкле ультратавыш тикшеренүләре үткәрелгән, алар нәтиҗәләре буенча медико-социаль экспертиза үткәрү өчен документлар әзерләнеп, МСЭ территориаль бюросына җибәрелгән.

Хокук саклау эшчәнлегендә без хөкем ителгәннәрнең хезмәткә хокукларын саклауны бәяләүгә зур игътибар бирәбез (Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе мәгълүматлары буенча 2020 елның 16 декабренә хезмәткә җәлеп ителгән хөкем ителгәннәрнең тоткан урыны 61 процент тәшкил иткән. Гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә иректән мәхрүм ителүгә һәм мәҗбүри эшләргә хөкем ителгәннәр Россия Федерациясе законына ярашлы рәвештә, хезмәткә, шул исәптән хезмәткә түләүгә хокукларга ия. Монда үз эшчәнлегебез буенча да, башка чыганакларны анализлап та аерым проблемалар булуын билгелибез.

Әйтик, Татарстан Республикасытөзәтү учреждениеләрендә законнарны саклауга күзәтчелек буенча Түбән Кама прокуратурасы мәгълүматы буенча, 2020 ел дәвамында минималь хезмәт хакы күләме турындагы законга туры килмәгәнлектән хөкем ителгәннәрне эшкә җәлеп итү турында төзәтү учреждениеләре җитәкчеләренең 13 боерыгына протест белдерелгән. Татарстан Республикасы төзәтү учреждениеләрендә законнарны саклауга күзәтчелек буенча Казан прокуратурасы төзәтү учреждениеләре җитәкчеләренең 10 боерыгына протест белдергән.

Үз чиратында, мәҗбүри эш рәвешендә җәза үтүче хөкем ителгәннәргә карата да шундый хокук бозулар күзәтелүен ачыкладык.

Вәкаләтле вәкилгә мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән кешедән килгән шикаять буенча, прокуратура органнары безнең башлангыч буенча тикшерү үткәрде, аның нәтиҗәләре буенча эш бирүченең («Мегалит» оешмасы Яшел Үзән шәһәре) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 136 маддәсенең эш хакы түләү вакыты бозылу һәм минималь хезмәт хакы күләменнән кимрәк түләү өлешенә кагылышлы таләпләрен бозу фактлары ачыкланды.

Моңа кадәр хөкем ителүче Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә мөрәҗәгать иткән булган, аңа анда хезмәт мөнәсәбәтләрендә катнашучы хезмәткәр үзе һәм аның эш бирүчесе икәнен әйтеп, бары суд органнарына мөрәҗәгать итәргә кушканнар.

Шунысын да билгеләргә кирәк, Татарстан Республикасы хөкүмәтенең хокук бозуларны кисәтү комиссиясенең 2020 елның 28 сентябрендәге утырышы беркетмәсенә ярашлы рәвештә, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе җитәкчелегенә, хөкем ителгәннәрне мәҗбүри эшкә урнаштыру мәсьәләсе буенча потенциаль эш бирүчеләр белән килешүләр төзү эшен дәвам итәргә кушылды. Вәкаләтле вәкил эш бирүчеләр исемлеген киңәйтү хөкем ителгәннәрне күбрәк эшкә урнаштырырга мөмкинлек бирер, дип саный, ләкин яңа эш бирүчеләрне җәлеп итү хезмәткәрләрдә начар чагылыш табарга тиеш түгел. Безнең фикеребезчә, җинаять-башкару системасы органнары һәм учреждениеләре хезмәт законнарын саклауга дәүләт контроле өлкәсендә вәкаләтләре булмаган килеш, хөкем ителгәннәрне мәҗбүри эшкә тарту проблемасыннан баш тартырга тиеш түгелләр, хезмәткә түләү буенча аларның хезмәт хокуклары бозылу турында мәгълүмат алганнан соң, әлеге фактлар турында тиз арада контроль-күзәтчелек органнарына хәбәр итәргә тиешләр.

Эш бирүченең аерылгысыз бурычы булып, бер үк эшне бер үк күләмдә, бер үк сыйфат белән башкаручы хезмәткәрләргә тигез күләмдә хезмәт хакы түләү өлешендә хезмәт законнары таләпләрен саклау тора.

Вәкаләтле вәкил республика предприятиеләренә мәҗбүри эшкә урнаштырылган хөкем ителгәннәрнең хезмәт хакы, шундый ук эшне башкарган башка хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләменнән түбәнрәк булу очракларын да ачыклады.

Әйтик, без Казан шәһәре «Сафьян» җәмгыятенең «Россиядә эш» Гомумроссия вакансияләр базасында 20000 сум хезмәт хакы белән төрле эшләр башкаручыны эшкә кабул итү турында белдерү урнаштырганын ачыкладык. Ләкин төрле эшләр башкаручы итеп урнаштырылган мәҗбүри эшләргә җәлеп ителгән хөкем ителгәннәр өчен аның күләме 12500 сум тәшкил иткән.

Әлеге мәгълүмат прокуратура органнарына җибәрелде һәм прокурор тикшерүеннән соң, Казан шәһәренең Киров районы прокуратурасы «Сафьян» җәмгыятенә хезмәт законын бозуны бетерүне сораган кисәтү җибәрде.

Агымдагы елда җинаять-башкару системасы учреждениеләрен тикшергәндә иректән мәхрүм итү рәвешендә яки мәҗбүри эшләргә җәлеп ителү рәвешендә җәза үтәүче хөкем ителгәннәрнең хокукларын саклау буенча эш дәвам иттереләчәк, шул исәптән, хезмәт саклау өлкәсендә, сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә, инвалидларны социаль яклауга хокуклар бозылганы ачыкланган очракларда прокуратура органнары мәгълүматы да исәпкә алынып, тикшерү үткәреләчәк.

Бер үк вакытта шуны да билгеләргә була, иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче хөкем ителгән кешеләрне җинаять эшләре яисә тоту шартларына кагылышлы мәсьәләләр генә борчымый.

Алар бүгенгесе һәм киләчәге белән дә кызыксына, иректән мәхрүм итү урыныннан чыккач, эшләп, лаеклы хезмәт хакы алып, уңайлы фатирларда яшәргә телиләр.

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнарны тормышка яраклаштыру темасының актуальлеге шик уятмый, ул рецидив җинаятьчелек проблемасы белән дә тыгыз бәйләнгән. Татарстан Республикасындагы һәр икенче җинаять элек хөкем ителгән кеше тарафыннан кылына, җинаять кылганда хөкем ителү вакыты чыкмаган да була.

Иректән мәхрүм итү урыннарында социаль һәм психологик эш нәтиҗәлелеген күтәрү һәм хөкем ителгән кешеләргә постпенитенциар ярдәм системасын үстерү исәбенә, иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үткән затлар кылган рецидив җинаятьләрне киметү Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2010 елның 14 октябрендә дөнья күргән 1772-р нче карары белән расланган, 2020 елга кадәр җинаять-башкару системасын үстерү Концепциясенең төп максаты булып тора.

Дәүләтнең иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән кешеләр социаль файдалы хезмәт белән шөгыльләнсен дигән кызыксынуы күренә. Үз ягыбыздан шуны да билгеләми булмый, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән кешеләр кайбер сәбәпләр аркасында хезмәт базарында көндәшлеккә азрак сәләтле булалар, мәшгульлек хезмәте органнары ярдәменә күбрәк мохтаҗлар. Шул ук вакытта, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән кешеләр ел саен меңәрләп исәпләнә. Әйтик, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе мәгълүматлары буенча, 2020 елда иректән мәхрүм итү урыннарыннан 3146 кеше азат ителгән (узган елда – 3779 кеше).

Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы биргән мәгълүматка караганда, 2020 елның 1 ноябренә халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә мәҗбүри тоту урыннарыннан азат ителгән 316 кеше мөрәҗәгать иткән. Мәшгульлек үзәкләре булышлыгы белән 120 граждан эшкә урнаштырылган. Җәмәгать һәм вакытлы эшләр кысаларында агымдагы елда 6 граждан эшкә урнаштырылган.

Әлеге гражданнарны эшкә урнаштыру проценты югары түгел. Бу элеккеге хөкем ителгән кешеләрнең кирәкле күнекмәләре һәм осталыклары булмыйча, мондый күнекмәләр кирәк булган эш урыннарына дәгъва итүе белән дә бәйле булырга мөмкин. Бу хакта Татарстан Республикасының 2006 елның 24 июлендә дөнья күргән 60 нчы «Аеруча социаль яклауга мохтаҗ гражданнар һәм инвалидлар өчен эш урыннары квотасы һәм резервы турында»гы законына ярашлы рәвештә, элеккеге хөкем ителгәннәр эшкә урнаша алырдай эш урыннары квотасы елдан ел тулмау турындагы факт та дәлилли.

Шуның белән бергә социаль кләймә фактларын да истән чыгарырга ярамый. Барлык эш бирүчеләр дә хөкем ителгән кешеләргә карата яхшы фикердә түгел. Без бу проблемага берничә ел элек, берничә шәһәрнең мәшгульлек үзәкләрен тикшергәч, еллык докладларның берсендә игътибар иткән идек. Гражданны мәшгульлек хезмәте органы юлламасы белән эшкә урнашырга килгәч, хөкем ителгән булуын сәбәп итеп, эшкә алмаганнар.

Вәкаләтле вәкил адресына эшкә урнашуда ярдәм итүне сорап, элек иректән мәхрүм итүгә хөкем ителгән кеше мөрәҗәгать итте, ул ике ел буе хөкем ителүе аркасында слесарь-сантехник һөнәре буенча эшкә урнашуда кыенлыклар кичергән.

Бүгенге көндә республикада мәшгульлек үзәкләре вәкилләре төзәтү учреждениеләрендә даими булалар. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2020 елның ун аенда төзәтү учреждениеләрендә мәшгульлек үзәкләренең мобиль офислары биш тапкыр эшләгән, 70 хөкем ителүчегә консультация бирелгән.

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгәч үк эшкә урнашу мөмкинлеге күбрәк булсын өчен, без Вәкаләтле вәкил каршындагы Эксперт советының 2020 елның 20 ноябрендә, «Элеккеге хөкем ителгән кешеләрне тормышка яраклаштыруда дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары роле» темасына үткән утырышында, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре хезмәткәрләре һәм эшлекле сыйфатларын исәпкә алып,

хезмәткәрләрне эшкә җәлеп итүдә кызыксынган эш бирүчеләр вәкилләре белән бергә төзәтү учреждениеләренә бару мөмкинлеген карарга тәкъдим иткән идек.

Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, әлеге тәкъдим эш бирүчеләрдә яклау тапкан. Төзәтү учреждениеләре стеналары артында вакансияләр ярминкәсе үткәрергә Казан шәһәрендә һәм Питрәч муниципаль районында үз эшчәнлеген алып баручы өч эш бирүче теләк белдергән. Дәүләт органнарының бу юнәлештә беренче адымнар ясавын исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы карамагында булган мәшгульлек үзәкләренә хөкем ителгәннәр өчен вакансияләр ярминкәсе оештыруда кирәкле ярдәмне күрсәтер, дип ышана.

Шунысын да билгеләргә кирәк, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 29 июлендә дөнья күргән 631 нче карарына ярашлы рәвештә, ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән кешеләрне тормышка яраклаштыру буенча мөһим роль җирле үзидарәләр органнарына бирелә, алар каршында тиешле ведомствоара комиссияләр төзелә.

Шуның белән бергә, комиссияләр эше белән бәйле мәсьәләләр буенча җирле үзидарәләр органнарыннан алынган мәгълүматны анализлау, ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән кешеләрне тормышка яраклаштыру буенча ведомствоара бергәлек булмауның кайбер мисалларын күрсәтте.

Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетыннан тормышка яраклаштыруга булышлык итүгә мохтаҗ затларны ачыклау буенча планлы чаралар үткәрелмәвен дәлилләүче мәгълүмат керде. Алексеевск муниципаль берәмлеге башкарма комитеты мәгълүматыннан күренгәнчә, элек ирektән мәхрүм итү рәвешендә җәза үткәннәрне тормышка яраклаштыруны алар, муниципаль берәмлектә кабатланган җинаять буенча эчке эшләр органнары хезмәткәрләре үткәрә торган профилактика эше дип аңлый.

Ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны тормышка яраклаштыруда мондый караш булырга тиеш түгел дип саныйбыз. Асылда, мондый мөнәсәбәт булганда хөкем ителгән кеше, ул тормышка яраклаштыруга ризалык биргән очракта, аның мәнфәгатьләрен кайгыртып кабул ителергә мөмкин булган чаралар комплексы турындагы мәгълүматтан да мәхрүм ителә. Бу уңайдан Вәкаләтле вәкил фикеренчә, һәр муниципаль берәмлектә ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән кешеләрне тормышка яраклаштыру мәсьәләләрен хәл итү өчен чаралар планы эшләнергә тиеш.

Иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтүче хөкем ителгәннәрне тормышка яралаштыруның аерым элементы дип, әлеге төрне мәҗбүри эшләр рәвешенә алыштыруны атарга була.

2019 елдан Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтчелек комиссиясе әгъзалары белән бергә, хөкем ителгәннәрнең туганнарына һәм тоткыннарның үзләренә иректән мәхрүм итү рәвешен йомшаграк җәза төренә алыштыру турында консультацияләр бирү практикасы гамәлгә кертелде. 2020 елда 57 кабул итү үткәрелеп 500 дән артык кеше кабул ителде.

Хөкем ителүченең иректән мәхрүм итү рәвешендәге җәзаны мәҗбүри эшләргә алыштыру турындагы юлламасын суд караганда хөкем ителгән кешенең төзәлү хәлен бәяләү критерийларының берсе – зыян күрүчегә җинаять китергән зыянны каплау.

Әлеге мәсьәләне карау кысаларында кылган җинаятьтән китерелгән зыянны һәм матди зыянны каплау проблемасы әһәмиятен югалтмый. Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе мәгълүматлары буенча идарәнең структур бүлекчәләрендә үтәлүдә булган җинаять китергән зыянны каплау турындагы башкару эшләре 6 151 013 мең сумга 10022не тәшкил иткән. 2021 елның 1 гыйнварына прокуратура органнары мәгълүматлары буенча иректән мәхрүм ителгән 1708 кешенең башкару кәгазе булган, шулардан эшкә сәләтлеләре һәм эшкә урнаштырылганнары – 1509 кеше.

Үз чиратында, төзәтү учреждениесендә эшкә урнаштырылган хөкем ителүченең хезмәт хакыннан зыян күрүче файдасына түләүләр күчерелмәү очраклары да бар.

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил хезмәткәренең Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтчелек комиссиясе әгъзалары белән бергә гражданнарны кабул итү вакытында Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе 5 нче төзәтү колониясендә тотылучы тоткынның хатыныннан мөрәҗәгать керде, ул җинаять белән китерелгән зыян өчен, зыян күрүчеләр файдасына хөкем ителүчедән акча алу турында суд карары законлы көченә керүгә карамастан, аның җәза үтү урыныннан акча тоту өчен башкару документы күчермәсен суд приставы-башкаручысы җибәрмәве турындагы мәсьәлә белән мөрәҗәгать итте.

Хөкем ителүче үтәп бетермәгән иректән мәхрүм ителү рәвешендәге җәзасын мәҗбүри эшләргә алыштыру мәсьәләсе буенча судка мөрәҗәгать итәргә җыенган булган, ләкин зыян күрүчегә зыянны кайтармаганлыктан суд юлламасын канәгатьләндермәс дип уйлаган.

Кабул итү вакытында тоткынның хатынына башкару документы буенча бурычны каплау тәртибе аңлатылды, Татарстан Республикасы Баш суд

приставына закон бозуга юл куелу фактын бетерүгә булышлык итүне сораган хат җибәрелде.

Нәтиҗәдә, Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе белән уртак тырышлык нәтиҗәсендә гамәлдәге законны бозу бетерелде, суд приставы-башкаручысы карары белән тоткынның хезмәт хакының 50 проценты тотып калынды.

Шунысын да билгеләргә кирәк, Суд приставлары федераль хезмәтенең, аның территориаль органнарының, суд приставлары-башкаручыларының һәм Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең, җәза үтәтүче учреждениеләрнең, шулай ук җинаять-башкару системасы тикшерү изоляторларының үзара хезмәттәшлеге гомуми шартлары 2015 елның 25 ноябрендә дөнья күргән «Суд приставлары федераль хезмәте һәм Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең үзара хезмәттәшлеге турында»гы 0001/43/01-81180 нче Килешүендә (Алга таба – Килешү) билгеләнгән, аның положениеләре хезмәтләр вазифасына кергән һәм үзара кызыксыну тудырган мәсьәләләр буенча мәгълүмат алмашуны тормышка ашыру тәртибен билгели.

Килешүнең 2.1.2 пунктына ярашлы рәвештә, Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең төбәк органнарының структур бүлекчәләре иректән мәхрүм ителү рәвешендә җәза билгеләнгән бурычлыларга карата, җәза үтүче учреждениеләрдән тоткынның эшкә урнашуы турында да, аның хезмәт хакы турында да мәгълүмат сорыйлар.

Әлеге уңайдан Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә җинаять эше буенча, зыян күрүчеләр файдасына зыянны кайтару турындагы башкару документлары буенча Килешүнең 2.1.2 пунктына ярашлы рәвештә, төзәтү учреждениеләрендә җәза үтәүче гражданнарның хезмәт хакыннан тиешле сумманы вакытында алу максатыннан Россия Җәзаланы үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе белән бергә эшләүне тәкъдим итәбез.

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән кешеләрне тормышка яраклаштыру буенча эшкә катнашып, без еш кына җинаятьнең кешенең белеме һәм хезмәт күнекмәләре җитмәү, алкоголизмнан һәм наркотиктан бәйлелек аркасында социаль тирәлеккә ярашмау нәтиҗәсе, дип билгелибез. Социаль тирәлектән тайпылуны, димәк кабаттан җинаять кылу куркынычын – озак вакытка иректән мәхрүм ителү аеруча арттыра. Проблеманы хәл итү ысулының берсе – хөкем ителгәннәрне социаль тернәкләндерү буенча махсус чаралар кабул итү.

2018 елдан Вәкаләтле вәкил иҗтимагый оешмалар белән бергә, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе, 16 нчы медико-санитар часте, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау

министрлыгы һәм прокуратура органнары белән хезмәттәшлектә, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе 19 нчы төзәтү колониясендә махсус оештырылган «тернәкләндерү отряды» базасында психоактив матдәләрдән бәйлелеккә эләккән хөкем ителгән кешеләрне психик яктан төзәтү буенча проектны тормышка ашыра.

Узган елның сентябрендә әлеге проект шулай ук Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенең 2 нче төзәтү колониясендә дә тормышка ашырыла башлады.

Ел ахырына әлеге «тернәкләндерү отряды» базасында берничә дистә кеше тернәкләндерү, тернәкләндерүдән соңгы дәвалану курсларын узды. Тернәкләндерүне психологлар һәм социаль хезмәткәрләр үткәрә. Программа лекцияләрне, семинарларны, тренингларны, шәхси консультацияләрне үз эченә ала. Программа өч этаптан тора, аны тормышка ашыру вакыты – 6 ай.

Проектның ахыргы максаты психоактив матдәләрдән психологик бәйлелекне алу. Шул ук вакытта узган елда төзәтү учреждениесендә тернәкләндерү курсын үтү вакытын диспансер күзәтү вакытына кертү турында килешүгә ирешелде.

Әлеге тәҗрибәне уңай дип исәплибез. Хөкем ителгәннәр һәм аларның туганнары әйтүенчә, үткәрелә торган тернәкләндерү курсы психоактив матдәләргә тискәре мөнәсәбәт тудырырга, шулай ук гомум кабул ителгән кыйммәтләрне сакларга булыша. Шул ук вакытта алар өчен «тернәкләндерү отряды»нда булу – кайсыдыр вакытны «рәшәткә артында» үткәрү ысулы гына түгел, ә төзәтү учреждениеләре стеналарыннан тыш тормышка әзерләнгән булу мөмкинлеге.

Төзәтү учреждениеләрен һәм тикшерү изоляторларын тикшерү эшләрен үткәрү белән бергә, узган елда без Эчке эшләр министрлыгының республика районнарындагы бүлекләре махсус кабул итү һәм вакытлыча тоту изоляторларында булган затларны тоту шартларына таләпләрне саклау буенча Эчке эшләр министрлыгы һәм Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзалары белән бергә тикшерүләр үткәрүне дәвам иттек.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтчелек комиссиясе әгъзалары белән бергә, Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләрендәге вакытлыча тоту изоляторларында булдык. Анда коридорларның, гомуми куллану биналарының һәм камераларның санитар-гигиена торышы, матди-көнкүреш әйберләре ягыннан тәэмин ителеш тикшерелде.

Урынга барып тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, кимчелекләрне бетерү максатыннан Эчке эшләр министрлыгы министры А.В.Хохоринга шикләнелгән һәм гаепләнүче кешеләрне матди-көнкүреш әйберләре белән тәэмин итүдәге

кимчелекләрне бетерергә тәкъдим иткән хат җибәрелде. Хатны карау нәтиҗәләре буенча министрлык тиешле эш үткәрде.

Яңа короновирус инфекциясе таралу белән бәйле хәл иректән мәхрүм итүгә хөкем ителгән кешеләрнең, сак астында тотылган гаепләнүчеләрнең, шулай ук чит ил гражданнарын вакытлыча тоту үзәкләрендә тотылучы чит ил гражданнарының күрешүгә хокукларын тормышка ашыруга үз төзәтмәләрен кертте (2020 елның 11 аенда чит ил гражданнарын вакытлыча тоту үзәкләрендә 208 кеше бар иде).

Әлеге вәзгыятьне исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил мәҗбүри тоту урыннарында тотылучы затлар үз якыннары һәм туганнары белән күрешә алсын өчен законда каралган башка ысулларны тормышка ашыруга игътибарны юнәлтте.

Әйтик, Вәкаләтле вәкил адресына Чаллы шәһәрендә яшәүче, Чаллы шәһәрендәге чит ил гражданнарын вакытлыча тоту үзәгендә тотылучы иренә көн саен телефон элемтәсе хезмәтләреннән куллану мөмкинлеге бирелмәве аркасында хокуклары бозылу турындагы мәсьәлә белән мөрәҗәгать итте.

Шикаятьне карау нәтиҗәләре шуны күрсәтте, махсус учреждениедә тотылучы чит ил гражданнарына сишәмбе һәм җомга көннәрендә телефоннан аралашуга чикләүләр кертелгән. Билгеләнгән хәлне һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының 2016 елның 30 декабрендә дөнья күргән 935 нче боерыгы белән расланган, Россия Федерациясе чикләреннән чыгарып җибәрелергә тиешле чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны тоту өчен билгеләнгән Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы яки аның территориаль органы махсус учреждениеләре өчен үрнәк көн тәртибе положениеләрен исәпкә алып, без, Татарстан Республикасы Эчке эшләр министры адресына чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга телефон хезмәтләреннән файдаланганда каршылыклар тудырырга ярамавы турында хат җибәрдек. Хатны карау нәтиҗәсендә аларга көн саен телефон элемтәсеннән файдаланырга рөхсәт ителде.

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 18 апрелендә дөнья күргән 275 нче «Яңа короновирус инфекциясе (COVID-19) алга таба таралу куркынычы булганлыктан, Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның хокукый хәлен көйләү буенча вакытлыча чаралар турында»гы указы көченә керү, Россия Федерациясенең чит дәүләтләр белән авиа элемтәләрен вакытлыча туктату турындагы карар белән бергә, 2020 елда Вәкаләтле вәкилнең махсус учреждениедә тотылучы чит илләр гражданнарын яклау буенча интенсив эшчәнлеген көчәйтте.

Россия Федерациясе чикләреннән административ чыгарып җибәрелергә тиешле Үзбәкстан гражданнарын фактта чыгару буенча Вәкаләтле вәкил

Казандагы Үзбәкстан Республикасы Генераль консуллыгына мөрәҗәгать итте. Җәмәгать ярдәмчесе Г.Г. Балафендиева белән бергә, чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту үзәкләрендә тотылучы кешеләр өчен онлайн-консультацияләр үткәрелде (48 кеше консультация алды).

Мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын саклау мәсьәләләре элеккечә үк Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты контролендә кала.

## Кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре өлкәсендә хокукый агарту, аларны яклау формалары һәм ысуллары

Берләшкән Милләтләр Оешмасы кабул иткән Гомум кеше хокуклары декларациясе дәүләтләрнең кеше хокукларын һәм аның төп ирекләрен хөрмәт итүгә һәм саклауга булышлык итүен күздә тота. Хокукларның һәм ирекләрнең гомум характерын аңлауны тәэмин итү бу бурычны тулысынча башкару өчен зур әһәмияткә ия.

Халыкара оешмаларның һәм халыкара килешүләрнең катнашучысы буларак, Россия Федерациясе кеше хокукларын һәм аның төп ирекләрен гомум хөрмәт итүгә һәм саклауга булышлык итәргә йөкләмә алган. Шундый булышлык юнәлешләренең берсе булып – кеше хокуклары һәм ирекләре турында мәгълүмат тарату, кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре өлкәсендә хокукый агарту тора.

Үз хокукларыңны, ирегеңне һәм законлы мәнфәгатьләреңне белү – аларны саклауның нигезле гарантияләренең берсе. Хокукый мәдәният җәмгыятьнең хокукый тормышы сыйфатын, социаль төркемнәр, җаваплы вазифадагы затлар тәртибен, шулай ук дәүләт һәм гражданлык җәмгыяте тарафыннан гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен гарантияләү дәрәҗәсен билгеләүче халык мәдәниятенең бер өлеше булып тора. Бу мөнәсәбәттә хокукый агарту процессын һәм халыкка мәгълүмат бирүнең эзлеклелеген һәм тотрыклылыгын тәэмин итү өчен фәнни тирәлек, гражданлык җәмгыяте һәм дәүләт структураларының тырышлыгын берләштерү кирәк.

Вәкаләтле вәкил эшчәнлегендә кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре өлкәсендә хокукый агарту мөһим юнәлешләрнең берсе булып тора.

Кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре өлкәсендә хокукый агартуга булышлык итү, аларны яклау формалары һәм ысуллары 2000 елның 3 мартында дөнья күргән 95 нче «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча

вәкаләтле вәкил турында»гы Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә, Вәкаләтле вәкилнең төп бурычларының берсе.

Вәкаләтле вәкил эшендә хокукый агартуның мөһимлеген 2020 елда килгән мөрәҗәгатьләрне анализлау нәтиҗәләре дә күрсәтә, күп очракта бозылган хокукларны торгызу өчен Вәкаләтле вәкилнең катнашуы кирәк тә булмады. Кешеләргә үз хокукларын ничек итеп якларга кирәклеген аңлатырга гына кирәк иде һәм аларга бу хакта язмача яки телдән аңлатылды.

Берүк вакытта хокукый мәгълүмат бирүгә кагылышлы мөрәҗәгатьләр санының елдан ел югары булып калуын һәм килгән барлык мөрәҗәгатьләрнең 10 процентка якынын тәшкил иткәнен әйтергә кирәк (2014 елда – 146, 2015 елда – 186, 2016 елда – 146, 2017 елда – 256, 2018 елда – 106, 2019 елда – 210, 2020 елда – 500).

Вәкаләтле вәкил Аппаратында күп еллар инде хокукый агартуның түбәндәге практикасы уңышлы тормышка ашырыла:

- Гражданнарның хезмәт хокукларын саклау мәсьәләләре буенча оешмалар һәм предприятиеләрнең җитәкчеләрен һәм кадрлар хезмәткәрләрен өйрәтү семинар-киңәшмәләре;
- «Өченче буын университеты» тыңлаучылары өчен «Хокукый белемнәр мәктәбе»;
- Хәрби хезмәткә чакырылучылар һәм аларның ата-аналары өчен «Хокукый белемнәр мәктәбе»;
- Инвалид-балалар ата-аналары (законлы вәкилләре) өчен «Хокукый белемнәр мәктәбе»;
- Казанда, муниципаль берәмлекләрдә яшәүчеләр өчен «Хокукый ярдәм көннәре»;
- Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе карамагындагы төзәтү учреждениеләрендә «Хокукый ярдәм көннәре»;
- Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар өчен «Хокукый ярдәм көннәре»;
- Тематик телефон «кайнар элемтәләре»;
- Республиканың мәгариф оешмаларында «Кеше хокуклары буенча бердәм дәрес».

Вәкаләтле вәкил республика халкын мәгълүмат белән тәэмин итү өчен рәсми сайтын, социаль челтәрләрдәге Инстаграм (@tat_ombudsman) һәм ВКонтакте (https://vk.com/sariyasaburskaya) битләрен актив алып бара.

Вәкаләтле вәкилнең хокукый агарту өлкәсендәге эшчәнлеге министрлыклар һәм ведомстволар, җәмәгать оешмалары белән хезмәттәшлектә

алып барыла һәм дәүләт органнарының һәм гражданлык җәмгыяте вәкилләренең конструктив хезмәттәшлеге үрнәге булып тора.

Хезмәттәшлекнең әлеге формалары 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Стратегиядә каралган. Сигезенче бүлеге тулысынча хокукый агартуга һәм халыкның хокукый грамоталыгы дәрәҗәсен күтәрүгә багышланган, Стратегияне тормышка ашыру буенча чаралар планын үтәү турында мәгълүмат ел саен тулыланып, Стратегиядә барлык катнашучыларга җибәрелә, шул исәптән Вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына.

Татарстан омбудсманы институтының төп программа документы – 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Стратегияне тормышка ашыруның төп принцибы булып, гражданлык җәмгыяте өчен ачыклык тора.

Стратегияне тормышка ашыруның өстенлек юнәлешләренең берсе – кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау һәм яклау өлкәсендә дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм гражданлык җәмгыяте эшчәнлеген камилләштерү, моны аерым гына хәл итеп булмый, чөнки кеше хокукларын яклау өлкәсендә проблемаларны ачыклау һәм аларны хәл итү юлларын билгеләү, һичшиксез, уртак бурыч булып тора.

2020 елда, Россия Федерациясендә короновирус инфекциясе таралуга киртә булучы чикләү чараларына карамастан, Вәкаләтле вәкилнең хокукый агарту практикасы мәгълүмати технологияләрне кулланып дәвам итте.

Кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре өлкәсендә хокукый агарту буенча Вәкаләтле вәкил эше формаларының берсе – гражданнарның хезмәт хокукларын саклау мәсьәләләре буенча тематик семинар-киңәшмәләр.

Эш хакын түләү, хезмәт килешүләре төзү, хезмәтне саклау, архив эше мәсьәләләре актуаль булып кала һәм эш бирүчеләр ягыннан да, республиканың дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары ягыннан да аерым игътибарны таләп итә. Яңа форматта – Zoom программасын кулланып – Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы дәүләт Хезмәт инспекциясе, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы белән берлектә, республиканың 17 районының (Әгерҗе, Азнакай, Актаныш, Әлки, Әтнә, Балтач, Биектау, Минзәлә, Мөслим, Яңа Чишмә, Нурлат, Саба, Спасс, Тәтеш, Теләче, Чирмешән, Ютазы) меңгә якын предприятиесе һәм оешмасы катнашкан дәресләр үткәрелде.

2019 – 2020 елларда хокукый агартуның әлеге формасын тормышка ашыру барышында республиканың барлык муниципаль районнары колачланды. 2021 елда әлеге эш яңа форматта дәвам итәчәк. Гражданнарның хезмәт

хокукларын яклау мәсьәләләре буенча тематик семинар–киңәшмәләрне Татарстан Республикасының эре предприятиеләре вәкилләре өчен үткәрү планлаштырыла, шул уңайдан Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына, Татарстан Республикасының дәүләт Хезмәт инспекциясенә, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына бу юнәлештә уртак эшне дәвам итәргә тәкъдим итәбез.

Моннан тыш, 2021 елда Вәкаләтле вәкил яңа хокукый агарту проектын тормышка ашыруны – торак-коммуналь торак хуҗалыгы өлкәсендә гражданнарның хокукларын яклау мәсьәләләре буенча тематик семинар-киңәшмәләр үткәрүне күздә тота. Проектның максатчан төркеме – Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә идарәче оешмалар. Әлеге уңайдан Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясенә, «Татарстан Республикасындагы күп катлы йортлар белән идарә итү оешмалары берлеге» төбәк коммерциячел булмаган партнерлыгы үзкөйләүле оешмасына, «Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле төбәк үзәге» коммерциячел булмаган партнерлыгына әлеге проектны тормышка ашыруда катнашырга тәкъдим итәбез.

2020 елда видеоэлемтә форматында Zoom программасын кулланып «Россия пенсионерлары берлеге»нең төбәк бүлеге (җитәкчесе – Л.Н. Мишина) «Өченче буын университеты» тыңлаучылары өчен «Хокукый белемнәр мәктәбе» дәресләрен үткәрү практикасы дәвам итте. Узган елда «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында: эшчәнлек нигезләре, бурычлар һәм гражданнар хокукларын яклау ысуллары», «Социаль тәэминат: пенсия, пособиеләр», «Коммуналь хезмәтләр өчен түләүне исәпләү мәсьәләләре: торак законнарында соңгы үзгәрешләр», «Өлкән яшьтәге гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтү» темаларына дүрт дәрес үткәрелде.

Хисап чорында Вәкаләтле вәкил инвалид-балалар ата-аналары Бөтенросссия оешмасының төбәк бүлеге (җитәкчесе – Ж.В. Халтурина) белән бергә инвалид-балалар ата-аналары (законлы вәкилләре) өчен «Хокукый белемнәр мәктәбе» социаль проектын тормышка ашыра башлады, аның максаты – лекцияләр уздыру, шулай ук Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре белән очрашу үткәрү.

Компетентлы министрлыклар, ведомстволар һәм иҗтимагый оешмалар катнашында инвалид-балалар ата-аналары (законлы вәкилләре) өчен «Хокукый белемнәр мәктәбе»нең җиде дәресе узды, аларда тыңлаучыларга кешене инвалид дип тану кагыйдәләре, инвалид итеп таныганда кулланыла торган критерийлар һәм квалификацияләр, дәүләт хезмәтләре күрсәтү тәртибе –

административ регламентка ярашлы рәвештә медико-социаль экспертиза органнарында дәлилләү турында; санатор-курорт дәвалануга путевкалар бирү тәртибе һәм социаль хезмәтләр җыелмасы турында, әлеге мәсьәләләр буенча карарларга шикаять бирү тәртибе турында; салым законнарының гомуми нигезләре, инвалид-балалары булган ата-аналар өчен булган салым ташламалары турында; мөрәҗәгатьләр тапшыру кагыйдәләре, мөрәҗәгатьләр тапшырганда ышанычлы тоту күнекмәләрен формалаштыру ысуллары, бушлай юридик ярдәм күрсәтү тәртибе һәм урыннары турында; тернәкләндерү шәхси программасын формалаштыру һәм тормышка ашыру тәртибе турында; торак һәм торак-коммуналь өлкәдәге законнарда актуаль үзгәрешләр турында мәгълүмат бирелде.

2021 елда бу эш дәвам итәчәк. Моннан тыш, Вәкаләтле вәкил хокукый агарту буенча чараларда катнашучылар аудиториясен киңәйтергә планлаштыра, шул уңайдан 2021 елда әлеге проектны тормышка ашыруга һәм үстерүгә Гомумроссия инвалидлар оешмасының «Бөтенроссия Хезмәт Кызыл байрагы орденлы сукырлар җәмгыяте» Татарстан төбәк бүлегенә, гомумроссия инвалидлар оешмасының «Бөтенроссия чукраклар җәмгыяте» Татарстан төбәк бүлегенә, Гомумроссия инвалидлар җәмгыятенең «Татарстан Республикасы инвалидлар җәмгыяте» Татарстан төбәк бүлегенә кушылырга тәкъдим итә.

Россия Федерациясендә язгы чакырылыш кампаниясе короновирус пандемиясе чорында старт алды. Яшь егетләрнең сәламәтлеген саклау максатыннан, Вәкаләтле вәкил, республиканың муниципаль берәмлекләре башлыклары һәм Татарстан Республикасы Хәрби комиссары адресына чакырылыш чараларын үткәргәндә, короновирус инфекциясе пандемиясе чорында чир таралуга юл куймаучы шартларны тәэмин итү кирәклеген сораган хатлар җибәрде.

Әлеге өлештә чакырылыш комиссияләре әгъзаларына һәм хәрби хезмәткә чакырылучыларга битлекләр һәм перчаткалар кияргә кирәклеге, куллар өчен йогышсызландыру чаралары булу, хәрби хезмәткә чакырылучыларны чакырылыш чараларына чиратлар булдырмас өчен график нигезендә чакыру, социаль дистанция саклау, биналарны даими дезинфекцияләү һәм җилләтү кирәклеге тәкъдим ителде. Вәкаләтле вәкилнең әлеге тәкъдимнәренең чакырылыш комиссияләре тарафыннан үтәлешен муниципаль берәмлекләрдә һәм шәһәрләрдә, муниципаль берәмлектәге чакырылыш комиссиясе әгъзасы булган җәмәгать ярдәмчеләре күзәтте.

Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Хәрби комиссары белән бергә Татарстан Республикасыннан хәрби хезмәткә чакырылучыларны һәм хәрби хезмәткәрләрне хокукый агарту буенча планлы эшне дәвам итте, аларга, хәрби хезмәткә чакырылучылар һәм аларның ата-аналары өчен «Хокукый белемнәр

мәктәбе» кысаларында, аларның хокуклары һәм аларны яклау ысуллары турында, шулай ук Россия Федерациясе субъектларындагы хәрби частьларында, шулай ук командаларны хәрби хезмәт итү урыннарына озатканда аларның хокукларын яклауга булышлык итү турында сөйләде. 2020 елда санитар-эпидемиологик хәл начар булганлыктан, Татарстан Республикасы Апас һәм Түбән Кама районнарында яшәүче хәрби хезмәткә чакырылучылар һәм аларның ата-аналары өчен «Хокукый белемнәр мәктәбе»нең ике генә дәресе үтте.

2020 елның язгы һәм көзге чакырылышлары кысаларында Вәкаләтле вәкил һәм аның ярдәмчеләре эшелонда 300 татарстанлыны озата барды, Байкал арты, Хабаровск өлкәләрендәге, Кырым Республикасындагы, Самара һәм Свердлов өлкәләрендәге, Казан шәһәрендәге 11 хәрби частьтә булды.

Хәрби частьларда булганда Вәкаләтле вәкил һәм аның ярдәмчеләре часть җитәкчелеге белән очрашулар үткәрәләр, Татарстаннан булган хәрбиләр белән әңгәмә коралар, аларны омбудсман институты компетенцияләре, аларның хокуклары, аларны яклау ысуллары белән таныштыралар, Татарстан Республикасыннан килгән егетләрнең хәрби хезмәттәге шартлары никадәр уңайлы икәненә инану өчен, казармаларны, уку классларын, ашханәне, медицина пунктын, юыну бүлмәләрен, тренажер залын карыйлар.

Чакырылыш кампанияләре кысаларында, традицион рәвештә типографиядә бастырылып, Татарстанның хәрби хезмәткә баручыларына 3 мең данә хәрби хезмәт үтү тәртибе, хәрби хезмәткәрнең хокуклары һәм вазифалары турында җавап бирүче мәгълүмати бюллетень – «Хәрби хезмәткә чакырылучы белешмәсе» бастырылды.

Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре дәүләт хакимияте органнары һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләре белән бергә, «Хокукый ярдәм көне»н үткәрү барышында һәм тематик «кайнар элемтә»ләрне оештырганда бушлай юридик ярдәм оештырды.

Мәҗбүри тоту урыннарында тотылучы затлар өчен «Хокукый ярдәм көннәре» Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе белән берлектә, агымдагы елда алты тапкыр үткәрелде: бер тапкыр – урында, биш тапкыр – видеоконференцэлемтә тәртибендә гражданнарны бергәләп кабул итү формасында. Телдән мөрәҗәгать итү мөмкинлеге Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенең 3 нче төзәтү колониясендә, 5 нче төзәтү колониясендә, 10 нчы төзәтү колониясендә, 18 нче төзәтү колониясендә, 19 нчы төзәтү колониясендә, 4 нче төзәтү колониясендә, 2нче төзәтү колониясендә, 8 нче төзәтү колониясендә җәза үтәүче 56 хөкем ителгән кешегә бирелде.

Мигрантлар, шул исәптән Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Камадагы чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту үзәгендә тотылучылар өчен, шулай ук күзгә-күз һәм видеоконференцэлемтә тәртибендә «Хокукый ярдәм көннәре» үткәрелде. 2020 елда чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар өчен 1400 тапкыр консультацияләр үткәрелде.

Өч тапкыр Россия Пенсия фондының Казандагы район бүлекләрендә «Россия пенсионерлары берлеге»нең Татарстандагы бүлеге белән берлектә (идарә рәисе – Л.Н.Мишина) үткәрелгән «Хокукый ярдәм көннәре»ндә гражданнар 71 тапкыр консультация алды.

2020 елда Вәкаләтле вәкил җиде «кайнар элемтә» үткәрде. Болар: «Хезмәт мәсьәләләре», 10.02.2020; «Хәрби хезмәткә чакырылганда гражданнарның хокукларын яклау», 11.03.2020, 01.10.2020; «Сайлаулар үткәрү вакытында гражданнарның сайлау хокукларын саклау», 29.06.2020 – 01.07.2020, 10.09.2020 – 13.09.2020; «Сәламәтлекләре чикләнгән гражданнарның хокукларын яклау», 03.12.2020, аларда 561 кеше консультация алды.

«Кайнар элемтә» рәвешендә бушлай юридик ярдәм күрсәтү практикасын Вәкаләтле вәкил 2011 елда ук башлады, бу короновирус инфекциясе таралуга киртә булган чикләү чаралары кертелү вакытында актуаль булды.

Шунлыктан һәм гражданнар һәм консультация бирүче белгечләрнең сәламәтлеге өчен күзгә-күзгә карап консультацияләр үткәрүнең куркыныч булуын исәпкә алып, 2021 елда Вәкаләтле вәкил төрле темалар буенча ай саен «кайнар элемтә»ләр форматында «Хокукый ярдәм көннәре» үткәрергә планлаштыра.

Вәкаләтле вәкил элек Вәкаләтле вәкил оештырган «Хокукый ярдәм көннәрен» үткәргәндә катнашкан министрлыкларга, ведомстволарга, Россия Федерациясенең Татарстан Республикасындагы төбәк органнарына, тәкъдим ителгән форматта алга таба бергәләп эшләү мөмкинлеген карарга тәкъдим итә.

Хокукый агарту процессына яшьләрне һәм студентларны җәлеп итү максатларында, Вәкаләтле вәкил, 2020 елда гомуми, урта махсус һәм югары уку йортлары белән хезмәттәшлек итте.

2020 елда Кеше хокуклары халыкара көнен (10 декабрь) һәм Россия Федерациясе Конституциясе көнен (12 декабрь) бәйрәм итү кысаларында, Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында федераль омбудсман тәкъдиме буенча Вәкаләтле вәкил башлангычы белән, кеше хокуклары буенча Бердәм дәрес үтте.

Чаралар дәрес кысаларында республиканың 1 211 гомуми белем бирү оешмасында оештырылды. Кеше хокуклары буенча Бердәм дәрес үткәрүдә 157 290 укучы һәм 8 658 педагог катнашты.

Вәкаләтле вәкилнең муниципаль районнардагы һәм шәһәрләрдәге җәмәгать ярдәмчеләре өлкән сыйныф укучыларын, бала хокуклары турында Конвенция, Кеше хокуклары Декларациясе, Россия Федерациясе Конституциясе, кеше хокукларын яклауның гамәлдәге системасы, Россия Федерациясендәге һәм Татарстан Республикасындагы Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институты белән таныштырдылар.

Мәктәпләрдә шулай ук китап һәм методик әдәбият күргәзмәләре оештырылды, «Үз хокукларыңны бел, читләрнекен ихтирам ит», «Минем хокукларым», «Хокукым бар, ләкин бурычлы», «Мин һәм закон» темаларына әңгәмәләр үткәрелде, хокукый грамоталык дәресләре, видеороликлар күрсәтеп сыйныф сәгатьләре, «Закон яклавында» хокукый уеннары, «түгәрәк өстәл»ләр, сыйныф сәгатьләре үткәрелде, әлеге юнәлеш буенча проектлар якланды.

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт югары белем бирү бюджет оешмасы белән килешү буенча, 2020 елда университетның социаль эш факультеты студентларына «Кеше хокуклары. Бала хокуклары» темасына ике лекция укылды.

2020 елның сентябрендә Вәкаләтле вәкил булышлыгы белән «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт югары белем бирү автоном мәгариф учреждениесе, «Россия дәүләт хокук университеты» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Казан филиалы, «Болгар ислам академиясе» мөселман дини оешмасы студентларына, барлыгы бер меңнән артык кешегә, Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н. Москалькова кеше хокуклары буенча лекцияләр укыды.

Шулай ук 2020 елда Вәкаләтле вәкил Аппараты юриспруденция, политология, менеджмент, дәүләт һәм муниципальное идарәсе юнәлешләре буенча, Казан дәүләт университеты, Россия дәүләт хокук университеты, Казан инновацион университетының 29 студенты өчен производство һәм диплом алды практикасы үтү өчен мәйданчык булды.

2020 елда 16 декабрьдә Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт югары белем бирү автоном мәгариф учреждениесе белән үзара хезмәттәшлек турында төзелгән килешү буенча, гомуми белем бирү учреждениеләренең 7 – 11 сыйныф укучылары өчен кеше хокуклары буенча уку пособиесе әзерләү һәм бастыру, 2021 елда «Кеше хокукларын халыкара яклау» магистер программасын бергә тормышка ашыручы югары уку йортлары

Консорциум кысаларында, кеше хокуклары буенча VIII нче Җәйге мәктәп оештыру планлаштырыла.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, миграция, торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәләрендә халык белән эшләү буенча, пенсионерларга, эшсезләргә, тоткыннарга, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, авыр тормыш хәлендә калган кешеләргә ярдәм күрсәтү буенча күп кенә социаль әһәмиятле сорауларны коммерциячел булмаган хокук саклау иҗтимагый оешмалары белән бергәләп хәл итәргә туры килә, Вәкаләтле вәкил аларның социаль проектларын Татарстан Республикасы хөкүмәте, Татарстан Республикасы Президенты, Россия Федерациясе Президенты грант бәйгеләрендә катнашу стадиясендә яки аларны тормышка ашыру стадиясендә яклый.

2020 елда Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенең төзәтү учреждениеләре базасында махсуслашкан тернәкләндерү отрядлары төзү буенча проектны тормышка ашыру дәвам итте, аларның төп максаты – тернәкләндерү узган затларның психоактив һәм наркотик матдәләр куллану куркынычын киметү, тернәкләндерүгә булышу.

Әлеге социаль проектның инициаторлары – проектны Татарстан Республикасы территориясендә Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе 19 нчы һәм 2 нче төзәтү колонияләрендә җәелдерү өчен, Вәкаләтле вәкилнең теләктәшлеге алган «Вера» наркобәйлеләр туганнарының Казан иҗтимагый оешмасы (җитәкче – А.Я. Зарипов) һәм «Халыкны сәламәтлек саклау өлкәсендә профилактика һәм инициатива һәм социаль тискәре күренешләрне булдырмау» төбәк иҗтимагый оешмасы (җитәкче – А.Н. Дмитриев).

Проектны бергәләп тормышка ашыру максатыннан, Вәкаләтле вәкил, 2020 елда Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе 19 нчы һәм 2 нче төзәтү колонияләрендә оешкан тернәкләндерү отрядларында булды, реабилитантлар белән очрашты, төзәлү юлына баскан тоткыннарны яклау һәм башкарыла торган эшнең нәтиҗәлелеген күзәтү максатында алар белән аралашты.

Проектны тормышка ашыруның вакытлы йомгаклары, проблемалы мәсьәләләр һәм аны үстерү перспективалары 2020 ел дәвамында Татарстан Республикасында махсуслашкан тернәкләндерү отрядлары төзү буенча проектны тормышка ашыру буенча эшче төркем утырышларында тикшерелде, аларда даими төстә Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Республика наркология диспансеры» вәкилләре катнаша.

Программаны тормышка ашыру вакытында Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе 19 нчы төзәтү колониясендәге тернәкләндерү отрядында 540 дән артык кече психотерапия төркеме, 245 лекция, 80 тренинг, 980 шәхси консультацияләр үткәрелде. Отрядта тернәкләндерү программасында шушы чорда 42 тоткын катнашты.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе 2 нче төзәтү колониясендә 2020 елда проектта 21 кеше катнашты инде. Программаны тормышка ашыру чорында тернәкләндерү отрядында 80нән артык психотерапия төркеме, 50 лекция, 9 тренинг, 216 шәхси консультацияләр үткәрелде.

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларны Татарстан Республикасы хөкүмәте яклавында, психоактив матдәләрдән бәйле хөкем ителгән затларга, аларның гаиләләренә булышуның уникаль системасы эшли, ул наркотиклар куллануны киметүгә һәм социаль куркыныч авырулар (ВИЧ, туберкулез, гепатит һәм башкалар) һәм җинаятьчелек профилактикасына кагыла.

Профилактика буенча һәм җинаятьчелек рецидивын киметү буенча эшне тиешле дәрәҗәдә тоту өчен, проектны тормышка ашыруны даими финансларга кирәк. Проект көн саен хезмәт күрсәтү белән бәйле даими эшне күздә тотканлыктан, финанслауны өзү эшне бетерүгә китерәчәк, психоактив матдәләрдән бәйле затларга профилактик һәм тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүне киметәчәк.

Шунлыктан, психоактив матдәләрдән бәйлелеккә эләккән тоткыннарны тернәкләндерү буенча проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендә дөнья күргән 764 нче «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгатьчелек тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» турындагы карары белән расланган дәүләт программасына кертү, аны даими финанслауга мөмкинлек бирер, проектны Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенең башка колонияләрендә дә тормышка ашырып булыр, дип саныйбыз. Бу уңайдан Татарстан Республикасы хөкүмәтенә мондый мөмкинлекне карауны сорап мөрәҗәгать итәбез.

Миграцион мөнәсәбәтләрнең барлык тармагы: хезмәт мигрантлары, качаклар, хәер сорашучылар, илдән чыгарып җибәрелергә тиешле чит ил гражданнары һәм гражданлыклары булмаган затлар, Вәкаләтле вәкилнең социаль проектларны тормышка ашыруда «Яңа гасыр» автоном хәйрия коммерциячел булмаган оешмасы (генераль директор – Л.А.Таишева) һәм «Юридик клиника» мигрантларга һәм Татарстан Республикасында социаль яктан якланмаган башка катлауга хокукый ярдәм үзәге» төбәк иҗтимагый

оешмасы (җитәкче – Г.Г. Балафендиева) белән актив хезмәттәшлек итүе нәтиҗәсендә, читтә калмый. Алар 2020 елда Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең «Игелек эшләргә ашыгыгыз» медальләренә лаек булды.

2020 елда без иҗтимагый оешмалар белән берлектә, Татарстан Республикасы территориясенә кергәндә чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга төп хокуклар һәм законнар турында хокукый мәгълүмат бирдек, Android һәм IPhone өчен мобиль кушымталар белән рәсми сайтта мәгълүмат урнаштыру мөмкинлеге турында мәгълүмат бирдек. 2020 елда 710 мигрант M-help мобиль кушымтасында онлайн юридик һәм медицина мәгълүматы алды. 11 632 чит ил гражданы «Яңа гасыр» оешмасына мөрәҗәгать итеп, мәгълүмати материаллар алды. 37,7 % (4 387) чит ил гражданы һәм гражданлыгы булмаган зат бушлай юридик ярдәм ала алды. Социаль патронаж вакытында 8 204 мигрант информацион яклау алды.

Кеше хокукларын яклауның халыкара һәм дәүләт эчендәге стандартлары өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләре өчен курслар оештыру һәм үткәрү кысаларында, Вәкаләтле вәкил, «Яңа гасыр» оешмасы белән берлектә, «Хезмәт мигрантларын социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә комплекслы якын килү моделе» темасына җиде өйрәтү семинары үткәрде. Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык һәм Татарстан Республикасы хөкүмәте булышлыгы белән оештырылган семинарларда Россия Федерациясенең 62 төбәгеннән миграция сәясәте өлкәсендә эшләүче дәүләт (50 кеше) һәм коммерциячел булмаган оешмалар (78 кеше) җитәкчеләре һәм белгечләре катнашты.

Вәкаләтле вәкил теләктәшлеге белән «Яңа гасыр» коммерциячел булмаган оешмасы, «Җиңү өчен тест» проекты белән Президент грантлары Фонды бәйгесендә җиңүче булды, проект Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н. Москалькова тарафыннан хупланып, югары бәя алды.

Проектның төп бурычы – Россия Федерациясенең 9 төбәгендә яшәүчеләрне кеше иммунодефициты вирусы белән бәйле, өч «Тест-мобиль»дә мультидисциплинар командалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы «СПИД һәм йогышлы авырулар белән көрәш һәм профилактика буенча республика үзәге» хезмәткәрләренең медицина консультацияләре эше хисабына, тулы цикл тәртибендә профилактика, тест үткәрү һәм медико-социаль озата бару буенча бушлай хезмәтләр бирү юлы белән, кеше хокукларын яклау.

Нәтиҗәдә, 2020 елның июленнән, «Тест-мобильләрдә» мультидисциплинар команда 25 урынга чыгып, 731 кешегә тест үткәргән.

2021 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил мөрәҗәгате буенча, Идел буе федераль округы субъектларындагы омбудсманнар теләктәшлегендә «Җиңүгә тест» проекты Марий Эл, Башкортостан, Чувашстан, Удмуртия, Ульяновск, Киров, Самара һәм Оренбург өлкәләрендә тормышка ашырылачак.

Бу командалар эшендә Вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре дә актив катнашачак.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе белән берлектә (рәис – А.Г. Гайнутдинов), Вәкаләтле вәкил тарафыннан Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе һәм Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы карамагындагы мәҗбүри тоту урыннарындагы учреждениеләрдә хокукый агарту, бушлай юридик ярдәм күрсәтү, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен торгызу буенча актив эш алып барылды.

Вәкаләтле вәкил һәм Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе рәисе яисә комиссия вәкилләре белән берлектә, 245 тоткынның туганнарына бушлай юридик ярдәм күрсәтте.

Гадәттәгечә хөкем ителгәннәр өчен хәйрия акцияләре Татарстан Республикасы территориясендәге, шулай ук Чувашстан Республикасының Татарстан Республикасыннан җәза үтүче хатын-кызлар булган төзәтү колонияләрендә үтте.

«Социаль тернәкләндерү һәм адаптацияләү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы белән берлектә (генераль директор – А.Г. Гайнутдинов), Татарстан Республикасында авыр тормыш хәлендә калган кешеләр өчен «Приют» хәйрия проектын тормышка ашыру дәвам итте, яңа уртак проектлар кысаларында эш башланды. Болар – «Трудяги.РФ» социаль кадрлар агентлыгы, «Без булмасак кем?» волонтерлык хәрәкәте һәм башкалар.

2020 елда «Кеше приюты» социаль приютына яшәү урыны булмаган 2 373 кеше мөрәҗәгать итте. Аерым алганда, аларга түбәндәге төр ярдәм күрсәтелде («Кеше приюты» социаль проекты эшчәнлеге юнәлешләре буенча):

- 23 736 данә ризык таратылды.;
- 1 167 данә кием-салым бирелде.;
- 14 688 тапкыр куну урыны бирелде;
- 5 680 тапкыр мунча хезмәте күрсәтелде;
- 430 тапкыр чәчтараш хезмәте күрсәтелде;
- 78 сәгатьлек психологик консультацияләр үткәрелде – (63 кеше мөрәҗәгать итте);
- 104 сәгатьлек юридик консультация бирелде (230 кеше мөрәҗәгать

итте).

Моннан тыш, 12 кешегә Россия Федерациясенең башка төбәгенә китү өчен ярдәм күрсәтелде. Шулай ук 2020 елда гражданнарга төрле социаль учреждениеләргә урнашуга булышлык күрсәтелде. Әйтик, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Чаллы шәһәрендәге «Перекресток» аерым яшәү урыны һәм шөгыле булмаган затлар өчен социаль адаптацияләү үзәге» автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә 18 кеше, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Казан шәһәрендәге «Милосердие» аерым яшәү урыны һәм шөгыле булмаган затлар өчен социаль адаптацияләү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә – 12 кеше урнаштырылды.

2020 елда Вәкаләтле вәкил булышлыгы белән эшләүче «Социаль тернәкләндерү һәм адаптацияләү үзәге» коммерциячел булмаган оешмасы 7 кешенең ИНН, 7 кешенең СНИЛС, 9 кешенең паспортын торгызды, 8 гражданның пенсия белән тәэмин итүгә хокукын кире кайтарды.

«Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә иҗтимагый контроль төбәк үзәге» коммерциячел булмаган партнерлыгы белән берлектә (башкарма директор – Д.С. Романов), Татарстан Республикасында яшәүчеләргә торак-коммуналь хуҗалыгы мәсьәләләре буенча бушлай юридик ярдәм күрсәтелде, төп максаты, ярыш нигезендә торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә югары дәрәҗәдә хезмәт күрсәтү булган, идарәче компанияләр арасында «Идарәче компанияләр рейтингы» бәйгесе регламентын эшләү буенча эш алып барылды.

2020 елда Вәкаләтле вәкилнең социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар белән Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү, саклау, яклау һәм торгызу максатыннан нәтиҗәле хезмәттәшлек итү тәҗрибәсе Татарстан Республикасы оешуга 100 ел тулуга багышланган, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов кушуы буенча үткәрелгән «Татарстан турында 100%» онлайн-форумының онлайн-сессияләрендә, шулай ук яктыртылды, Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н. Москалькова катнашында Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының «түгәрәк өстәл» утырышында аерым тема булып каралды.

Гражданнарның хокукый аңын формалаштыруда төп аспектларның берсе – Вәкаләтле вәкил институты турында аларга массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек аша һәм халык өчен актив аралашу һәм фикер алышу урыны булган социаль челтәрләр аша мәгълүмат бирү.

Тулаем алганда, 2020 елда Вәкаләтле вәкил катнашында телевидениедә

8 видеосюжет чыкты, Татарстан Республикасы матбугат чараларында һәм интернет басмаларында 10 нан артык интервью (мәкалә) басылды. Моннан тыш, Вәкаләтле вәкил массакүләм мәгълүмат чаралары өчен даими төстә матбугат конференцияләре уздыра, вакыйгаларга, проблемалы мәсьәләләргә аңлатмалар бирә.

Вәкаләтле вәкил шулай ук кеше һәм граждан хокуклары һәм бурычлары, аларны яклау ысуллары турында мәгълүмат булган, әйтик, «Сезне полиция тоткарласа, нишләргә?», «Сез өйдә җәберләнсәгез, нишләргә?» «Хәрби хезмәткә чакырылучы белешмәсе» кебек буклетлар чыгарды, норматив актлар положениеләрен аңлатуга юнәлтелгән законнардагы яңалыклар турында рәсми сайтта (96) һәм социаль челтәрләрдә (111) мәгълүмат бастырды.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, Вәкаләтле вәкилнең халыкны хокукый агарту буенча эшчәнлеге, профиль белем бирү процессын оештыру өчен һәм җәмгыятьтә кирәкле хокукый белемнәр тарату өчен җаваплы дәүләт органнары эшен алыштырмый, ләкин аны тулыландыра. Вәкаләтле вәкилнең әлеге тармактагы эшенең актуальлеге Россия Федерациясендә хокукый мәгълүмат бирү һәм агарту Бердәм порталы эшен оештыру буенча үткәрелә торган эшчәнлек белән дә раслана, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы Россия Федерациясе Федераль җыены белән бергә Россия Федерациясе хөкүмәте карары проектын да эшләде.

Әлеге проект «Россия Федерациясендә бушлай юридик ярдәм күрсәтү турында» федераль закон положениеләрен, гражданнарның хокукый грамоталыгын һәм хокукый үзаңын үстерү өлкәсендә Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин раслаган Россия Федерациясе дәүләт сәясәте Нигезләрен тормышка ашыруга юнәлтелгән.

Портал төзүнең төп максаты – гражданнарның хокукый грамоталыгын һәм хокукый үзаңын үстерү, аларга аларның хокукларын саклау ысуллары, характеры турында хәбәрдарлыгы, административ һәм суд тәртибендә закон тарафыннан саклана торган мәнфәгатьләре, социаль тәртипнең төп моделе буларак законны үтәүгә стимуллар системасы төзү, хокукый нормаларны саклау һәм бурычларны намус белән үтәү идеяләрен җәмәгатьчелек аңына сеңдерү, шулай ук гражданнарга Интернет челтәрен кулланып, квалификацияле юридик ярдәм алу ысуллары һәм чикләре турында мәгълүмат бирү мөмкинлекләре өчен шартлар тудыру.

## Йомгак

Докладта әйтелгән проблемалардан чыгып, Вәкаләтле вәкил дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү, саклау һәм яклау максатыннан, кайбер чараларны тормышка ашыру мөмкинлеген карарга тәкъдим итә:

1. Гражданнарның хезмәткә хокукларын тормышка ашыру максатларында:

1.1. Хезмәт законнарын күзәтү буенча күзәтчелек алып баручы дәүләт органнарына, гамәлдә түгел дип танылган һәм юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан чыгарылган юридик зат (юридик зат гамәлләрен билгеләүче зат) исеменнән эш итүче вәкаләтле затлардан эш хакы буенча бурыч алуга юнәлтелгән чаралар күрергә.

1.2. Татарстан Республикасында Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына үз карамагындагы мәшгульлек хезмәте органнарына түбәндәгеләрне йөкләргә:

элек мәшгульлек органнары эшсез гражданнарны эшкә урнаштыру өчен биргән юллама буенча берничә тапкыр мөрәҗәгать иткән вакытка вакантлы урыннар тулганлыктан, эшкә алудан баш тарткан эшсез гражданнарны эшкә урнаштыру буенча кичектергесез чаралар күрергә (вакансия турында мәгълүмат алу белән кичекмәстән бу хакта эшсезгә хәбәр итәргә, шул исәптән телефон аша да); эшсезгә, булган аерым һөнәр яки вазифа буенча кирәкле хезмәткәрләр эзләп мәшгульлек үзәкләренә мөрәҗәгать иткән эш бирүчеләргә, үзенең персональ мәгълүматләрен кабаттан тапшырырга ризалык бирергә тәкъдим итәргә;

мәшгульлек хезмәтләре органнарының рәсми сайтында эшсез гражданнарны һөнәргә өйрәтү өчен курслар җыю турында мәгълүматлар урнаштырганда гаризаларны кабул итү даталар турындагы мәгълүматны да кертергә.

2. Кешенең социаль яклауга хокукларын тормышка ашыру максатларында:

2.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 апрелендә дөнья күргән, 267 нче карары белән расланган, өч яшьтән җиде яшькәчә балаларга айлык акчалата пособие бирү, шулай ук беренче төркем инвалид караучы затларга, шулай ук дәвалау учреждениесе заключениесе буенча читләр каравына мохтаҗ булган яки 80 яше тулган кешеләрне караган кешеләргә түләү, керемнәре булмаган, өч яшьтән җиде яшькәчә бала тәрбияләүче ата-

анага бала өчен айлык акчалата түләү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертергә.

2.2. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына комплекслы ярдәм күрсәтү максатларында, читләр ярдәменә мохтаҗ өлкән яшьтәге ялгыз гражданнарны ачыклау буенча социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эшен активлаштырырга.

2.3. Дәүләт учреждениесенә – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлегенә, рәсми сайтта, техник тернәкләндерү чарасы сатып алу яки хезмәтләр күрсәтүне тормышка ашыру вакытының соңгы билгеләнгән нәтиҗәләре буенча барлык техник тернәкләндерү чарасы яки хезмәтләр бәясе турында мәгълүматны үзвакытында урнаштырырга.

2.4. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына системалы төстә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче Даун синдромлы кешеләр санын, шулай ук йөзү белән шөгыльләнүче ДЦП диагнозлы балалар санын арттыруга юнәлтелгән тәкъдимнәрне эшләргә.

2.5. Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенә Россия Федерациясе Үзәк банкы Идел-Нокрәт баш идарәсенең Татарстан Республикасындагы Милли банкы белән берлектә, 2007 елның 2 октябрендә дөнья күргән 229 нчы «Башкару производствосы турында»гы законына ярашлы рәвештә чикләүләр куелган яки тартып алу мөмкин булмаган бурычлылар акчасын алуга кагылышлы проблемалы мәсьәләләр буенча карар эшләргә.

3. Ата-анасыз калган балалар, аларны тәрбияләүгә хокукны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре опека һәм попечительлек органнарына опекун (попечитель) булырга теләгән гражданнар гаризаларын карaганда опекун (попечитель) вазифаларын үтәү сәләтләрен, әхлакый һәм шәхси сыйфатларын бәяләү буенча тәкъдимнәр җибәрергә.

4. Гражданнарның сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокукларын саклау максатларында, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга бушлай медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләре программасы кысаларында, амбулатор-сырхауханә ярдәме күрсәтүне тормышка ашыручы медицина оешмалары белгечләренә үзвакытында язылуны оештыруга юнәлтелгән өстәмә чаралар күрергә.

5. Мәгариф өлкәсендә балигъ булмаган балалар хокукларын саклау максатларында җирле үзидарә органнарына:

укучыларны унынчы сыйныфка алу, шул исәптән профиль белем алуга кабул итү өчен индивидуаль сайлап алуны оештыру буенча гомуми белем бирү оешмаларында үзвакытында аңлату эшләре үткәрүгә контрольны тормышка ашырырга;

мәгариф оешмаларында ремонт эшләрен үзвакытында үткәрүгә контрольны көчәйтергә.

6. Гражданнарның торакка хокукларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына махсуслашкан торак фонды торак биналары белән тәэмин итү турында гаризаларны караганда, һәр очракта Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2019 елның 4 апрелендә дөнья күргән 397 нче карары белән расланган, торак белән тәэмин ителергә тиешле ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исемлеген төзү Тәртибе положениеләрен исәпкә алырга.

7. Уңайлы әйләнә-тирә мохитка кеше хокукларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы модераторы сыйфатында, «Чүплекләр» төре буенча эшне активлаштырырга.

8. Гражданнарның сайлауга хокукларын тормышка ашыру максатларында:

8.1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән берлектә, гражданнарның сайлау хокукларын күзәтү һәм «Минем тавыш» Татарстан сайлаучылары Форумы сессияләре кысаларында яшь сайлаучылар белән эшләү буенча эшне дәвам итәргә.

8.2. Җирле үзидарә органнарына, сәламәтлекләре чикләнгән гражданнарның, шул исәптән инвалидлар дип танылган кешеләрнең, аларны икенче катка күтәртү өчен лифтлар яки башка җайланмалар булмаган тавыш бирү өчен участокларны беренче каттан югарырак урнаштырмауга кагылышлы сайлау хокукларын тәэмин итүгә юнәлтелгән практиканы дәвам итәргә.

9. Иректән мәхрүм итү яки мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәүчеләрнең, мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгәннәрнең хокукларын саклау һәм яклау максатларында.

9.1. Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә:

мәшгульлек хезмәте органнарына төзәтү учреждениеләрендә җәзасын үтәп бетерергә алты айдан азрак вакыты калган хөкем ителгәннәр өчен, вакантлы урыннар булган оешмалар җитәкчеләре (вазифадагы затлар)

катнашында урынга барып, эш урыннары ярминкәсе уздыруда булышлык итәргә;

хөкем ителгән кешеләрне мәҗбүри эшкә урнаштыру өчен эш бирүчеләр белән килешүләр төзегәндә, хөкем ителгәннәрнең хезмәт хакына кагылышлы хезмәт хокукларын бозуга юл куймау буенча чаралар күрергә (мәҗбүри эшкә урнаштырылган хөкем ителгәннәргә эш бирүчеләр билгеләнгән хезмәт хакы күләменнән азрак хезмәт хакы билгеләгән очракта, мондый белешмәләрне контроль-күзәтчелек органнарына җибәрергә).

9.2. Җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 29 июлендә дөнья күргән 631 нче карары белән расланган, ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны тормышка яраклаштыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турында положениегә яраклы рәвештә, ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны тормышка яраклаштыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия эшен оештырырга.

10. Республикада яшәүчеләрне хокукый агарту максатларында:

10.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил «Вера» наркобәйлеләр туганнары Казан иҗтимагый оешмасы һәм «Халык сәламәтлеген саклау өлкәсендә профилактика һәм башлангыч һәм социаль тискәре күренешләрне булдырмау» төбәк иҗтимагый оешмасы белән берлектә тормышка ашыра торган психоактив матдәләрдән бәйлелеккә эләккән хөкем ителгән кешеләрне тернәкләндерү проектын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендә дөнья күргән 764 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» Дәүләт программасына кертү мөмкинлеген карарга;

10.2. Татарстан Республикасы Архив эше дәүләт комитетына, Татарстан Республикасы дәүләт Хезмәт инспекциясенә, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына гражданнарның хезмәт хокукларын саклау мәсьәләләре буенча оешмалар һәм предприятиеләр җитәкчеләре һәм кадрлар хезмәткәрләре өчен өйрәтү семинар-киңәшмәләр оештыру буенча Вәкаләтле вәкил белән берлектә эшне дәвам итәргә;

10.3. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгына, Татарстан Республикасы дәүләт Хезмәт инспекциясенә, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлар белән идарәче оешмалар берлеге» төбәк коммерциячел булмаган партнерлыгы үзкөйләүле оешмасына, «Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгы

өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле төбәк үзәге» коммерциячел булмаган партнерлыгына Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә гражданнар хокукларын саклау мәсьәләләре буенча өйрәтү семинар-киңәшмәләре үткәрү буенча проектында катнашырга;

10.4. Гомумроссия инвалидлар оешмасының «Бөтенроссия Хезмәт Кызыл байрагы орденлы сукырлар җәмгыяте» Татарстан төбәк бүлегенә, Гомумроссия инвалидлар оешмасының «Бөтенроссия чукраклар җәмгыяте» Татарстан төбәк бүлегенә, Гомумроссия инвалидлар җәмгыятенең «Татарстан Республикасы инвалидлар җәмгыяте» Татарстан төбәк бүлегенә, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең сәламәтлекләре чикләнгән затлар һәм инвалид-балалар ата-аналары (законлы вәкилләре) өчен «Хокукый белемнәр мәктәбе» проектын тормышка ашыруда катнашырга тәкъдим итә.

С.Х. Сабурская,
Татарстан Республикасында Кеше
хокуклары буенча вәкаләтле вәкил

Казан, февраль, 2021 ел